К. В. Закирова, Л. Р. Мортазина

# Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак

## Балалар бакчасында уеннар

***Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма***

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
тәкъдим ителгән



**Казан**
**2012**

УДК 373.24
ББК 74.100.58
З 18

**Рецензентлар:**

***М. М. Гибатдинов,*** ТР ФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге җитәкчесе, педагогика фәннәре кандидаты;

***Н. Г. Зарипова,*** Казан шәһәре 166 нчы балалар бакчасы мөдире;

***М. Г. Шиһабиева,*** Казан шәһәре 415 нче балалар бакчасы тәрбиячесе.

**Закирова К. В., Мортазина Л. Р.**

**З 18** Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма / К. В. Закирова, Л. М. Мортазина. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2012. – 192 б.

**ISBN**

Китап мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә эшләүче тәрбиячеләргә, физкультура инструкторларына, музыка җитәкчеләренә атап чыгарыла. Әсбаптан шулай ук башлангыч сыйныф укытучылары, озайтылган көн төркемнәрендә эшләүче педагоглар, педагогия көллиятендә укучы студентлар да файдалана ала. Тәкъдим ителгән уеннар бигрәк тә әтиәниләргә өйдә, табигать кочагында нәниләре белән ял вакытларын оештыруда файдалы ярдәмлек булыр.

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**ISBN**

© Редакционно-издательский центр, 2012
© Закирова К. В., Мортазина Л. М., 2012

# КЕРЕШ

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында иң яратып уйнала торган уеннар – *халык уеннары*. Халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш-көнкүреше чагылыш тапкан бу уеннар балаларда өлгерлек, тапкырлык, ярдәмләшү, шулай ук кешелеклелек, шәфкатьлелек, сабырлык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияли. Уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Уен вакытында балаларның иҗат мөмкинлекләре ачыла, мөстәкыйльлекләре арта, оештыру сәләтләре үсә. Кечкенә вакытта алынган хәрәкәт күнекмәләре нәниләргә әйләнә-тирә мохит белән тирәнрәк танышырга ярдәм итә. Халык уеннары – җитезлеккә, көчкә, зирәклеккә сынау ул.

Уеннарның нәниләрне тәрбияләүдә иң мөһим һәм алыштыргысыз чара булуын XX гасырның 20 нче елларында, әле татар балалар бакчалары барлыкка килә генә башлаган вакытларда ук, татар педагоглары да билгеләп үткән. Тәрбияче, үзе балалар бакчалары оештырган һәм шуңа җитәкчелек иткән Зөһрә Салихова уеннарга иң беренче чиратта сүз байлыгын арттыру чарасы буларак караган һәм уеннарның балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килү принцибын алга сөргән. Ул: «Балаларның шигырь, җыр, уен, музыкалары һәм һәрбер эшләре яшьләренә, телләренә күрә сайланып эшләнгән булырга тиеш. Баланың әхлагы да тиз формалашып китә торган чак – җиде яшькә кадәр булган вакыт. Җидедән соңга калган бозык табигатьле балаларны төзәтү ифрат кыен була, димәк, тәрбиячеләр, соңга калмыйча, бигрәк шул вакытка тырышлык

белән баланың рухын (психологиясен) ныклап өйрәнергә тиеш була», – дип яза һәм балаларның алдагы гомерендә танышачак күп нәрсәләрне уеннар, шигырь, җырлар аша күңеленә сеңдерергә мөмкин дип саный. Чыннан да, уеннар тирә-юньне, дөньядагы күренеш һәм предметларны аңлауда, аларны дөрес кабул итүдә иң төп чараларның берсе булып тора. Бала иң беренче эш күнекмәләрен дә нәкъ менә уеннар аша ала. Бу яктан караганда уеннарның әһәмияте кимеми, киресенчә, вакытлар үтү белән арта гына бара. Бүген, зур технологияләр алга киткән фән-техника чорында, иң гади булган күренешләр, предмет һәм күнекмәләр белән таныш булмаган балалар да бар. Халык уеннары шул бушлыкны тутыруда әһәмиятле бер чара булып тора.

Әлеге **уеннар җыентыгын төзүнең максаты** – тәрбиячеләрне һәм ата-аналарны моңарчы бик үк билгеле булмаган, онытыла башлаган уен үрнәкләре белән таныштыру, 20–40 нчы еллардагы халык уеннарын торгызу, заман таләпләренә яраклаштырып, бүгенге көн балаларына аларны җиткерү. Билгеле булганча, кайбер уеннар, еллар үтү белән, үзгәрешләр кичереп, башка яңгыраш алганнар. Без бу уеннарның беренчел, борынгырак вариантларын тәкъдим итәргә булдык.

Китапта төп урынны 20–40 нчы елларда халык тарафыннан яратып уйналган, шулай ук совет чорында төрле милләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә татар балалар бакчаларына кергән интернациональ уеннар алып тора.

Әсбапны язуда С. Миңлекәйнең «Балалар өчен җырлы уеннар» (1925), З. Салихованың «Мәктәпкә кадәр тәрбия өчен кулланма» (1925), «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен хәрәкәтле 16 уен һәм җәйге тәрбия мәйданында аларны үткәрү кагыйдәләре» (1933), «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кагыйдәле хәрәкәтле уеннар» (1940), «Уеннар» (1945), «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен хәрәкәтле уеннар» (1948) һ. б. китаплар файдаланылды. Катлаулы эчтәлектәге уеннар гадиләштерелде, балаларның яшьләренә яраклаштырылды,

заман шартларына, бүгенге көн педагогика һәм методика фәннәре таләпләренә туры китереп үзгәртелде.

Җыентык 3 бүлектән тора. **«Уйныйк, сөеник, көлик!..» дип исемләнгән I бүлеккә *хәрәкәтле уеннар*** тупланды. Алар балаларның психологик үзенчәлекләрен истә тотып, яшь аермалыкларына карап, һәр төркем өчен бүленеп бирелде.

Балаларның яше арткан саен, уеннарның максаты катлаулылана бара. Төрле яшьтәге балаларга бер уенның төрле вариантларын тәкъдим итәргә була. Мәсәлән, балаларның бик яратып уйный торган «Песи һәм тычканнар» уены. Тәрбияче 3–4 яшьлек нәниләрнең, бер-берләренә бәрелешмичә, төрле юнәлештә йөгерүләрен максат итеп куйса, зуррак төркемнәрдә балалар сигнал буенча тиз хәрәкәт итәргә, мәйданчыкта урыннарын табарга, куышып уйнарга өйрәнәләр. Алар түгәрәккә тезелергә, түгәрәк буйлап йөрергә, хәрәкәтләрне сүзләргә яраклаштырып башкарырга күнегәләр.

Хәрәкәтле уеннар *йөгерүле, сикерүле, ыргытулы* һ. б. шундый төрләргә бүленәләр.

*Йөгерүле уеннарның* максаты – балаларда туры һәм төрле юнәлештә йөрү, йөгерү күнекмәләре булдыру, сигнал буенча хәрәкәт башкара белүләрен үстерү, бер-бер артлы тезелеп йөрергә һәм йөгерергә, бер-берсен куып тотарга өйрәтү, игътибарлылык, җитезлек, өлгерлек тәрбияләү.

*Сикерүле уеннар* ярдәмендә балалар бер урында, ике аякта берьюлы, югарыдан түбәнгә, озынлыкка сикерергә өйрәнәләр; балаларда хәрәкәтләрне күрү сигналы белән яраштыра белү күнекмәләре булдырыла, сигнал буенча хәрәкәт итә белү күнекмәләре үстерелә.

*Ыргытулы уеннар* ярдәмендә балалар туп тәгәрәтеп уйнарга, бер-берсенә туп тапшырырга, гәүдәне уңга һәм сулга борырга, хәрәкәт итүче бер ноктага атып тидерергә өйрәнәләр.

Уен ул – гасырлар буена үскән, камилләшкән тәрбия чарасы. Кешелек җәмгыяте үсү белән, уеннар да катлаулылана һәм камилләшә бара.

Уеннар, элек-электән күңел ачу чарасы гына булып кал-

мыйча, иң беренче чиратта тирә-юньне, дөньяны танып белүдә, тормышта иң кирәкле булган белем һәм күнекмәләрне үзләштерүдә дә зур роль уйнаганнар. Шуңа күрә уеннарда иң беренче чиратта бабаларыбызның эш-гамәлләре, һөнәри эшчәнлекләре чагылыш тапкан. Шул ук вакытта, бу уеннарга карап, халкыбызның күңел көзгесен күз алдына китерергә, уй-кичерешләрен белергә дә мөмкин. Шуңа күрә дә бүгенге көндә халыкның элеккеге уеннарын кире кайтару мөһим. Бу уеннарны педагогик процесста дөрес файдалану тарихыбызны, халкыбызның борынгы гореф-гадәтләрен яхшырак белергә, шулай ук балаларыбызның милли үзаңы формалашуга ярдәм итә.

Татар халык уеннары арасында чагыштырмача соңгы вакытларда барлыкка килгән, башка халыклардан кергән уеннар белән беррәттән, күп гасырлар буе сакланганнары да бар. Мәсәлән, бүгенге балалар тарафыннан яратып уйнала торган «Очты-очты» уенының инде XI гасырда ук билгеле булганлыгы мәгълүм (бу турыда төрки телләр белгече, иң борынгы язма истәлекләрне туплаган «Диване лөгатет-төрк» сүзлеге авторы Мәхмүт Кашгари язып калдырган). Әлеге һәм башка шундый ***аз хәрәкәтле, зиһен сынаш уеннары,*** шулай ук халкыбызның борынгы заманнардан ук яратып уйнаган уеннарыннан берсе – ***җырлы-биюле уеннар*** – җыентыкның **«Уйнап күңел ачабыз» исемле II бүлегендә** тупланып бирелде.

*Аз хәрәкәтле уеннар* балаларның игътибарлылыгын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, дикъкатен арттыруга, тапкырлыкларын үстерүгә, зиһеннәрен ныгытуга ярдәм итә. Әлеге уеннар ярдәмендә балаларда сабырлык, түземлелек, кыюлык, гаделлек кебек әхлакый сыйфатлар да тәрбияләнә.

*Җырлы-биюле уеннарның* максаты – балаларда җыр һәм музыканың характерына туры китереп хәрәкәт итү күнекмәләре формалаштыру; халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну һәм аларга карата мәхәббәт тәрбияләү. Уен вакытында балалар көйгә карап хәрәкәтләнәләр, дәртләнеп

җырлыйлар, бииләр. Әлеге уеннар музыкаль авазларны тоемларга ярдәм итәләр, балаларның күңелләрендә нәфислек, матурлык тойгысы уяталар.

Соңгы елларда мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә, *нәниләрне туган халкының рухи-әхлакый һәм милли-мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү белән беррәттән, башка милләт вәкилләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыруга җитди игътибар бирелә.* Бу бурычлар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе, үтемлесе һәм нәтиҗәлесе – халык уеннары.

Күпмәдәниятле (поликультуралы) тәрбия максатларын истә тотып, әлеге бүлеккә рус һәм янәшәбездә яшәүче башка тугандаш халыкларның хәрәкәтле уеннары кертелде. Бу уеннар балаларда Идел буенда яшәүче төрле милләт вәкилләренә, аларның гореф-гадәт, йолаларына ихтирамлы мөнәсәбәт тудыруда; башкаларны ихтирам итү, кешелеклелек, тату яшәү һ. б. шундый матур әхлакый сыйфатлар тәрбияләүдә ярдәмче булыр. Аларны катнаш төркемнәрдә, шулай ук мәдәниятара бәйләнешләрне ныгыту максатында, татар балаларын башка милләтләрнең мәдәнияте белән таныштырганда файдаланырга мөмкин.

**«Уйнап һич тә туймыйбыз!..» дип исемләнгән III бүлектә** дәрес-шөгыльләрдә файдалану өчен, ***физкультминутлар һәм санамышлар*** тупланды.

Физкультминутларның максаты – төрле эшчәнлек вакытында нәниләргә кыска вакытлы ял итү мөмкинлеге булдыру; ишетү, күрү органнарын, гәүдә мускулларын, кул чукларын ял иттерү. Аяк-кул, бармак, муен, гәүдә өчен хәрәкәтләрне эченә алган гимнастик күнегүләр күңелле, файдалы узсын өчен, аларны төрле җыр, такмаклар белән башкарырга мөмкин. Шигъри юллар белән яисә көй ярдәмендә (фортепьяно, аудиоязма, бубен) үткәрелә торган ял минутларын балалар бигрәк тә ярата.

Татар халык иҗатының иң борынгы жанрларыннан берсе булган санамышлар, нәниләрне санарга өйрәтү, катлаулы саннарны истә калдыру максатыннан тыш, йөгерешле, качышлы

һәм башка күмәк уеннарда уенны алып баручыны, әйдәүчене сайларга да мөмкинлек бирә. Бер үк вакытта санамышлар баланың зиһене, истә калдыру сәләте артуга да булышлык итә. Шуны истә тотып, китапта иң уңышлы дип тапкан санамышларны да туплап бирергә булдык.

Уен ул – сәламәтлек чыганагы. Тән сәламәтлеге белән бергә, баланың рухи яктан дөрес формалашуы иң беренче чиратта уеннар һәм аларның дөрес оештырылуына бәйле. Шуңа күрә балалар бакчаларында да, гаиләдә дә уеннарны дөрес итеп оештыруга җитди игътибар итәргә кирәк. Уеннар никадәр кызыклырак итеп оештырылса, аларның файдасы шулкадәр зуррак. Балаларга алар яратмаган уенны көчләп тагарга ярамый. Өлкәннәр барлык төр уеннарны да җанлы, кызыклы, тәэсирле итеп оештыра белергә тиешләр. Иң мөһиме – балаларны *уенга җыя, туплый белү*. Моның өчен балаларда уенга карата кызыксыну уятырга кирәк. Рәсемнәр, төрле уенчыклар күрсәтү, я булмаса алдан уенның эчтәлеген ача торган шигырь яки әкият сөйләү моңа зур булышлык итә. Шушы максаттан чыгып, әлеге бүлектә З. Салихова туплап биргән һәм С. Миңлекәй тарафыннан язылган шигырь үрнәкләре урын алды. Әлеге шигырьләрне «Әйләнә-тирә дөнья белән таныштыру» дәресләрендә, саф һавада табигатьне күзәтү вакытларында файдаланырга мөмкин.

«Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак» җыентыгы буыннар арасындагы бәйләнешне саклау, туган телгә, торган төбәккә, милләтеңә мәхәббәт тәрбияләүдә, янәшәдә яшәүче башка халыкларның гореф-гадәтләренә, йолаларына кызыксыну уятуда файдалы ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз.

# I БҮЛЕК

# Уйныйк,
# сөеник,
# көлик

Уйныйк, сөеник, көлик!
Дәртле, җанлы, без күңелле,
Безгә ямьле Җир йөзе,
Безгә карап елмая
Күкнең кояш, ай, йолдызы!
*(С. Миңлекәй)*



# ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР

## *2–3 яшьлек балалар өчен уеннар*

### Куяным

Тәрбияче балаларны зур түгәрәк ясарга чакыра. Түгәрәк уртасына зур уенчык куян утыртыла.

Тәрбияче җырлый, ә балалар җыр көенә төрле бию хәрәкәтләре ясыйлар, тәрбиячегә кушылып җырлыйлар:

Яшь куянчык шаян була,
Ул уйнарга ярата.
Күрегез, ничек ярата!
Күрегез, ничек ярата!

Я куяным, якын кил!
Матур итеп сикер син.
Менә ничек, менә ничек,
Менә ничек сикер син!

Билләреңә кулың куй,
Матур итеп бие син.
Менә ничек, менә ничек,
Менә ничек бие син!

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны уйнаганда, балалар хәрәкәтләрне тәрбияче белән бергә башкаралар.

• Уен өйрәнелеп беткәч, куян роленә кыюрак бер баланы билгеләргә мөмкин.

### Йонлач көчек

Балалар урындыкларда утырып торалар. Тәрбияче «йонлач көчек» була. Ул бүлмәнең бер читендә алга сузылган кулларына башын куеп утыра – «йоклый».

Балалар, түбәндәге текстны әйтә-әйтә, әкрен генә аның янына киләләр:

Әнә ята йонлач көчек,
Борынын сузган ул ничек?
Йоклаганга да ошый,
Әллә юриме мышный?
Уятыйк үзен – торсын!
Нәрсә булса да булсын!

Балалар, шигырьне әйтеп бетергәннән соң, көчекне сыйпыйлар, иркәлиләр. Кинәт көчек күзен ача, сикерә, өрә башлый. Балалар урыннарына таба йөгерәләр, көчек аларны куа. Тотылган баланы «көчек» итеп билгеләргә мөмкин.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Шигырьне әйтеп бетерми торып, балалар көчеккә кагылмыйлар.

• Балалар көчекне бераз сыйпаганнан соң гына, ул күзләрен ача, селкенә башлый.

• Уенны үзләштергәннән соң, көчекне балалар арасыннан сайларга мөмкин.

• Шигырьне алдан өйрәнергә кирәк.

## Куян

Балалар түгәрәкләнеп басып торалар. Бер бала «куян» итеп билгеләнә. Ул түгәрәкнең уртасында тора.

Барлык балалар тәрбияче белән бергә җырлыйлар һәм җырның эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар:

Ап-ак куян утыра,
Колагын селкеп тора,
Менә шулай, менә шулай
Колагын селкеп тора.

Аңа тик тору кыен,
Җылыта ул тәпиен,

Һоп, һоп, һоп, һоп,
Җылыта ул тәпиен.

Куян тик торса – туңа,
Сикергәли ул шуңа,
Һоп, һоп, һоп, һоп,
Сикергәли ул шуңа.

Җырның ахырында куян, ике аякта сикереп, түгәрәк буенча бара һәм берәр баланың алдына килеп туктый. Шул бала «куян» була.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Балалар белән текстны уенга кадәр алдан өйрәнергә кирәк.
- Тәрбияче балаларның сүзләрне дөрес әйтүләрен күзәтә.

## Мәче

Балаларның урындыкларын тезеп, түгәрәк ясала. Балалар – «тычканнар» – урындыкларның артларына качалар. Уртада, паласта, «мәче» утыра.

Тәрбияче җырлый:

Мич башында ялкау мәче
Мыр-мыр йоклый, берни белми.
Уяна да сузылгалый,
Битен юа, борылгалый.

Көн озын, төн килеп җитә,
Мәче торып ауга китә.
Ауга китә, тычкан куа,
Куа-куа барып тота.

Тәрбияче җырлаганда, мәче сузылгалый, битен юа. Җыр тәмамлануга, тычканнар, ояларыннан чыгып, төрле якка йөгерә башлыйлар. Мәче берсен тота. Тотылган тычкан «мәче» була, уен кабатлана.

## Тавыклар һәм әтәч

Балалар урындыклар өстенә менеп, чүгәләп яки гадәти рәвештә утыралар. Алар «тавыклар» булалар. Арадан бер малай «әтәч» итеп билгеләнә.

Тәрбияче түбәндәге шигырьне әйтә:

Әтәч сары итектән,
Йөри комлык өстеннән...
Як-ягына карана,
«Кик-ри-күк!» – дип кычкыра.

Бу вакытта әтәч, канатларын кага-кага, горур кыяфәттә бүлмә буйлап йөри. Тәрбияче сөйләп бетергәч, ул, туктап, түбәндәге сүзләрне әйтә:

Йоннарым җем-җем итә,
Тавышым еракка китә.
Кикрикүк!.. Кикрикүк!..
Кояш, мине ишетеп,
Йокыдан тора көлеп,
Кикрикүк, кикрикүк!
Уяныгыз хәзер үк!
Кикрикүк!.. Кикрикүк!..

Әтәч кычкырганнан соң, барлык тавыклар, сикереп төшеп, үзләренә җим эзләргә китәләр – бүлмә буйлап йөгереп йөриләр. Әтәч тә алар белән йөгерә. Тәрбиячеhistories «Ти-ти-ти!» дип чакыруына барысы да үз урыннарына әйләнеп кайталар. Аннан соң яңа «әтәч» сайлана, һәм уен яңадан башлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче балаларның уенын күзәтеп тора һәм тиешле урында аларны чакырып ала.

• «Тавыклар» белән «әтәчнең» «чүпләнеп» йөрүләрен бик озакка сузарга ярамый, бу – уенның сүлпәнәюенә, балаларның кызыксынулары кимүгә китерергә мөмкин.

## Кәҗә

Бу уен балаларны бүлмәдә үз урыннарын истә калдырырга, табарга, күзәтүчән, игътибарлы булырга өйрәтә.

Балаларның урындыклары бүлмәнең кара-каршы якларына куела. Балалар урындыкларда утырып торалар. Бер читтәрәк тәрбияче басып тора – ул кәҗә ролен үти.

Уен башлану белән, күңелле көй астында, балалар бүлмә буйлап йөри башлыйлар (җитәкләшеп яисә берәм-берәм генә). Берникадәр йөргәннән соң, тәрбияче җырлый башлый:

Балаларны куып килә,
Зур мөгезле бер кәҗә,
Сөт эчмәгән балаларны
Мөгезе белән ул сөзә.

Җырның соңгы сүзләрен әйтеп бетерүгә, кәҗә балаларны куа башлый, балалар, йөгерешеп, үз урыннарына качалар (урындыкларына барып утыралар).

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны көндезге йокыдан торганнан соң, бигрәк тә сөт эчәр алдыннан үткәрсәң күңелле була.

• Мөгезле кәҗәне гәүдәләндергәндә, хәрәкәтләр, мимика һәм тавыш белән образны тулырак итәргә, балаларга кәҗәне күз алдына китерергә ярдәм итү өчен тырышырга кирәк.

## Чебешле тавык

Тәрбияче – «тавык», ә балалар «чебиләр» булалар. Тавык урындыкта яки келәм өстендә утыра, чебиләр аның янына ук килеп утыралар.

Тавык йокымсырап, күзләрен йомып утырган арада, чебиләр әкрен генә төрле якларга йөгереп китәләр, җим эзләнеп йөриләр.

Тавык уяна, янында чебиләре юклыкны күрә дә аларны ча-

кыра башлый: «Кыт-кыт-кыт, барыгыз да минем яныма килегез!» – ди. Чебиләр әниләре янына йөгереп киләләр.

Уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• «Чебиләр» бүлмә буйлап йөриләр яки йөгерәләр.

• «Тавык» чакыргач та, «чебиләр» барысы да йөгереп килергә тиешләр.

• Әгәр уен бүлмәдә үткәрелсә, балаларга йөгерү өчен урынны билгеләргә кирәк.

## Җитез балалар

Балалар урындыкларда утырып торалар. Идәнгә куелган кәрзингә уртача зурлыктагы 5–6 туп салына. Балаларның бер өлеше (туп санына карап), утырган урыннарыннан торып, бер рәткә тезеләләр.

Тәрбияче: «Бер, ике, өч», – ди дә кәрзиндәге тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Балалар туплар артыннан йөгерәләр. Һәр бала бер тупны тотып, тәрбиячегә китереп бирә. Тәрбияче балаларны мактый. Туплар артыннан йөгергән балалар үз урыннарына килеп утыралар, ә алар урынына башка балалар чыга.

## Казлар

Балалар – «казлар» – бүлмәнең бер башына куелган урындыкларда утырып торалар. Бу – «Казлар өе». Тәрбиячелең: «Ка, ка, ка! Ак казларым, соры казларым, йөрергә чыгыгыз!» – диюенә, балалар барысы да бүлмә буйлап йөриләр. «Үлән чүпләгез!» – дигәч чүгәлиләр һәм, казлар кебек «үлән чүпләр». «Су эчегез!» – дигәч, барысы да баш һәм гәүдәләрен аз гына түбән ияләр, аннан соң югары күтәрәләр, башларын җиңелчә генә артка ташлыйлар. «Йөгерегез өйгә, соры бүре килә!» – дигәч, барысы да үз урыннарына йөгерәләр.

## Курчак белән куыш уены

Балалар бүлмә буйлап тезелгән урындыкларда утыралар. Тәрбияченең кулында курчак. Ул, курчакны алга чыгарып: «Курчак йөгереп китте, Динә белән Ренат, тотыгыз!» – дип йөгерә башлый. Исемнәре әйтелгән балалар тәрбияче артыннан йөгереп китәләр. Бераз йөгергәч, тәрбияче аларга курчакны тоттыра. «Динә белән Ренат куып җиттеләр, курчакны тоттылар», – ди. Ике бала курчакны ике кулыннан тотып, балалар каршына алып киләләр. Уен яңадан башлана.

Курчакны кууда барлык бала катнашкач, уен тәмамлана. Тәрбияче: «Инде курчак ял итә, бүлмәгә кереп китә (яки «комга уйнарга китә», яки «аш ашарга китә»)», – дип, уенны йомгаклый.

Бу уенны аю баласы, эт һ. б. шундый йомшак уенчыклар белән дә үткәрергә мөмкин.

## Кояш һәм яңгыр

Бүлмәнең бер читендә ярымтүгәрәк рәвешендә урындыклар – «өйләр» урнаштырыла. Алар артлары белән бүлмәнең уртасына каратылып, бер-берсеннән берникадәр ара калдырылып куела. Балалар да, тәрбияче дә (тәрбиячегә зур урындык куела) – һәркем үз «өе»нең эчендә (урындыкның алгы ягында) чүгәләп утыралар. Барысы да «тәрәзә»дән (урындык аркасындагы уемтыктан) карыйлар, «урам»ны күзәтәләр.

Тәрбияче, «тәрәзә»дән карап: «Бүген һава ничек яхшы!» – ди. Ул бүлмәнең уртасына чыга һәм барлык балаларны уйнарга чакыра. Балалар йөгерешеп «өй»ләреннән чыгалар һәм, куллары белән тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. (Уенның эчтәлегенә бәйләнешле берәр җыр җырларга да мөмкин.)

Тәрбияче кинәт: «Карагыз әле, яңгыр килә, тизрәк өйгә!» – ди. Барысы да үз урыннарына йөгерәләр.

Тәрбияче: «Өй түбәсендә яңгыр ничек шыбырдый, тыңлыйк әле», – ди һәм шулвакытта, бармак очлары белән урындык ар-

касына сугып, яңгыр тамчылары төшкән тавыш чыгара. Яңгыр тамчылары тавышы башта көчлерәк була, соңыннан әкренәя бара һәм бөтенләй туктый.

Тәрбияче: «Урамда яңгыр туктадымы икән? Хәзер чыгып карыйм, аннан соң сезне чакырырмын», – дип, «өе»ннән чыга. Ул, башын югары күтәреп, һавага карый һәм: «Кояш чыкты – яңгыр яумый. Йөрергә чыгыгыз!» – дип, балаларны уенга чакыра. Балалар барысы да, йөгерешеп, урамга чыгалар, түгәрәккә тезелеп уйныйлар, бииләр. Бераз вакыттан соң кинәт «Яңгыр килә!» дигән хәбәр ишетелә, барысы да кабат үз урыннарына йөгерәләр.

Шул рәвештә уенны берничә тапкыр кабатларга мөмкин.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Бу уенны бина эчендә дә, уен мәйданчыгында да үткәрергә була. Урындыклар урынына «өй»ләрне җиргә түгәрәк белән сызып билгеләргә мөмкин.

## Кем тупны тизрәк китерә?

Уен өчен төрле төстәге туплар һәм шул төсләрдәге тартмалар кирәк була. Балалар бүлмәнең бер читенә тезелгән урындыкларда утыралар. Тәрбияче алар каршына туплар салынган берничә тартма куя һәм уенның эчтәлеген аңлата. «Туплар тәгәрәп киткәч, сез аларны, берәмләп китереп, тартмага салырга тиеш: туп кызыл төстә булса – кызыл тартмага, яшел булса – яшел тартмага» һ. б.

Тәрбияче: «Бер, ике, өч, йөгер!» – ди һәм балалар йөгерергә тиешле якка тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Туплар тәгәриләр, балалар алар артыннан йөгерәләр. Һәрберсе берәр тупны, алып килеп, шул туп төсендәге тартмага салалар. Соңыннан туплар бергә кушыла, һәм уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Туплар салу өчен билгеләнгән тартмаларны балалар йөгерә торган урыннан бераз читкәрәк, бер рәткә тезеп куярга

кирәк. Тәрбияче тартма янында балаларның тупларны дөрес салу-салмауларын тикшереп тора. Һәрбер бала бер генә туп алырга, туплар саны балалар санына туры килергә тиеш. Төркемдә балалар саны күп булганда, уенчыларны берничә төркемчәгә бүлеп (5–6 бала белән), чиратлашып уйнарга мөмкин.

• Балалар бары тик тәрбияче сигналыннан соң гына йөгерергә тиешләр.

• Йөгергәннән соң, балаларга бераз утырып ял итәргә мөмкинлек бирергә, уенны кабатлауны ашыктырмаска кирәк.

## Поезд

Балалар бер-бер артлы тезелеп басалар. Алар – «вагоннар», ә алда басып торучы тәрбияче «паровоз» була. Паровоз гудок биргәч, поезд кузгалып китә. Бара торгач, тизлеген арттыра. Станциягә (алдан билгеләнгән урынга) якынлашканда, поезд барышын әкренәйтә, аннан соң бөтенләй туктала. Бераздан соң поезд гудок бирә һәм яңадан кузгалып китә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны бераз катлауландырып, 3–4 яшьлекләр белән дә уйнарга мөмкин.

• Паровоз ролен башта тәрбияче үзе үти, тора-бара бу рольне балалар үзләре дә үти алалар.

• Уен барышында балаларны (вагоннарны) бер-берсенә тотындырмау яхшырак, чөнки тотынышып йөрү балаларның хәрәкәтләнүләренә комачаулый.

• 3–4 яшьлек нәниләр белән уйнаганда, бу уенга төрле өстәмәләр кертергә мөмкин. Мәсәлән, берәр бала «светофор» була, аңа кызыл һәм яшел төстәге ике флаг бирелә. Кызыл флагны күтәрү белән, поезд туктый; яшел флагны күтәргәч, баруын дәвам итә (бу рольне балалар чиратлап үтиләр).

• Поезд «күпер» буйлап (идәнгә җәелгән 15–20 см киңлектәге палас яки картон өстеннән яки җиргә сызылган

ике сызык арасыннан) барырга мөмкин. Әгәр вагоннар юлдан (рельстан) чыксалар, ягъни берәрсе сызыктан читкә басса, поезд туктала, вагон «төзәтергә» җибәрелә.

• Уенны түбәндәгечә тәмамларга мөмкин: поезд, пассажирлар утыртып, берәр «шәһәргә» килә. Барысы да «балалар бакчасына» (алдан билгеләнгән урынга) кунакка китәләр һәм анда, утырып, бераз ял итәләр.

• Тора-бара уенга түбәндәге вариантларны кертергә мөмкин: поезд белән урманга, дачага һ. б. җирләргә баралар. Мәсәлән, балалар, поездга утырып, урманга җиләк яки чәчәк җыярга баралар (бер-бер артлы тезелешеп яки йөгерешеп баралар). Берникадәр барганнан соң, поезд туктый, бөтен пассажирлар җиләкләр, чәчәкләр җыялар. Аннан соң поезд белән өйгә кайталар.

## *3–4 яшьлек балалар өчен уеннар*

### Кара урманда, аю янында

Мәйданчыкның (бүлмәнең) бер читендә «аю өне» – җиргә сызып ясалган түгәрәк билгеләнә. Балалар арасыннан берсе «аю» итеп сайлана. Ул үз өнендә утыра. Барлык башка балалар, гөмбә, җиләк җыйган булып кыланып, әкрен генә аю янына баралар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Аю бабай урманында
Җиләк, гөмбәләр җыям,
Аю бабай күрмәсен,
Без йөргәнне сизмәсен!

Әлегә кадәр йокымсыраган кыяфәттә утырган аю бу сүзләрдән соң кыймылдый, киерелә башлый һәм өненнән (түгәрәктән) чыга. Балалар төрле якка йөгерәшәләр, аю аларны куа. Тотылган бала аю ролен үти.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Балаларга уйнаганда «аюдан» курыкмаска, «аю» куа башлагач кына йөгерергә кирәклеген аңлатырга кирәк.

## Куык

Уйнаучылар, тыгыз итеп тезелеп, кечкенә түгәрәк ясыйлар. Кулга-кул тотынышып, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, артка таба чигенәләр, әкрен генә түгәрәкне киңәйтәләр:

Өрел, куык, зур булып,
Тик шартлый күрмә, тулып;
Һаман да син бул матур –
Күпереп, кабарып тор!

Зур, киң түгәрәк ясала. Тәрбияче: «Куык шартлады!» – дигәннән соң, балалар, кулларын ычкындырып, тиз генә кул чабалар (куык шартлаган тавыш чыгаралар) һәм «Һоп!» дип чүгәлиләр.

Куык яңадан өрелә, уен кабатлана.

## Тавыклар яшелчә бакчасында

Җирдән 50 см биеклектә ике агач арасына бау тарттырыла – «бакча» чиге билгеләнә. Балалар «тавыклар» булалар. Тәрбияче, бакча караучысы булып, бакчада утыра.

Каравылчы йокыга киткәч, тавыклар бау астыннан бакчага керәләр. Бакча караучысы уяна да, «Көш-көш!» дип, тавыкларны куа, тавыклар йөгерешеп китәләр. Аннан соң уен яңадан кабатлана.

## Кем тизрәк?

Уен өчен балалар санынча кызыл һәм зәңгәр төстәге флаглар кирәк. Балалар, кулларына флаглар тотып, музыка яки бубен шалтыравы астында төрле юнәлештә йөриләр. Тәр-

бияченең «Тукта!» дигән сүзенә балалар туктап калалар. Тәрбияче, бер читкә китеп: «Бер, ике, өч, барыгыз да монда күч!» – ди һәм кызыл (яки зәңгәр) флагны күтәрә. Кызыл флаг тоткан балалар тәрбияче янына җыелалар.

Уен 2–3 тапкыр кабатлана.

## Мәче һәм тычканнар

Тәрбияче – «мәче», балалар «тычканнар» булалар. Тычканнар ояларында – арты белән әйләндереп куелган урындыкларда утыралар. Мәче мәйданчык буйлап тычканнар эзләп йөри, ә тычканнар тын гына үзләренең ояларында утыралар. Тычканнарны тапмагач, мәче үзенең оясына кереп йоклый. Тычканнар, мәче йокыга киткәч кенә, ояларыннан йөгерешеп чыгалар һәм тәмле ашамлык эзли башлыйлар, йөгерешәләр. Мәче уяна. Ул, мияулап, бер-бер артлы тычканнарны тота (кулы белән орына) башлый. Тычканнар үз ояларына кереп калырга тырышалар, тотылган тычканнарны мәче үз өенә алып китә.

Уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Уенны беренче тапкыр уйнаганда, тәрбияче балалар тирәсендә йөреп, аларга йөгереп качарга мөмкинлек бирә. Балалар тиз генә йөгерергә, үз урыннарын тиз генә табарга өйрәнәләр. Уенны кабатлап уйнаганда, мәчегә тычканнар тотарга булышучы кечкенә «мәче баласы» («песи») сайларга да мөмкин.
- Тычканнар мәченең «Мияу!» дигән сүзеннән соң гына йөгерә башлыйлар.

## Тигез юл буйлап

Уен бер-бер артлы тезелеп бару, ике аякта сикерү хәрәкәтләрен камилләштерергә ярдәм итә.

Балалар кара-каршы тезелгән урындыкларда ял итеп уты-

ралар. Тәрбияче аларга «сәяхәткә чыгарга» тәкъдим ясый. Балалар урыннарыннан торалар, бер-бер артлы тезелеп, тәрбияче артыннан баралар. Тәрбияче: «Тигез юлдан барабыз», – дигәндә, балалар колоннада гади адым белән атлап баралар, «Ташлык җирдән барабыз», – дигәндә, таштан ташка сикергән кебек, ике аякта сикерәләр. Шулай аралаштырып, уенны 2–3 тапкыр кабатлагач, тәрбияче: «Барыбыз да чокырга төштек, бух!» – ди, барысы да чүгәлиләр. «Чокырдан чыктык», – диюгә күтәреләләр. Уен кабатлана. Ахырдан тәрбияче: «Менә безнең өебез, өйгә кереп утырыгыз», – дигәч, балалар үз урыннарына йөгерәләр.

## Төрле төстәге өйләр

Уен балаларга төсләрне аерырга, төсләрнең исемнәрен истә калдырырга ярдәм итә, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәтә.

Уен үткәрелә торган урынның дүрт почмагына зәңгәр, кызыл, сары, яшел төсләрдәге кечкенә флаглар кадап куела. Һәр балага шундый ук төстәге бер тасма бирелә.

Балалар бер-бер артлы тезелешеп, билгеләнгән чиктән чыкмыйча, мәйданчык буйлап йөриләр. Тәрбияче сигналы буенча (мәсәлән, ул кул чапкач), һәркайсы үз «өенә» (кызыл тасмалы бала кызыл флаг янына һ. б.) йөгерә.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Балаларның ашыкмыйча, әкрен генә йөрүләрен күзәтергә кирәк. Флаг урынына төрле төстәге туп яки йомшак уенчык куярга мөмкин. Тәрбияченең кул чабуын бубен тавышы белән алыштырырга була.

## Куян

Балалар, түгәрәк ясап, идәнгә утыралар. Бер бала «куян» итеп билгеләнә, ул уртада басып тора.

Утырган балалар тәрбияче белән бергә шигырь әйтәләр:

Соры куян юына,
Кунакка дип җыена.
Юды колагын,
Юды борынын,
Корытып, корытып
Сөртте барын.

Түгәрәк уртасындагы «куян» шигырьдәге сүзләрне хәрәкәтләр белән күрсәтә (куянның ничек борынын, колагын, койрыгын юуын тасвирлый). Шигырь тәмам булганнан соң, ул, ике аяклап сикереп, түгәрәктәге балаларның берсе янына килә – «кунакка бара». Сайланган бала аның урынына чыгып баса, һәм уен яңадан башлана.

## Флагны тап

Уен үлән үскән мәйданчыкта яисә болында уйнала. Тәрбияче үлән арасына флаглар (яки уенчыклар) куя (флаглар балалар санынча булырга тиеш). Балалар күзләрен йомып утырып торалар. Тәрбияченең «Булды!» дигән сигналына балалар күзләрен ачалар һәм флагларны эзләргә китәләр. Флагны кем алдан тапса, шул урындыкка (яки алдан билгеләнгән махсус урынга) беренче булып утыра, аның артыннан флагны табучы башка балалар килеп утыралар. Барлык флаглар табылып беткәннән соң, балалар тезелешеп басалар. Флагны башкалардан элек табучы бала колоннага беренче булып баса. Ул җиңгән дип санала.

*Уенның варианты.* Флагларны кар өемнәренә яки куак артларына яшерергә мөмкин. Балалар күзләрен йомалар, тәрбияченең «Булды!» дигән сигналыннан соң күзләрен ачалар һәм флагларны эзлиләр. Флагны тапкан балалар тәрбияче янына йөгереп киләләр. Бөтен флаглар табылып беткәч, балалар флагларны тотып бииләр. Аннан соң уен яңадан башлана.

## Тупны тәгәрәтә бел

Балалар ярымтүгәрәк булып, идәндәге паласта аякларын сузып утыралар. Тәрбияче, берникадәр ара калдырып, аларга каршы утыра. Ул кечкенә резин тупны (тупның диаметры 20–25 см булырга тиеш) чират белән һәр баланың каршысына тәгәрәтә, ә балалар тупны, тотып алып, кире тәрбиячегә таба тәгәрәтергә тиешләр.

## Тере туплар

Тәрбияче бер зур туп алып, аны җиргә бәреп сикертеп уйный һәм түбәндәге шигырьне әйтә:

Минем тавышлы шат тубым,
Син сикердең, мин кудым.
Син кызыл, сары, күгелҗем,
Мин артыңнан йөгердем.

Аннан соң тәрбияче балаларны үз янына чакыра һәм аларга туп кебек сикерергә куша. Тәрбияче шигырьне кабатлый, балалар сикерәләр, бу вакытта тәрбияче балаларның башлары өстендә кулы белән тупны җиргә бәргән кебек хәрәкәт ясый. Тәрбияченең: «Туп тәгәрәп китте, хәзер аны куып җитәм», – дип әйтүенә, барлык балалар мәйданчык буйлап йөгереп китәләр, ә тәрбияче аларны куа.

Уенны кабатлаганда, турыдан-туры балаларның сикерүләреннән башларга мөмкин.

## Кошлар

Балаларның урындыклары бүлмәнең төрле урыннарына куела (2–3 урындыкны берләштереп куярга да мөмкин). Болар – «кош оялары». Оядагы «кошлар» саны оя итеп ясалган урындыклар санына карап билгеләнә. Мәсәлән, оя өч урындыктан ясалган булса, бу ояда өч кош урнаша. Кошлар (балалар) оя-

ларында утыралар. Тәрбияче: «Кошлар очтылар!» – диюгә, кошлар ояларыннан очып чыгалар һәм бүлмәнең (мәйданчыкның) төрле урыннарында очып йөриләр. Тәрбияченең «Кошлар ояларында!» дигән сигналыннан соң ояларына кайталар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Балалар «оя»га иркенләп керә алсыннар өчен, урындык араларында бушлык иркен, зур булырга тиеш.

• Кошларның очу, ял итү, йоклау вакытларын музыка астында үткәрергә мөмкин.

• Урамда уйнаган очракта, кош ояларын җиргә сызык сызып та ясарга була.

## Кыңгырауны тот!

Ике агач арасына, ике очын бәйләп, бау сузыла. Бауның биеклеге бала кулын югары күтәргәндә аңа аз гына җитми калырлык булырга тиеш. Бауга кечкенә генә ике кыңгырау элеп куела.

Ике бала бау янына килә. Алар, сикереп, куллары белән кыңгырауны тотарга тырышалар. Уенда барлык балалар да катнаша.

Уенны бүлмәдә дә уйнарга мөмкин.

## Кунакны таны!

Балалар ярымтүгәрәк формасында тезелгән урындыкларда утыралар. Алардан берникадәр ераклыкта урта бер җиргә кечкенә кыңгырау тагылган бау сузыла. Бау балалар, сикереп, кулларын тидерерлек биеклектә булырга тиеш. Тәрбияче 2–3 баланы чакырып ала һәм аларны «кунаклар» итеп билгели. Алар баудан ераккарак барып басалар. Тәрбияче башка балалар уртасына барып утыра, һәм уен башлана.

Тәрбияче сигналы буенча, билгеләнгән балалардан берсе бау янына йөгереп килә һәм, аяк өстендә сикереп, кыңгырауны

өч тапкыр шалтырата – кунак килә. Шулвакытта балалар һәм тәрбияче: «Кайсы йөри анда?» – дип сорыйлар. Бала: «Һау, һау, һау!» – дип җавап бирә. Балалар: «Бу көчек икән», – диләр. «Көчек» урынына барып утыра. Аннан соң икенче бала, йөгереп килеп, кыңгырауны шалтырата, һәм «Тагын кайсы йөри?» дигән сорауга ул: «Мияу, мияу, мияу», – дип җавап бирә һ. б.

Уен кабатланганда, 2–3 яңа бала сайлана һәм алар тәрбияче белән бергә тавыш ярдәмендә үзләренә таныш булган төрле хайваннарны гәүдәләндерәләр.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Кунакка килергә билгеләнгән балаларның буйларын исәпкә алып, кыңгырауны я түбәнрәк төшерергә, я югарырак күтәрергә туры килә.

• Кунаклар, ике аякта сикереп, кыңгырауга өч тапкыр кагылырга тиешләр.

• Кечкенә балаларга яхшы таныш булган һәм тавышларына охшатып гәүдәләндерә алырлык хайваннарны гына билгеләргә кирәк (кәҗә, сыер, эт, песи, сарык, әтәч, тавык, каз һ. б.).

• Кунакларның чиратлап килүен тәрбияче үзе билгели.

## Мәче һәм мәче балалары

Балалар парлашып басалар. Аларның берсе – «мәче», икенчесе «мәче баласы» була. Һәр мәче үзенең баласы белән аерым өйгә урнаша (бер-берләреннән берникадәр ара калдырып басалар).

Әни мәчеләр йокыга китә (күзләрен йомалар). Шулвакытта мәче балалары, өйләреннән чыгып, бүлмә буйлап йөгерә, сикеренә, уйный башлыйлар. Тәрбияче сигнал бирүгә, мәчеләр уяналар һәм мияулый башлыйлар. Мәче балалары үз әниләре янына кайталар.

Балалар рольләрне алмашалар, уен дәвам итә.

## Светофор

Балалар мәйданчыкта (бүлмәдә) ирекле рәвештә басып торалар. Алар – «автомобильләр», «автобуслар», «велосипедлар», «трамвайлар» һ. б. Мәйданчыкның уртасында, кулына яшел һәм кызыл төстәге флаглар тотып, «автоинспекция хезмәткәре» – тәрбияче басып тора. Автоинспекция хезмәткәре флагларын күтәрми торып, транспорт чаралары урыннарыннан кузгалырга тиеш түгелләр. Ул яшел флагны күтәрү белән, автомобильләр һ. б. мәйданчыкта үзләре теләгән якка, үзләре теләгән тизлек белән бер-берсенә бәрелми йөри башлыйлар. Әгәр автоинспекция хезмәткәре кызыл флаг күтәрсә, шулвакыт бөтенесе туктарга, урыннарыннан кузгалмаска тиешләр. Яшел флагны күтәргәнче, балалар шушы хәлдә басып торалар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Флаглар урынына бер ягы яшел, икенче ягы кызыл төстәге түгәрәк булса да ярый.

• Уен өчен төрле атрибутлар (рульләр, баулар, таяклар, шалтыравыклар һ. б.) бирелсә, уен тагын да күңеллерәк үтә.

• Бу уен балаларны урам кагыйдәләре, транспорт төрләре, кайбер яңа төшенчәләр (депо, автоинспекция хезмәткәре һ. б.) белән таныштыра, тәртипкә өйрәтә.

## Аюны кем чакырды?

Балалар ярымтүгәрәк рәвешендә куелган урындыкларда утыралар. Алардан берникадәр ераклыкта (балаларга аркасы белән) тез өстенә уенчык аю куйган бер бала утыра. Ул «аю» була.

Тәрбияче балаларның берсенә «Аю!» дип эндәшергә куша. Шуннан соң аю тотып утырган бала үзен чакырган («Аю!» дип эндәшкән) баланы эзләргә китә. Ул, кулына аюны күтәреп, барлык балалар тирәсеннән әйләнеп чыга: «аю» барысын да «иснәп» караган була һәм үзен чакырган бала алдына (әгәр таныса) туктый, баланың тезенә тәпиләрен куя, тавышын чыга-

ра. Әгәр «аю» эндәшкән баланы дөрес тапса, табылган бала, уенчык аюны алып, урындыкка утыра.

Уен дәвам итә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уен өчен уенчык сайлаганда, «тавышлы» йомшак аюга өстенлек бирергә кирәк.

• «Аю» баланы тавышы буенча беренче тапкырда ук таныса, тәрбияче аны билгеләп (мактап) китәргә тиеш.

## Сез яңгырдан куркасызмы?

Уйнаучылар өчен, мәйданчыкның ике ягына кара-каршы сызык сызып, ике өй ясала. Уенда катнашучы барлык балалар бу өйләрнең берсенә урнашалар. Тәрбияче яңгыр ролен башкара. Ул, уен үткәрелә торган урынның урта бер җиренә басып, балалардан: «Сез яңгырдан куркасызмы?» – дип сорый. Балалар: «Курыкмыйбыз», – дип җавап бирәләр һәм «яңгыр»га таба йөгерә башлыйлар. Алар каршыдагы өйгә керергә тырышалар. «Яңгыр» йөгерүчеләрне куа, тотарга тырыша. Балалар өйгә кереп беткәч, уен кабатлана. Тотылмаган балалар арасыннан икенче «яңгыр» сайларга мөмкин.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Өйдән чыгып йөгерү «Юк, курыкмыйбыз» дигәч кенә, ә йөгерүчеләрне тоту ике өй арасындагы чиктә генә булырга мөмкин.

## Кем тизрәк?

Балаларга кызыл һәм зәңгәр төстәге тасмалар бирелә. Алар тәрбияченең җырлавы яки музыка астында мәйданчык буйлап, үзләре теләгән якка йөгерешеп йөриләр.

Тәрбияченең «Тукта!» дигән сигналына барлык балалар да туктый. Тәрбияче исә бер читкә йөгереп китә дә: «Бер, ике, өч, хәзер монда күч!» – дип, кулын алга суза. Аның бер кулында

кызыл, икенче кулында зәңгәр флаг була. Кызыл тасмалы балалар кызыл флаг каршына, зәңгәр тасмалы балалар зәңгәр флаг каршына килеп басалар. Тәрбияче кайсы колоннаның тизрәк тезелгәнен әйтә.

*Уенга күрсәтмә*

• Тәрбияче җыелу урынын алмаштырып тора. Соңрак флагларны да алмаштырырга, ягъни бер тапкыр уң кулына кызыл флаг, сул кулына зәңгәр флаг тотса, икенче тапкыр уң кулына зәңгәр флаг, сул кулына кызыл флаг тотарга мөмкин.

## Тигез юл буйлап

Тәрбияче балаларга саф һавага чыгарга тәкъдим итә. Балалар, бер-бер артлы тезелеп, тәрбияче артыннан баралар һәм түбәндәге сүзләрне сөйлиләр:

Нәниләр бара
Тигез юл буйлап,
Тигез юл буйлап,
Ашыкмый атлап. *(Атлап баралар,)*
Ташлар өстеннән,
Ташлар өстеннән *(ике аяклап сикереп баралар,)*
Барган чагында,
Чокырга төштек, *(чүгәлиләр,)*
Чокырга төштек – бух...
Чокырдан чыктык – уф! *(торалар.)*

Аннан соң түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Тигез юл буйлап
Кайткан чагында,
Аяклар арыды, *(Арыган кыяфәт чыгарып,*
Аяклар арыды... *әкрен генә баралар.)*

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уен барышында балалар бер-берсеннән калмый бергә барырга, хәрәкәтләрне сүзләргә туры китереп ясарга, сүзләрне

әйтеп бетерүгә, үз урыннарына – урындыкларга барып утырырга тиешләр.

• Башта хәрәкәтләрне балалар белән бергә тәрбияче үзе дә эшли. Балалар уенның кагыйдәләрен һәм хәрәкәтләрне үзләштергәннән соң, тәрбиячегә, хәрәкәтләрне эшләмичә, сүзләрне генә әйтергә мөмкин.

## Очкычлар

Бүлмәнең бер читендә урындыклар тезеп куела. Бу – «аэродром». Балалар – «очучылар». Алар аэродром эчендә очарга сигнал булганны көтеп утыралар.

– Очучылар, сез очарга әзерме? – ди җитәкче ролен башкаручы тәрбияче.

Балалар урыннарыннан торалар һәм:

– Әзер! – дип җавап бирәләр.

– Моторны борыгыз! – ди җитәкче.

Балалар, «ррр... ррр...» дип, мотор борган шикелле итеп, кулларын тиз-тиз әйләндерәләр.

Җитәкче «Очарга!» дип боерык бирә һәм яшел флаг күтәрә. Очкычлар, бүлмә буйлап, төрле якларга очалар. Берникадәр вакыттан соң тәрбияче кызыл флаг күтәрә һәм:

– Очучылар, кире кайтыгыз! – ди.

Барысы ды аэродромга очып кайталар һәм кире урыннарына утыралар.

Балалар бераз ял иткәннән соң, яңадан очарга сигнал бирелә, һәм уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Балалар, яшел флагны күтәргәч, аэродромнан очып китәргә, ә кызыл флагны күтәргәч, әйләнеп кайтырга кирәклекне истә тотарга тиешләр.

• Хәрәкәтләр сигнал булганнан соң гына башкарылырга тиеш.

• Флаг күтәреп сигнал бирү урынына «радио» аркылы

чакырырга мөмкин. («Тыңлагыз, тыңлагыз! Очучылар, кайтыгыз!»)

• Беркадәр вакыттан соң тәрбияче үзенә ярдәмче итеп балаларның берсен сайлый, һәм бу бала, тәрбияче булышлыгы белән флагларны алып, аның белән бергә сигнал бирә. Бу – балаларны, тәрбиячедән башка, үзлекләреннән уйнарга өйрәтү максаты белән эшләнә.

## Аю һәм бал кортлары

Уен мәйданчыгындагы комлык (гөмбә) бал кортлары өе – «умарта» итеп файдаланыла. Бу ояга «бал кортлары» – балалар урнаша. Аю ролен үтәүче тәрбияче агач яки куак артына яшеренә.

Бал кортлары, бал җыяр өчен, ояларыннан чыгып, мәйданчыкта жуылдый-жуылдый очалар. Кинәт аю килеп чыга. Ул, бер яктан икенче якка чайкала-чайкала, салмак кына адымнар белән мәйданчыкта йөри, үзе иснәнә. Бал кортлары, аю килеп чыгу белән, ояларына качалар, ә аю, оя янына килеп, бал алырга тырыша. Кортлар жуылдый башлыйлар һәм аюны чагалар (тәрбияче ояга сузыла башлагач, балалар аның кулына тотынырга тырышалар). Аю, чыннан да, корт чаккан шикелле, тәпиләре (кулы) белән аларны куган була һәм качып китә. Кортлар яңадан бал җыярга китәләр. Уен дәвам итә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Бал кортлары, аю күренүгә, умарталарга очарга, ә ул киткәч, бал җыю өчен очарга тиешләр. Вакытка карап, тәрбияче уенның өлешләрен үзе көйли.

• Уенны берничә тапкыр кабатлап уйнарга мөмкин.

## Туп

Уен кыш көне җылынырга теләүче балалар белән мәйданчыкта үткәрелә.

Бер бала, туп сикерүенә охшатып, бер урында ике аякта сикерә, ә тәрбияче, баланың баш түбәсе өстендә уч төбе белән (туп сикертеп уйнаган кебек) бер аска, бер өскә хәрәкәтләр ясап, түбәндәге шигырьне әйтә:

Сары, кызыл, күгелҗем,
Минем матур тупкаем,
Сине куып җитә алмыйм,
Ничек куып тотаем?

Бу сүзләрдән соң туп (бала) тәгәрәп китә, ә тәрбияче аны куа.

Әгәр уенда берничә бала катнашса, алар да туп тирәсенә басалар һәм аның белән бергә сикерәләр. Туп булып уйнаган бала йөгереп киткәч, балалар аны куалар. Тупны тота алган бала «туп» була һәм түгәрәкнең уртасына чыга.

Уен кабатлана.

## Туп белән үткәрелә торган уеннар

**1 нче уен**

Балалар ярымтүгәрәк тәртибендә басып торалар, ә тәрбияче аларга тупны чиратлап ыргыта. Әгәр бала тупны тотып алса, ул чүгәли һәм тупны киредән тәрбиячегә тәгәрәтә. Әгәр ул тупны тотып ала алмаса, туп артыннан йөгереп барып, аны тәрбиячегә китереп бирә.

**2 нче уен**

Бу уен беренче уен кебек үткәрелә, ләкин балалар тупны тәгәрәтмиләр, бәлки тәрбиячегә ыргыталар. Балалар кулыннан туп ике тапкыр үткәннән соң, тәрбияче тупны ераккарак ыргыта, ә балалар аны барып алалар. Аннан соң балалар тупны тәрбиячегә бирәләр, уен яңадан кабатлана.

**3 нче уен**

Балалар түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына тартма куела. Балалар зур тупны тартмага ыргыталар. Башта балалар

тупны тартмадан 2 адым ераклыктан ыргыталар, соңыннан ара 3–4 адымга кадәр ерагайтыла.

**4 нче уен**

Балалар түгәрәккә басалар. Тәрбияче, түгәрәкнең уртасында торып, зур тупны һәр балага чират белән ыргыта, ә бала аны тәрбиячегә кире ыргыта. Ыргытуны 1,5 м ераклыктан алып азазлап 2–2,5 м га кадәр җиткерәләр.

## *4–5 яшьлек балалар өчен уеннар*

### Тота бел

Уен тиз йөгерергә, җитезлеккә өйрәтә.

Балалар тәрбияче белән бергә түгәрәкләнеп тезеләләр һәм бер-берсенең кулларына тотынышалар. Түгәрәк уртасына әйдәүче баса. Балалар түгәрәк буенча уңга яки сулга таба әйләнеп йөриләр һәм түбәндәге сүзләрне көйләп әйтәләр:

Без, балалар,
Яратабыз уйнарга,
Йөгерергә, җырларга.
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга,
Тот!

Соңгы «Тот!» дигән сүзне әйтү белән, балалар мәйданчык (бүлмә) буйлап йөгерә башлыйлар, ә әйдәүче аларны куып тотарга тырыша.

Тотылган балалар вакытлыча уеннан чыгалар. Әйдәүче 3–5 баланы тоткач, уен тәмамлана. Уйнаучылар арасыннан яңа әйдәүче сайлана (тотылган балалар сайлана алмый). Яңа уенга үткән уенда тотылган балалар барысы да яңадан катнаша. Уен 3–5 тапкыр кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенның әйдәүче ничә баланы тотканга кадәр дәвам итүе алдан ук килешенергә тиеш.

## Тизрәк урыныңа бар

Уен балаларны урында ориентлашырга, ритм хисен тоярга, тигез хәрәкәтләр ясарга өйрәтә.

Тәрбияче балаларны колоннага тезә, аннан соң алга басып, үзе балалар белән бергә атлап йөри башлый. Балалар тигез атлап йөрсеннәр өчен, ул башта кул чаба һәм шул ук вакытта: «Бер-ике, бер-ике, бергә!» – дип әйтә, аннан соң, балаларның атлавына туры китереп, аларга таныш булган нинди дә булса бер җыр җырлый башлый. Җырның бер куплетын яки бөтенесен җырлап бетергәч, тәрбияче кисәктән генә: «Тизрәк урыныңа бар!» – дип кычкыра, һәм балалар барысы да урыннарына йөгерәләр. Тәрбияче башкалардан алда йөгерүче балаларны үз урынына билгеләп куя.

## Көтүче

Бүлмәнең яки мәйданчыкның бер почмагында «абзар» – хайваннар яши торган урын, ә икенче почмагында «көтүлек» билгеләнә. Балалар «йорт хайваннары» («сыер», «кәҗә», «сарык») була. «Көтүче» (тәрбияче) уртага чыга һәм сөйли:

Көтүче, курай тотып,
Яшел болында йөри.
Көтүче яхшы уйный,
Матур көйләрне көйли.

Бу сүзләрне әйткәч, курайда уйный башлый (яки «ту-ру-ру» дип көйләп, курайда уйнаган хәрәкәтләр ясый). Курай тавышына сыерлар, сарыклар, кәҗәләр чыгалар. Көтүче аларны көтүгә куа:

Ягез, ягез, хайваннарым,
Барыйк уйсу җирләргә,
Хәтфә төсле кырларга,
Яшел чирәм ашарга.

Балалар таралышып йөриләр. Көтүче кайту сигналын уйнагач, барысы да, йөгерешеп, көтүче янына киләләр. Беренче килгән бала, иң алга басып, көтүне абзарга алып кайта.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Балалар көтүче янына курай тавышын ишеткәч кенә килергә тиешләр.

• Мөмкинлек булса, уенда курай, быргы, флейта яки башка өрмә музыка коралын файдаланырга мөмкин.

*Уенның 2 нче варианты.* Көтүче ролен арада зуррак бала үти. Сүзләрне тәрбияче әйтә, ә курайда «көтүче» булган бала уйный.

Тәрбияче сөйли:

Иртән иртүк көтүче
Уйный: «ту-ту-ру-ру-ру».

Аңа каршы сыерлар «җавап бирәләр»:

Му-му-му-му-му-му,
Әйдә, көтүеңне ку
Матур уйсу җирләргә,
Хәтфә төсле кырларга,
Яшел чирәм ашарга.

## Куяннар

Балалар – «куяннар» – «тау итәгенә» җыелганнар (тау итәге урынына мәйданчыктагы тауны яки башка берәр биеклекне файдаланырга мөмкин).

Тәрбияче: «Җылыну өчен куяннар тәпиләрен селкиләр», – диюгә, балалар сикергәлиләр һәм тәпиләрен бер-берсенә бәрәләр. Бераз вакыттан тәрбияче әйтә:

Һава салкын, тын гына,
Басып тору туңдыра,
Җылыныр өчен тизрәк,
Сикерик күңеллерәк.

Шул сүзләрне ишетүгә, балалар тау итәгеннән йөгереп чыгалар һәм кулларын баш өстенә куеп, ике аяклап сикергәлиләр. Җылынып җиткәч, тәрбияченең хәбәр бирүе буенча, яңадан тау итәгенә кайталар. Теләгән балалар белән уен кабатлана.

## Бүре һәм көтү

Мәйданчыкта, уен өчен билгеләнгән урынның бер читенә сызык сызып, «көтүлек» билгеләнә. Икенче якка «бүре оясы» куела. «Көтүче», «бүре», «сыерлар», «сарыклар» билгеләнә. Көтүче (баштарак бу рольне тәрбияче үзе башкара) уен урынының уртасына килә дә түбәндәге сүзләрне әйтә:

Алды кулына быргысын
Көтүче: «ту-ру-ру-ру»;
Ә аңарга бер сыер
Каршы чыкты: «му-му-му».

Соңгы сүзләрне әйткәч, сыер (яки сыерлар), мөгрәп, уен үткәрелә торган урынның уртасына чыга. Шунда ук кәҗә һәм сарыклар да чыгалар. Көтүче түбәндәге сүзләр белән аларны көтүлеккә куа:

Син, сыер, кит урманга,
Төсле матур кырларга,
Тик кайтырсың кич белән,
Кич белән, күп сөт белән.

Соңгы сүзләрне әйтү белән, терлекләрнең барысы да төрлесе төрле якка таралышып китә, ә көтүченең «Бүре!» дигән сүзенә барлык терлекләр көтүче янына йөгерешәләр. Йөгереп килеп җитә алмаганнарны бүре тотып ала да үзенең оясына алып китә. Тотылган хайваннар саны 3–5 кә җиткәч, уен тәмам була. Яңа «бүре» сайланып, уен дәвам итә.

## Кая йөгерергә?

Һәр балага ике төстәге (кызыл һәм зәңгәр) флаглар таратыла. Уен мәйданчыгының ике почмагында сызыклар сызыла һәм һәрберсенә аерым төс билгеләнә – бер почмакка кызыл, икенчесенә зәңгәр төстәге берәр билге яки предмет (шар, туп, шакмак, йомшак уенчык һ. б.) куела. Балалар барысы да үзләренең флагларын, төсенә карап, ике «өй»нең берсенә илтеп куялар.

Тәрбияче балаларны бүлмәнең каршы ягында сызылган туры янына тезә. Аннан соң берәр төсне атый, һәм балалар үзләренең флаглары янына йөгерәләр. Алдан йөгереп җитеп, үзенең флагын, алып, югары күтәргән бала беренчелекне ала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Флаглар урынына төрле предметларны, мәсәлән, чәчәкләр, ташлар һ. б. ны файдаланырга мөмкин, ул вакытта тәрбияче «чәчәкләр» яки «ташлар» дип кычкыра.

• Балаларны, ике ян-якка кулларын сузарлык итеп, иркен урнаштырырга кирәк. Әгәр, урын тар булып, барлык балаларга тезелергә мөмкин булмаса, ул вакыт тезгәндә, балаларны ике төркемгә бүләргә кирәк.

• Бер төркем уйный, икенче төркем исә уйнаучыларны күзәтә һәм биремне беренче башкарган кешене билгели. Аннан соң төркемнәр алмашына, уен дәвам итә.

## Өрел, куык!

Балалар түгәрәккә тезелеп басалар. Башларын алга ия төшеп, берсен икенчесе өстенә куйган йодрыкларына һава өрәләр – «куык кабарталар». Башларын турайтып, эчләренә һава алалар да яңадан, иелеп, «ф-ф-ф» дип, «трубка» эченә һава тутыралар (2 тапкыр кабатлана). Һәр өргән саен, бер адым артка атлыйлар (куык кабара бара). Шул рәвештә бу күнегү 2–3 тапкыр кабатлана. Аннан соң, бер-берсенең кулларына тотынган хәлдә, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә артка чигенә барып, түгәрәкне киңәйтәләр:

Өрел, куык, зур булып,
Тик шартлый күрмә тулып;
Һаман да бул син матур –
Кабарынып тор да тор!

Жөмләнең ахыргы сүзләрен әйткәндә, куык (түгәрәк) зур булып җитешә.

Тәрбияче: «Куык нинди зур булып өрелде!» – ди һәм һәр бала янына килеп, кулларын тотып карый. Бер бала турысында тукталып кала һәм: «Һава, чык», – ди. Барлык балалар, кулларына тотынган килеш, түгәрәкнең уртасына керәләр һәм «тс, тс... » диләр (куык эченнән һава чыга). Аннан соң куык яңадан өрелә, уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны төрлечә үткәрергә мөмкин. Мәсәлән, куык өрелгәннән соң, тәрбияче: «Куык шартлады, кечкенә куыклар очып киттеләр! Очтылар, очтылар, очтылар... » – ди. Балалар үзләре теләгән якка йөгерешеп китәләр. Аннан соң тәрбияче: «Шартладылар!» – ди. Балалар, кулларын чәбәкләп, «Һоп!» дип, идәнгә утыралар. Уйнаучылар яңадан түгәрәккә тезеләләр, уен кабатлана.

## Куышу

Уен мәйданчыгының каршы якларына ике туры сызыла. Болар – балаларның «өйләре». Барлык балалар бер туры сызыкның артына (өй эченә) басалар. Турылар арасында уйнаучыларның берсе басып тора.

Өй эчендә торучы балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без, балалар, яратабыз
Йөгереп, сикереп уйнарга.
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга,
Тот!

Тәрбиясенең «Бер, ике, өч, инде монда куч!» дигән сүзеннән соң барысы да, өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Ике өй арасындагы бала йөгерүче балаларны тота.

2–3 бала тотылганнан соң, икенче тотучы сайлана, һәм уен яңадан башлана.

## Туп белән куышу

Балалар түгәрәк ясап басалар. Түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, тупны түгәрәк буенча җибәрәләр (бер-берсенә бирәләр):

Бер, ике, өч,
Дүрт, биш, алты,
Туп кемдә калды?
– Миндә!

Соңгы сүз туры килгән бала, «Миндә!» дип, тупны югары күтәрә һәм аны балаларның аякларына ыргыта. Аягына туп тигән бала уеннан чыга. 3–5 бала «тотылгач», уен тәмам була. Кабатлап уйнаганда, тупны икенче юнәлештә җибәрәләр.

## Аучы һәм ерткыч җәнлекләр

Уйнаучылар арасыннан бер бала «аучы» итеп билгеләнә. Ул бүлмәнең бер почмагында тора. Балалар – урмандагы «җәнлекләр»: «төлкеләр», «куяннар», «аюлар», «бүреләр» һ. б., алар төркемнәргә бүленеп, бүлмәнең төрле җирләренә урнашалар. Аучының кулында ике кечкенә туп. Ул урманда җәнлекләрне караштырып йөри һәм, берникадәр йөргәч, ял итәргә утыра. Шулвакыт тәрбияче: «Куяннар, төлкеләр һ. б. чыктылар», – ди. Бу сүзләрне ишетүгә, үз исемнәре әйтелгән җәнлекләр өннәреннән чыгалар (балалар аларның характерлы кыланышларын күрсәтеп йөриләр. Мәсәлән, куяннар ике аякта сикерәләр, төлкеләр койрыкларын болгап йөриләр һ. б.)

Тәрбияче: «Аучы!» – диюгә, барлык җәнлекләр өннәренә таба йөгерәләр, ә аучы аларны «ата» – тупларны бер-бер артлы ыргыта. Туплар кемгә дә булса тисә, шуны, алып китеп, «читлеккә» (билгеләнгән урынга) утырта.

Аучы 3–4 җәнлекне аткач, яңа «аучы» сайлана, уен яңадан башлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Аучы тупларны баскан урыннан кузгалмыйча гына атарга тиеш.

• Үз өненә кергән җәнлеккә туплар белән атарга ярамый.

• Бу уенны үткәрер алдыннан, балаларны кыргый җәнлекләр тормышына багышланган берәр әкият яки әдәби әсәр белән таныштырып китәргә дә мөмкин.

## Кайда яшерелгән, тап

Тәрбияче балаларга стенага (яки коймага) таба йөзләре белән әйләнеп басарга куша. Үзе, әкрен генә балалар яныннан бер читкә китеп, нинди дә булса берәр уенчыкны яшереп куя (уенчык тиз генә табарлык урынга яшерелми). Уенчыкны яшергәннән соң, тәрбияче, балаларга якынрак килеп: «Булды!» – ди. Бу эзләргә мөмкин дигәнне аңлата. Балалар бүлмә буйлап йөриләр һәм яшерелгән уенчыкны эзлиләр.

Уенчыкны беренче тапкан бала, барысы да күрсеннәр өчен, аны югарырак күтәрә. Аннан соң барысы да яңадан стена янына йөгерәләр, кабат артлары белән борылып басалар. Ә уенчыкны эзләп тапкан бала аны яшерә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Теләсә нинди кечерәк уенчыкны яшерергә мөмкин. Уенчыкны яшерер алдыннан, аны балаларга күрсәтергә кирәк. Әгәр балалар күп булса, бер үк вакытта төрле төстәге 2–3 флагны яки уенчыкны яшерергә мөмкин. Барлык уенчыклар яки флаглар табылганнан соң, табучы балалар аларны яңадан яшерәләр.

• Әгәр уен мәйданчыкта алып барылса, уйный торган урынны чикләргә кирәк, югыйсә, әйберне эзләү күп вакытны алып, кечкенә балаларның уеннан күңелләре тиз кайтуы мөмкин. Балаларга уенның төп шартларын аңлатырга кирәк: уенчыкны кайда яшергәнне карамаска һәм уенчыкны тавышсыз, шыпырт кына яшерергә.

## Әйдә, безне куып кара...

Балалар тәрбияче белән бергә түгәрәккә басалар. Барысы да кулга-кул тотынышалар. Түгәрәкнең уртасына алып баручы баса. Балалар, түбәндәге сүзләрне әйтеп, түгәрәк буенча уңга яки сулга таба йөриләр:

Без, балалар, яратабыз
Йөгереп, сикереп уйнарга.
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга!
Тот!

Соңгы сүзне әйтү белән, барлык балалар төрлесе төрле якка йөгереп китәләр, ә алып баручы (уртадагы бала) качучыларны куа. Тотылган балалар уеннан чыгып торалар. Алып баручы 3–5 баланы тоткач, уен тәмам була.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Яңа алып баручы тотылмаган балалар арасыннан билгеләнә.

• Уен яңадан башлангач, тотылган балаларның барысы да кабат уенга катнашалар. Беренче алып баручыны тәрбияче үзе билгели яки ул санамыш ярдәмендә сайлана.

## Яңгыр

Балалар уен үткәрелә торган бүлмәнең (яки мәйданчыкның) төрле җирләренә таралып йөриләр. Тәрбияче: «Болыт килә, болыт», – ди. Балалар, моны ишетүгә, әкрен генә үз тирәләрендә әйләнә-әйләнә, алдан билгеләнгән урынга җыелалар.

Барлык бала да җыелып беткәч, тәрбияче: «Яңгыр ява!» – ди. Балалар баскан җирләрендә ике аякта сикерә башлыйлар. Балалар бераз сикеренгәч, тәрбияче: «Яшен яшьни!» – ди. Балалар өч тапкыр чапылдатып кул чабалар. Тәрбияче: «Күк күкри!» – диюгә, балалар аяклары белән тыпырдыйлар – күк күкрәгән тавыш чыгаралар. Шулай итеп, яңгыр яуу, яшен

яшьнәү һәм күк күкрәү хәрәкәтләре берничә тапкыр кабатлана. Тәрбияче: «Болытлар таралалар», – диюгә, балалар яңадан бүлмәнең төрле җирләренә таралалар.

*Уенга күрсәтмә*

• Тәрбияче, бер үк төрле хәрәкәтләрнең артык күп кабатланып, балаларның арымауларына игътибар итәргә тиеш.

## Бакалар

Берничә бала «бака» итеп билгеләнә. «Бакалар» түгәрәкләп тезеп куелган урындыкларга утыралар. Уртада түгәрәк сызыла – ул «күл» була. Бакалар түгәрәк күл янында «ике аяклап» сикерешәләр. Калган балалар, тәрбияче белән бергәләп, түбәндәге шигырь юлларын әйтәләр:

Юл буенда бакалар
Сикерә-сикерә чабалар.
Куа-куа-куа, куа-куа-куа,
Сикерә-сикерә чабалар.

Шигырьнең ахырында балалар кул чабалар – бакаларны куркыталар. Бакалар күлгә сикерәләр һәм тын гына «чүгәләп утыралар».

Яңа «бакалар» сайлана, уен яңадан башлана.

## Соры бүре

Уйнаучылардан берсе «бүре» итеп билгеләнә. Ул өнендә (мәйданчыкта сызып билгеләнгән урында) утыра. Калган балалар «кәҗә бәтиләре» булалар. Алар көтүдә (болында) үлән ашап йөриләр, сикерәләр, уйныйлар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Тәмле үлән ашыйбыз,
Бүреләрдән качмыйбыз,
Ашап туйгач, чабышып,
Тагын өйгә кайтабыз.

Соңгы сүзне әйткәннән соң, бүре, өненнән чыгып, кәҗә бәтиләрен куа башлый. Ике кәҗә бәтие тотылганнан соң, яңа «бүре» сайлана, һәм уен яңадан башлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Кечкенәләр белән бу уенны яз яки җәй көнендә уйнарга кирәк. Елның бу вакытларында балалар җиңел киемнәрдән булалар, иркенләп хәрәкәтләнәләр. Шуның белән беррәттән, алар коллективта уйнау, йөгерү күнегүләрен дә шактый үзләштерә башлаган булалар.

• Уенны өйрәнү этабында тәрбияче үзе дә балалар белән бергә кәҗә бәтие булып уйнарга һәм уендагы сүзләрне үзе башлап әйтергә тиеш.

• Шигырьне әйтеп бетергәннән соң гына, кәҗәләр йөгерергә, ә бүре куарга тиеш.

## Куяннар

Балалар – «куяннар». Алар «ояларында» – җиргә сызылган түгәрәк сызыклар эчендә торалар. Аларга каршы якта «яшелчә бакчасы», ә аның янында «сакчы этнең оясы».

Куяннар бакчага кәбестә һәм кишер ашарга китәләр, яшелчә түтәлләре арасында (сызыклар буйлап) сикереп йөриләр. Кинәт тәрбияче: «Эт килә!» – дип кычкыра. Куяннар, йөгерешеп, үз ояларына качалар, ә эт аларны куа. 2–3 куян тотылганнан соң, яңа «эт» билгеләнә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Эт оясының яшелчә бакчасыннан ераклыгы куяннар эттән качып китеп өлгерерлек булырга тиеш.

• Уенны аңлатканда, балаларга бер сызыктан икенчесенә кадәр ничек сикеререп барырга кирәклекне күрсәтергә кирәк.

• «Эт килә!» дигән сигналдан соң гына качарга ярый.

• Тотылган куянны эт үзенең оясына алып китә. Куяннарны ояларында вакытта тотарга ярамый.

• Бу уенны мәйданчыкта үткәрергә тәкъдим ителә.

## Кыш бабай

Балалар түгәрәккә тезеләләр.

Кыш бабай (тәрбияче) түгәрәк уртасында, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, акрын гына йөри:

Ап-ак озын сакаллы
Бу менә мин – Кыш бабай.
Эзләп сезне урманда,
Йөрим инде ничә ай.
Тиз йөгереп килсеннәр
Миңа кирәк җәнлекләр.

Түгәрәктә торучы балалар: «Син нинди җәнлек эзлисең соң?» – дип сорыйлар.

Кыш бабай: «Куяннарны эзлим», – ди.

Түгәрәктә торучы балалар куяннар кебек сикерешәләр. Бераз сикергәч, алар: «Ә син куяннарны яратасыңмы?» – дип сорыйлар.

Кыш бабай: «Яратам», – дип җавап бирә.

Балалар: «Ә син аларны куып тота аласыңмы?» – дип сорыйлар.

Кыш бабай: «Куып тота алам», – ди.

Куяннар йөгерешеп китәләр, ә Кыш бабай аларның берсен куып тота.

Уен яңадан башлана. Бу юлы Кыш бабай башка бер җәнлекне (мәсәлән, тиеннәрне, аюларны, боланнарны һ. б. ны) эзләвен әйтә. Балалар шул җәнлекләрнең хәрәкәтләрен (мәсәлән, аю алпан-тилпән йөри, тиеннәр вак-вак сикерешеп йөриләр, боланнар кызу йөгерәләр, керпе бик акрын хәрәкәтләнә һ. б. ны) күрсәтәләр.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны башлаганчы, хәрәкәтләрне ничә тапкыр үтәү һәм нинди сүзләрне әйтү турында тәрбияче балаларга аңлатып куя.

• «Куып тота алам» дигән сүздән соң гына балалар йөгерешеп китәләр.

• Тотылган җәнлекләрне Кыш бабай бер читкә алып китә, ә уен кабатланганда, алар яңадан түгәрәккә тезеләләр.

• Уен кыш көнендә урамда үткәрелә. Шулай ук бина эчендә дә, мәсәлән, Яңа ел бәйрәмендә уйнарга мөмкин.

## *5–6 яшьлек балалар өчен уеннар*

### Тот, тот!

0,5 м озынлыктагы таякка тоту өчен җайлы булган берәр әйбер (мәсәлән, божра яки мамык тутырылган кечкенә янчык) нык бау белән беркетелә. Таякка йомшак әйбер эләргә кирәк, ул, балаларга тиеп, аларның тәннәрен авырттырмаслык булсын.

Балалар түгәрәккә тезеләләр. Тәрбияче түгәрәк уртасында кулына таяк тотып басып тора. Ул таякка эленгән әйберне чиратлап һәр балага якынлаштыра. Таякны әле балаларның куллары тигезлегенә кадәр төшереп, әле югары күтәреп, шаяра-шаяра, «Тот, тот!» дип кабатлый. Таякка эленгән әйберне тота алган бала җиңүче була.

### Авыз ачып калма

Балалар түгәрәк ясап басалар. Һәрберсенең алдына берәр уенчык куела. Тәрбияченең «Таралыгыз!» дигән сигналы буенча, балалар үз урыннарыннан йөгереп китәләр һәм музыка астында ирекле рәвештә биеп, уйнап йөриләр. Шул арада тәрбияче уенчыкларның берсен алып куя, шулай итеп, уйнаучыларның берсен урынсыз калдыра. Ул бубенга нык итеп сугуга (яки «Урыннарыгызга!» дип кычкыруга), балалар нинди дә булса уенчык артына килеп басалар, уенчыкны, алып, югары күтәрәләр. Уенчыксыз калган бала «авыз ачып калучы» була. Уен 5–6 тапкыр кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Йөгерү һәм сикерү вакытларында тәрбияче бубен кагып торырга да мөмкин.

• Уен музыка белән оештырылса, музыка җитәкчесе уен барышын күзәтергә, билгеле бер этапларда музыканы җибәрергә яки туктатып торырга («Урыннарыгызга!» дип кычкырганда) тиеш була.

## Үз төсеңне эзлә

Балалар берничә төркемгә бүленеп басалар. Һәр төркемгә төсле тасмалар бирелә (бер төркемгә – кызыл, икенчесенә – зәңгәр, өченче төркемгә – яшел, сары һ. б.). Төркемнәр уртада капка калдырып, түгәрәк булып тезеләләр. Һәр төркемнең үз әйдәүчесе була. Аның кулында үз төркеменең тасмалары төсендәге флаг була.

Балалар бубен тавышына яки музыка астында мәйданчык буенча таралып йөгерәләр. «Тукта!» дигән сигналны ишетү белән, алар тукталып калалар һәм күзләрен йомалар. Шул арада әйдәүчеләр урыннарын алмашалар. «Үз төсеңне эзлә!» дигән сүзгә бөтенесе күзләрен ачалар һәм үз төсләрен эзләп йөгерәләр. Үзенең төсе янына беренче булып җыелып өлгергән төркем җиңүче була.

## Үз «капитаныңны» тап

Балалар, берничә төркемгә (командага) бүленеп, мәйданчыкның төрле урыннарында басып торалар. Һәр төркемдә бер бала «капитан» итеп билгеләнә. Төркемнәр үз капитаннарын уртада калдырып, кечкенә түгәрәкләр ясап тезеләләр.

Төркемнәр музыка астында үз түгәрәкләре буйлап әйләнеп йөриләр һәм нинди дә булса эш эшләгән хәрәкәт ясыйлар (мәсәлән, язалар, чигү чигәләр, кер юалар һ. б.). Тәрбиячેнең «Йөгер!» дигән сүзенә барлык балалар мәйданчык буенча тара-

лышып йөгерә башлыйлар, «Тукта!» дигәч, бар да тукталалар һәм күзләрен йомалар. Шул арада капитаннар урыннарын алышыналар. Тәрбиячененң «Капитаныңны эзлә!» дигән сүзләренә барысы да күзләрен ачалар һәм ничек тә булса тизрәк үз капитаны янына җыелырга тырышалар. Үз капитаны тирәсенә башкалардан элегрәк җыелган төркем җиңгән санала. 2–3 уеннан соң капитаннар алмашына. Уен 4–5 тапкыр кабатлана.

## Төлке тавык кетәклегендә

Мәйданчыкның кара-каршы якларына 2 озын эскәмия – тавыклар өчен «кунача» куела. Эскәмиянең арткы ягы – «тавыклар кетәклеге». Кетәклек эчендәге тавыклар (балалар) канатларын кага-кага йөгерешеп йөриләр.

Бер читтә «төлке оясы» урнашкан була. Анда «төлке» утыра. Шулвакыт әтәч кычкырган тавыш ишетелә (тәрбияче ике тапкыр «кикрикүк» дип кычкыра). Икенче тапкыр кычкыруга, тавыклар куначага таба йөгерәләр һәм, кунача өстенә менеп, төлкедән котылырга тырышалар. Төлке тавыклар артыннан йөгерә һәм вакытында куначага менәргә өлгермәгән (яки анда тора алмыйча егылып төшкән) тавыкларны тотып, үз оясына алып китә. Төлке 2–3 тавыкны тоткач, уен тәмамлана. Яңа «төлке» һәм яңа «әтәч» сайлана.

Уен 3–4 тапкыр кабатлана.

## Тавышыннан бел

Мәйданчыкта зур түгәрәк сызыла. Түгәрәктән читтәрәк тәрбияче басып тора. Балалар мәйданчык буйлап йөгереп йөриләр. Тәрбиячененң «Бер, ике, өч, тизрәк түгәрәккә күч!» дигән сүзләренә барлык балалар түгәрәк кырыена килеп тезеләләр. Алдан ук сайлап куелган бер бала тәрбияче янына йөгереп килә дә түгәрәккә арты белән баса.

Түгәрәккә җыелып беткәч, барлык балалар болай диләр:

Без бераз шаярыштык,
Урыннарга урнаштык.
Син тизрәк уйлап тап:
Кем кычкырды сине атап?

Сүзләр әйтелеп беткәч, тәрбияче кулы белән балаларның берсенә күрсәтә. Ул бала түгәрәккә арты белән басып торган баланың исемен атый. Бу соңгысы, тавышына карап, аңа кем эндәшкәнен белергә тиеш. Әгәр ул тавыштан таныса, үзенә эндәшкән бала белән урынын алмаша. Шуннан соң уен яңадан башлана һәм 5–6 тапкыр кабатлана.

Уен ишетү тойгысын үстерә.

## Йомырка белән йөгерү

Бер сызык буйлап тезелгән балаларның уң кулларына йомырка салынган агач кашык тоттыралар. Команда булгач, балалар, кашыкны сабыннан тотып, билгеле урынга хәтле йөгерәләр. Алар ничек кенә булса да кашыктагы йомырканы төшермәскә тырышалар, ләкин кул белән йомыркага орынырга ярамый. Юлда кашыктан йомырканы төшергән бала, кире кайтып, яңабаштан йөгерә башлый.

Бу уен хәрәкәт иткәндә гәүдәнең тигезлеген сакларга өйрәтә, балаларның дикъкатен үстерергә ярдәм итә.

## Үрмәкүч һәм чебеннәр

Санамыш ярдәмендә «үрмәкүч» сайлана. Балалар «чебеннәр» була. Чебеннәр бүлмә буйлап очалар. Тәрбияче «Үрмәкүч!» дип әйтү белән, үрмәкүч килеп чыга, ә чебеннәр теләсә нинди позада хәрәкәтсез калалар. Үрмәкүч чебеннәр янына барып, хәрәкәтләнмәсләрме дип карап йөри. Берничек тә хәрәкәтләнмәгән чебеннәргә тими, аз гына булса да хәрәкәтләнгән чебеннәрне үз оясына алып китә. Тотылган чебен уенның ахырына кадәр үрмәкүч оясында кала.

Беркадәр вакыт үрмәкүч үз оясында була. Бу вакытта чебеннәр тагын очып йөриләр. Үрмәкүч күренү белән, чебеннәр хәрәкәтләнүдән туктыйлар, ә үрмәкүч бары тик хәрәкәт күрсәткән чебеннәрне генә тота.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Балалар, уен кагыйдәсен бозып, шаярып, хәрәкәт ясамаска тиешләр. Уен кагыйдәсе буенча, андый баланы үрмәкүч тота алмый.

• Уенның барлык шартларын яхшы үтәүче балаларны уен ахырында билгеләп үтәргә кирәк.

• Уенны музыка белән дә үткәрергә мөмкин.

## Балалар һәм чуртан

Идәнгә яки җиргә (уен мәйданчыкта үткәрелгәндә) сызык сызып, елга урыны билгеләнә. Елгада балыклар (балалар) йөзәләр, әйләнәләр, бер-берсен куалар (сызыктан читкә чыкмыйлар).

Елганың бер башында таш астына качкан «чуртан» уйнаучы балыкларны күзәтеп тора. Кинәт чуртан, таш астыннан чыгып, балыкларны куа башлый. Балыклар аннан качалар, тотылган балык чуртан ролен үти. Уен кабатлана.

## Кем тизрәк җыелыр?

Балалар берничә төркемгә бүленәләр һәм, сигнал буенча, төрле якка йөгерешеп китәләр. Тәрбиянең «Җыелырга!» дигән командасы буенча, төркемнәр үз урыннарына җыелалар. Тизрәк җыелган төркем җиңүче була.

## Тиенне тот!

Уенны үткәрү өчен урындыклар кирәк була. Балалар «тиеннәр» булып, урманда «агач башларында» (урындыклар-

да) утырып торалар. Алдан билгеләнгән ике бала урманга тиен тотарга баралар. Аларны күргәч, тиеннәр хәрәкәтсез калалар (селкенмәгәндә, аларны берәү дә күрә алмый). Әлеге ике бала тиеннәрнең хәрәкәтләнү-хәрәкәтләнмәүләрен күзәтеп йөриләр.

Тотучылар киткәч, тиеннәр, агачтан сикереп төшеп, чикләвек җыя башлыйлар. Бу вакытта ике бала йөгереп килә дә тиеннәрне тотарга тырыша. Тиеннәр кире агачларга таба йөгерәләр, тизрәк менеп өлгерергә телиләр.

*Уенга күрсәтмә*

• Агачка менеп утырырга өлгергән тиеннәрне тотарга ярамый.

## Атлар

Мәйданчыкның кара-каршы якларында озын сызыклар үткәрелә. Балалар ике төркемгә бүленәләр. Бер төркем – «ат җигүчеләр», икенчеләре «атлар» була. Ат җигүчеләр атларын «абзарга» (мәйданчыкның яки бүлмәнең бер башына сызылган урынга) илтәләр, ә үзләре «өйләренә» (мәйданчыкның икенче ягына сызылган урын) кайтып китәләр.

Барысы да йоклыйлар. Бу вакытта тәрбияче (яки артык калган бала), «сакчы» булып, абзар янында утыра (яки йөреп тора) һәм түбәндәге сүзләрне әйтә:

Абзар янында утырып,
Атларны каравыллыйм.
Иртә беләнгә кадәр
Аз гына да йокламыйм.
Әкрен генә ала ат
Оясында пошкыра.
Төн яктыра башлады,
Әтәчләр дә кычкыра.
Менә төн үтеп китте,
Торырга вакыт җитте.

Әй уңганнар, торыгыз,
Атларыгызны җигегез!

Бу сүзләрдән соң «сәгать суга» (тәрбияче бубен кага). Ат җигүчеләр, торып, атларны җигәләр (дилбегә киертәләр). Дилбегә 2 метр чамасы озынлыктагы бау була (кыңгыраулар белән бизәлсә бигрәк тә яхшы). Атларны җигеп бетергәч, барысы да, абзардан чыгып, бер-бер артлы тезеләләр. Тәрбияче: «Атлар, барыгыз», – ди. Атлар аякларын күтәреп атлый, ә ат җигүчеләр гади адым белән атлап баралар. Тәрбияче: «Чабыгыз!» – дигәч чабалар, «Тпр-ру!» – дигәч туктыйлар.

Тәрбияче: «Атларны абзарга илтегез», – дигәч, ат җигүчеләр атларны, туарып, абзарга илтәләр, үзләре өйләренә кайтып китәләр.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны төрләндерергә мөмкин. Мәсәлән, балалар кырга эшләргә баручы эшчеләр һ. б. булалар.

• Тәрбияченең сигналын – «На-а!», «Тпр-ру!» ымлыкларын – балалар үзләре дә әйтәләр.

## Җәнлекне камап ал!

Санамыш ярдәмендә бер бала «төлке» («аю») итеп билгеләнә, калган балалар «аучылар» булалар.

Төлке (аю) урман буйлап әкрен генә, як-ягына карана-карана килә. Аучылар яшеренеп кенә, аның артыннан күзәтеп кенә киләләр. Әгәр төлке (аю) йөгерсә, аның артыннан куып баручы аучылар – балалар да йөгерәләр һәм, бер-берсенә куллары белән тотынып, төлкене (аюны) төрле яктан камап алалар, аны тота алсалар, алып китеп, зоология бакчасына илтәләр.

Аннан соң яңа «төлке» («аю») сайлана, һәм уен дәвам итә.

## Сыерчык оялары

Идәнгә (җиргә), икешәр бала сыярлык итеп, түгәрәкләр сызыла. Болар – «сыерчык оялары». Балалар – «сыерчыклар». Алар парлашып утыралар. Бер сыерчыкка урын җитми кала.

Сыерчык оялары ясалып беткәч (түгәрәкләр сызылып беткәч), сыерчыклар (балалар) төрле якларга оча башлыйлар.

Тәрбияче: «Безгә җылы яклардан сыерчыклар килде!» –дип әйтүгә, сыерчыклар ояларга җыелалар (һәрберсе түгәрәк эченә керергә тырыша). Һәр ояда бары тик ике генә сыерчык урнаша ала. Өченче сыерчыкка урын юк. Түгәрәккә кереп өлгермәгән сыерчык оясыз калган булып санала. Уен яңадан башлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Ояларны урындыклар тезеп тә ясарга мөмкин.
- Ояларга урнашу тәрбияче сигнал биргәч кенә башлана.
- Сыерчыклар теләсә кайсы ояга кереп урнаша алалар.
- Балалар ояларны үзләре теләгәнчә ясыйлар (ясый алмаганнарга тәрбияче булыша).
- Уен барышында тәрбияче сыерчыкларның оядан ерак очуларын һәм һаман да бер үк ояга кермәүләрен күзәтә.

## Хәйләкәр төлке

Барлык балалар түгәрәккә басалар. Түгәрәктән бер читтә – «төлке өне» була.

Түгәрәккә баскан балалар күзләрен йомалар. Шулвакытта тәрбияче түгәрәк буйлап йөри һәм бер балага кулы белән тиеп үтә. Тәрбияче кайсы балага кулы белән кагылса, шул бала «хәйләкәр төлке» була. Шуннан соң тәрбияче балаларга күзләрен ачарга һәм хәйләкәр төлкене эзләп табарга куша. Моның өчен балалар барысы бергә: «Хәйләкәр төлке, син кайда?» – дип сорыйлар һәм, хәйләкәр төлке үзен күрсәтмәсме дип, як-якка караналар. Берникадәр паузадан соң тагын бер тапкыр сорап карыйлар. Өченче тапкыр сораганнан соң, хәйләкәр төлке: «Мин

монда!» – дип кычкыра һәм уенда катнашучыларны куа башлый. Уйнаучыларның төрлесе төрле якка йөгерәләр. Тотылган балаларны төлке үз оясына алып китә.

Төлке 2–3 баланы тоткач, яңа «төлке» сайлана, һәм уен кабатлана.

Яңа «төлке»не, нәкъ беренче уендагы рәвештә, төлке ролендә уйнаган бала сайлап чыгара.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Төлке балаларны, «Төлке, син кайда?» дип, өч тапкыр сорагач кына куа башлый.

• Әгәр төлке өченче тапкыр сораганчы ук үзенең төлке икәнен сиздерсә, яңа «төлке» сайлана.

• Тотылган балалар арасыннан «төлке» сайланмый.

## Бүредән кач!

Уйнаучылар арасыннан берсе санамыш ярдәмендә «бүре» итеп билгеләнә.

Балалар урманга җиләккә баралар, таралышып, җиләк җыеп йөриләр (чүгәләп-чүгәләп алалар). Кинәт бүре улаган тавыш ишетелә, куаклар артыннан бүре килеп чыга. Балалар, бүредән качу өчен, тиз генә «агачларга» (гимнастика баскычына, урындыкка) үрмәләп менәләр. Бүре күздән югалгач, балалар, яңадан агач ботакларыннан төшеп, җиләк җыюларын дәвам итәләр. Яңа «бүре» сайлана, һәм уен яңадан башлана.

Уен берничә тапкыр кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Әгәр уен мәйданчыкта үткәрелсә, балалар бүредән куак артларына качалар.

• Уен кагыйдәсе буенча, бүре балаларны тотмый, оясыннан чыгып куркыта гына.

• Уенга өстәмәләр кертергә мөмкин. Мәсәлән, балалар урманда, җырлый-җырлый, җиләк җыялар:

Җиләк җыям, җиләк җыям
Әнкәемә бүләккә,
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк микән?..

Балалар җырны җырлап бетерүгә, бүре килеп чыга, аннан качып, агачларга (баскычка) меңәләр. Аннан соң бүре күздән югала, балалар яңадан җиләк җыя башлыйлар, уен кабатлана.

## Төз ыргыту

Бүлмә уртасына 50–60 см диаметрлы кәрзин куела. Балаларга кечкенә туплар өләшенә (резин яки чүпрәк туплар). Кәрзин әйләнәсенә, бераз ара калдырып, түгәрәкләр сызыла.

Балалар түгәрәк эченә кереп басалар да, сигнал буенча, тупларын кәрзингә берьюлы ыргыталар. Тәрбияче оста ыргытучы балаларны мактый.

Уен барлык балалар да тупларны кәрзингә кертә алганчы кабатлана.

## Каршылыкларны үтеп ярышу

Балалар 2 колоннага бүленеп, бер-бер артлы тезелеп басалар. Юлга каршылыклар куела: залның бер башында, рейкаларга тоташтырып, 15–20 см биеклектә бау бәйләнә (яки 50–60 см киңлектә сызык сызыла). Икенче башка, араларын 80 см калдырып, 3–4 кыршау куела һ. б.

Сигнал булуга, колоннада беренче булып басып торган бала бау аша сикереп чыга да кыршауларга таба йөгерә. Кыршаудан үрмәләп чыкканнан соң, йөгереп килеп, колоннада икенче булып басып торган балага кулы белән кагыла да колоннаның артына барып баса. Ярышны икенче бала дәвам итә.

Каршылыкларны үтеп, беренче булып тезелергә өлгергән команда җиңүче була.

## Тупны ыргыт!

Балалар залның бер башында тезелеп басып торалар. Кулларында – зур туплар. Бүлмәнең (мәйданчыкның) икенче башына, каршы якка, сызык сызыла (ара ераклыгы балаларның көчләренә карап билгеләнә). Уйнаучылар бер адым алга чыгып басалар. Тупны сызык артына җиткерергә тырышып ыргыталар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче кайсы баланың тупны сызыкка кадәр җиткермәвен, кайсысының сызыктан уздырып җибәрүен билгели.

• Тупны ыргытучылар аны йөгереп алып киләләр дә башка балага бирәләр.

• Әгәр дә уенга төрле яшьтәге балалар катнашса, ул вакытта, тупны ыргыту өчен, төрле ераклыкта берничә сызык сызарга мөмкин.

## Шарларның очрашуы

Уйнаучылар, түгәрәкләнеп, идәндәге келәм өстенә утыралар. Бер бала утырмый кала, ул, кулына ике төстәге шар тотып, түгәрәк эчендә йөри. Ике янәшә утырган баланы сайлап, аларга берәр шар бирә. Шарларны алучы балаларның берсе уң ягында, икенчесе сул ягында утырган балаларга шарларны биреп, түгәрәк буйлап күчереп йөртәләр. Бу шарлар соңгы ике бала кулында кара-каршы очрашалар. Шарлар кайсы балаларда очрашсалар, шул балалар, тиз генә урыннарыннан торып, шарларны бер-берсенә тидерәләр дә икесе ике якка таба түгәрәкнең тышкы ягыннан йөгереп китәләр. Буш калган урынга кем алдан килеп җитсә, урынны шул ала, ә соңга калган бала үзенең урынын түгәрәктә шарларны биреп йөрүчегә калдырып, үзе шарлар бирүче булып кала. Ул ике шарны ала да икенче пар балага бирә, һәм уен яңадан дәвам итә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Әгәр кара-каршы йөгерүче балалар үз урыннарына икесе

дә бер үк вакытта килеп җитсәләр, уенны алып баручы шарларны яңадан үзенә ала да, түгәрәктә йөреп, башка балаларны сайлый.

• Кара-каршы йөгерүчеләр, бер-берсе белән очрашкач, берсен берсе тотарга тиеш түгелләр.

## Капчыкны алмаштыр!

Балалар уен мәйданчыгының бер башында 2–3 колоннага бүленеп басалар. Һәр колоннаның алдыннан сызыклар үткәрелә. Мәйданчыкның икенче башында һәр колонна турысына берәр түгәрәк сызылып куела. Түгәрәкләр уртасында ком тутырылган бер үк төсле капчыклар ята. Колоннаның башында торучыларга да ком тутырылган капчыклар бирелә, аларның төсләре түгәрәктәге капчыклардан аермалы була.

Балаларның барысы да: «Бер, ике өч, йөгер!» – дип әйтәләр, һәм колоннада беренче булып басып торучы балалар, үзләренең түгәрәкләренә йөгереп барып, капчыкларын алмаштыралар һәм, яңадан йөгереп, үз урыннарына кайталар. Капчыклар башка балаларга тапшырыла, йөгергән балалар колоннаның артына барып басалар. Барлык балалар да бер тапкыр йөгереп, капчыкларны алмаштырып үткәч, уен беткән булып исәпләнә. Уенны беренче булып тәмамлаган (биремне үтәп, иң беренче булып тезелгән) колонна җиңүче була.

*Уенга күрсәтмә*

• Капчыклар нык, ике катлы тыгыз материядән тегеләләр һәм ком белән тутырылалар. Аларның зурлыгы 12х6х3 см булып, авырлыгы 100–150 грамм була. Мондый капчыкларны еракка ыргытып уйнау өчен дә файдаланырга мөмкин.

## Тупны сетка аша ыргыту

Мәйданчыкта, балаларның буеннан югарырак итеп, сетка тартылып куела. Балалар, сетканың ике ягына ике адым ераклыкта басып, сетка аркылы туп ыргыталар.

Туп ыргыту түбәндәгечә бара: беренче бала каршыдагы балага ыргыта. Каршыдагы беренче бала киредән үз каршында баскан беренче балага ыргыта. Аннан соң беренче бала тупны икенче балага бирә. Шул рәвештә уен дәвам итә. Тупны яхшы ыргытып һәм тотып алган пар бер адым артка чигә. Димәк, икенче уенда алар ераграк арадан ыргыталар. Алдан билгеләнеп куелган чиккә җиткәч, уен бетә.

## Сазлык

Бер-берсеннән 10–15 адым киңлегендә ара калдырып, ике сызык үткәрелә («сазлык»). Алар арасына, бер-берсеннән 25–50 см ара калдырып, түгәрәкләр («түмгәкләр») сызыла. Балалар шушы түмгәкләргә басып, сазлыкның бер ягыннан икенче ягына (бер сызыктан икенчесенә) күчеп чыгарга тиешләр. Балалар түмгәктән түмгәккә берьюлы ике аяк белән сикерәләр. Сазга баткан балалар уеннан чыгалар (кырыйга чыгып, «аякларын киптереп утыралар»).

## Кул чабу

Балалар түгәрәкләнеп тезелгән урындыкларда утырып торалар. Тәрбияче уенның кагыйдәләрен аңлата: «Мин хәзер 5 кә кадәр санyйм. Игътибарлы булыгыз: мин 5 санын әйткәндә, сез кул чабарга тиеш буласыз, ә инде 5 тән башка саннарны әйткәндә кул чапмыйсыз», – ди. Балалар тәрбияче белән берлектә кычкырып саныйлар, «5» дигәндә кул чабалар. Уен 2–3 тапкыр кабатланганнан соң, тәрбияче «ялгыша» башлый, ягъни 3 яки нинди дә булса башка санны (ләкин 5 не түгел) әйткәндә кул чабарга теләгән кебек булып кулларын җәя һәм тиз генә бер-берсенә китереп куша, ә балалар тәрбияче артыннан ялгышып кул чабалар. Ялгышкан балалар түгәрәктән бераз читкәрәк чыга баралар.

*Уенга күрсәтмә*

• Бу уенны, балаларның яшьләренә карап, башка саннар белән дә үткәрергә мөмкин.

## Кошлар һәм мәче

Өч-дүрт бала – «кошлар», калганнары – «кош балалары», ә бер бала «мәче» була. Уен башланыр алдыннан, кошлар һәм кош балалары агач ботакларында (урындык өстендә) булалар. Мәче кошлардан 20–30 адым ераклыктагы түгәрәк сызык эчендә утыра. Кошлар агач өсләреннән әкрен генә очып төшәләр һәм үзләренең балалары өчен азык эзләп очалар. Бераз очканнан соң, алар үзләренең балаларын, «Чик-чирик-чик-чирик!» дип, орлык чүпләргә чакыралар. Кош балалары очып киләләр. Барысы да, чүгәләп, кошларның җим чүпләүләрен гәүдәләндерәләр. Аннан соң кошлар үзләренең балаларын очарга өйрәтәләр – һәр кош үз баласы белән урман (бүлмә) буйлап оча. Мәче берни дә күрмәгән булып, йоклаганга салышып утыра. Бераз вакыттан соң мәче кинәт кошларга ташлана, кошлар, тизрәк агачларга кунып, мәчедән котылырга тырышалар (балалар биегрәк урынга менәләр). Тотылган кошны мәче өенә алып китә – бер читкә илтеп куя. Уен яңадан башлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Кош балалары бары тик кошлар чакыргач кына һәм һәрберсе үз әнисе артыннан гына оча.

• Балаларны туплау максатыннан, кошлар очып йөри алган чикне билгеләргә – түгәрәк сызарга мөмкин. Бу вакытта сызык эченнән читкә чыкмый гына очарга мөмкин дигән кагыйдә кертелә.

• Кош һәм мәче ролен үтәүчеләр һәр уеннан соң яңадан билгеләнә.

## Йорт куяннары

Урындыклар, берникадәр ара калдырылып, бер рәткә тезелә. Урындыклар арасына кыршаулар бәйләп куела. Бала-

лар кыршаулар артына өчәүләп-дүртәүләп чүгәлиләр. Болар – читлектәге «йорт куяннары». Санамыш ярдәмендә «сакчы» сайлана. Сакчы йорт куяннары янына килә, аларны ашата, аннан соң үзенең өенә китә – бераз читкәрәк китеп утыра. Ул киткәннән соң, йорт куяннары читлекләрдән чыгалар һәм бүлмә буйлап таралышалар, йөгерешеп, сикерешеп уйный башлыйлар. Сакчы, чыгып, йорт куяннарын читлекләргә куып кертә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Сакчы үзенең өенә кергәч кенә, йорт куяннары читлекләрдән чыга алалар.

• Балаларга бераз йөгерергә, сикерергә мөмкинлек бирергә, ләкин артык арып китүләренә юл куймаска кирәк.

• Уенны кабатлаганда, йөгерү яки сикерүләрдән соң ял бирү турында онытмаска кирәк.

## Башлык һәм таякчык

Балалар түгәрәк ясап басалар. Араларыннан берсе башына бәйләнгән чуклы башлык кия. Башлык баланың борын турысына кадәр төшеп, күзен каплап тора. Шуннан соң ул кулына таяк алып, түгәрәк уртасына кереп баса. Куллары белән тотынышкан балалар түгәрәк буенча әкрен генә йөгерәләр һәм: «Бер, ике, өч, дүрт, таяк тукылдавын көт!» – диләр. Башлык кигән бала үзенең таягы белән идәнгә сугып ала. Балалар туктыйлар һәм уртада торучының кемгә таягын сузганын көтеп торалар. Балалардан берсе, үзенә сузылган таякның очыннан тотып, башлыклы баланың исемен әйтә, ә башлыклы бала, аның тавышыннан танып, үзенә дәшкән баланың кем икәнен белергә тиеш була. Әгәр белә алмаса, уен янадан башлана. Шул рәвешчә, башлыклы бала үзенә дәшүчеләрне таныганчы, уен дәвам итә. Аннан соң башлык белән таяк икенче балага күчә, һәм уен яңадан кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Бу уен, гадәттә, бик җанлы һәм кызыклы үтә. Аны уйнаганда, тәрбияче балаларны тынлык сакларга күнектерергә тиеш. Югыйсә тавышны аеру мөмкин булмый.

• Түгәрәк уртасында торучы таяк белән шакылдатуга, түгәрәктәге балалар барысы да туктап калырга тиешләр.

## Карусель

Ике очын бергә китереп бәйләгән бау җиргә түгәрәк формасында җәеп салына. Балалар аның янына киләләр дә бауны җирдән күтәрәләр, тәрбиячене әйтүенә карап, аңа уң яки сул кул белән тотыналар.

Балалар, бауны тотып, түбәндәге сүзләрне әйтеп йөри башлыйлар:

Көчкә-көчкә-көчкә генә
Карусель кереште әйләнергә,
Ә аннары әйләнешеп-әйләнешеп,
Бар да китте йөгерешеп-йөгерешеп.

Балалар башта әкрен генә йөриләр, ә «йөгерешеп» дигән сүздән соң йөгерә башлыйлар. Балалар йөгергән вакытта, тәрбияче «йөгерешеп» дигән сүзне 6 тапкыр кабатлый, «борылырга» дигәч, балалар тиз генә борылалар да, бауны икенче кулларына тотып, кире якка йөгерә башлыйлар. Тәрбияче тагын берничә (6–7) кабат «йөгерешеп» дигән сүзне кабатлый, балалар бу вакытта йөгерәләр.

Әкрен, әкрен, ашыкмагыз,
Карусельне туктатыгыз.
Бер-ике, бер-ике,
Менә инде уен бетте.

Бу сүзләрне әйтә башлагач, карусель әйләнүе әкренәя һәм соңгы сүзләрне әйткәч туктый. Балалар бауны җиргә куялар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Әгәр уенда зур төркем (20–25 кеше) катнашса, балаларны ике төркемгә бүләргә мөмкин: бер төркем әйләнеп йөри, ә икенчесе тәрбияче белән бергә сүзләрне такмаклап әйтеп тора. Шул ук вакытта кул чабарга да мөмкин. Аннан соң төркемнәр алмашына.

• Уен беткәч, балалар мәйдан буенча таралалар, ә кыңгырау шылтырагач, карусельгә утырырга, ягъни бауга тотынырга ашыгалар. Уен 3–4 тапкыр кабатлана.

## *6–7 яшьлек балалар өчен уеннар*

### Күз бәйләш

Уйнаучылар түгәрәкләнеп тезеләләр, түгәрәкнең уртасында ике бала басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, ә икенчесенә кечкенә кыңгырау бирәләр. Беренче бала кыңгырау тавышы буенча иптәшен тотарга тырыша, ә икенчесе ничек булса да тоттырмаска тырыша. Ул тотылганнан соң, түгәрәк уртасына башка балалар керәләр.

### Узышчылар

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Уйнаучылардан 20–25 м ераклыкта сызык үткәрелә яисә бу урын флаглар белән билгеләнә. Уйнаучылар барысы бергә: «Бер, ике, өч!» – дип кычкыралар. Шуннан соң беренче булып басып торган ике бала флагларга кадәр йөгереп барып, кире йөгереп әйләнеп кайталар. Икесе дә бер-берсен узарга тырыша. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, аннан соң икенче пар йөгерә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче балаларның сигнал булганнан соң гына йөгерешеп китүләрен һәм билгеләнгән урынга барып җитүләрен күзәтергә тиеш.

• Парларны көчләре ягыннан тигез булуларын исәпкә алып сайларга кирәк.

## Җитез бул!

Уйнаучыларның һәрберсе, чиратлап, җитезлек, зирәклек, саклык таләп итә торган нинди дә булса эш үти, мәсәлән:

1) җиргә сызылган түгәрәк сызык өстеннән йөрергә;

2) түбән итеп бәйләнгән бау астыннан чыгарга, ләкин аңа кагылмаска;

3) идәнгә сызылган сызык буенча зигзаг ясап, ике аяклап сикереп барырга;

4) күзне йомган хәлдә, түгәрәкнең уртасыннан үз урынына кадәр килеп җитәргә;

5) киемендәге төймәсенә (сәдәфенә) тотынган хәлдә, билгеле бер урынга кадәр сул аякта сикереп барырга;

6) кечкенә тупны агач кашык эченә салып, тупны төшерми генә, кашыкны тотып барырга;

7) уенчык чиләккә 2–3 стакан чамасы су салып, тулы көенчә, чайкалдырмый, суны түкми алып килергә;

8) баш түбәсенә фанера куеп, аны кул белән тотмый гына, билгеләнгән урынга кадәр барырга һ. б.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче һәр балага көченнән килерлек бирем сайлый: зуррак, көчлерәк һәм җитезрәк балаларга кыенрак биремнәр, ә кечкенәләргә, әкренрәк балаларга җиңелрәк биремнәр бирелә.

• Бер бала биремне үтәгәндә, калган балалар урындыкка яки үлән өстенә утырып, аны күзәтеп торалар.

## Коткаручы таяк

Бер бала әйдәүче (уенны алып баручы) итеп билгеләнә. Ул, битен куллары белән каплап, уйнаучыларга арты белән стена кырыена баса. Аның янында коткаручы таяк ята. Әйдәүче

15–20 гә кадәр саный, бу вакытта башка балалар качалар. Әйдәүче, санап бетергәч, күзен ачып, таяк белән тукылдата-тукылдата: «Таяк килде, беркемне дә тапмады!» – ди һәм качкан балаларны эзләргә китә. Әйдәүче берәр баланы күрү белән, ул да, бала да, берсен берсе куып, коткаручы таяк янына йөгерешеп киләләр. Кем беренче килеп җитә, шул таяк белән тукылдата. Әйдәүче таяк янына беренче килеп җитсә, табылган баланың исемен әйтеп: «Коткаручы таяк Алмазны тапты!» – ди. Әгәр эзләп табылган бала таякны беренче килеп тукылдатса, ул: «Коткаручы таяк, коткар мине!» – ди. Әйдәүче балаларны эзләгән вакытта, һәр качкан бала, уңайлы моментны сайлап, таяк янына йөгереп килеп, аның ярдәмендә котылырга тырыша. Әйдәүче һәрвакыт йөгерүче баланы узып, таяк янына беренче булып килергә тырыша. Әгәр качкан баланың иң соңгысы таяк янына әйдәүчедән алда йөгереп килеп җитсә ул: «Коткаручы таяк, барыбызны ды коткар!» – ди. Мондый очракта әйдәүче үз ролен яңадан үти. Әгәр таяк янына әйдәүче алдан килеп җитсә, ул вакытта коткарыла алмаган балаларның беренчесе киләчәк уенда коткаручы була.

## Тычкан тозагы

Балалар ике төркемгә бүленәләр: бер төркем балалар түгәрәк ясап басалар, бу – «тычкан тозагы». Икенче төркем балалар түгәрәк тышында кала, алар «тычканнар» булалар.

Түгәрәктәге балалар, бер-берсенең кулларыннан тотып, түгәрәк буйлап йөриләр һәм такмаклыйлар:

Теңкәбезгә тиделәр бит,
Эх, бу явыз тычканнар,
Шулкадәр күп үрчегәннәр,
Кайдан гына чыкканнар.
Һәрнәрсәне кимерәләр,
Һәрнәрсәне ашыйлар,
Һәрбер җиргә керәләр дә
Бар әйберне ташыйлар.

Карагыз аны сез, юлбасарлар,
Сезнең койрыкка тиз басарлар.
Менә хәзер без корабыз тозак,
Яшәтмәбез сезне бик озак.

Такмак беткәч, балалар туктыйлар һәм тотынышкан кулларын югары күтәрәләр. Тычканнар тозак (түгәрәк) аша йөгереп керә башлыйлар. Тәрбиянең «шап» диюенә балалар кулларын төшерәләр, һәм тычкан тозагы шапылдап ябыла. Түгәрәк эченнән чыгарга өлгермәгән бала тотылган исәпләнә һәм вакытлыча уеннан чыга. Уен 2–3 тапкыр үткәрелә. Аннан соң төркемнәр алмашыналар.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Уенны кабатлаганда, икенче куплетның текстын әйтү белән чикләнергә мөмкин.
- Кайсы төркем күбрәк тычкан тота, шул җиңүче була.

## Кем ераграк ыргыта?

Уйнаучылар 2 яки 3 рәткә тезеләләр. Мәйданның киңлегенә карап, һәрбер рәттә 7–8 кеше була. Беренче рәттә басып торучыларның кулларында туп. Алар, тәрбияченең «Башлагыз!» дигән сигналына карап, кулларындагы тупларын ыргыталар. Ераграк ыргыткан бала мактала. Тупны ыргыткан балалар туплары артыннан йөгереп баралар да аны артларында торучыларга бирәләр.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Нинди ераклыкта ыргытуны белү өчен, уйнаучылар алдындагы җирдә 2–3 метр ераклыкта берничә сызык сызып куела.
- Уң һәм сул кул белән ыргытырга кирәк.
- Уен 4–6 тапкыр кабатлана.

## Флагны кем тизрәк алыр?

Мәйданчыкта, уен өчен билгеләнгән махсус урында, бер рәткә кыршаулар салына (саны урынның зурлыгына карап билгеләнә). Балалар, кыршау санына карап, төркемнәргә бүленәләр, кыршаулары янына колонналап тезеләләр. Кыршауларның икенче ягына, каршыга, берәр флаг салына. Тәрбияченең сигналы буенча, һәр колоннада беренче булып басып торган балалар, кыршаулар янына барып, аларны җирдән алалар һәм бер аяклары белән тезләнеп, кыршауны җиргә терәтеп торалар.

Тәрбияченең «Бер, ике, өч, йөгерегез!» дигән сүзенә колоннада беренче булып басып торган балалар алга йөгерәләр һәм, кыршау аркылы чыгып, җирдәге флагны күтәрәләр. Флагны беренче күтәргән бала уенда беренчелекне ала. Аннан соң, флагларны куеп, кыршау тотучы балаларны алмаштыралар, ә бу балалар колонналарның ахырына басалар.

*Уенга күрсәтмә*

• Уенны бераз катлауландыру өчен, тагын бер тоткарлыктан үтү кертергә мөмкин, мәсәлән, озынлыкка яки биеклеккә (бау аркылы) сикерү.

## Оясыз күке

Уйнаучыларның барысы да «кош» булып кыланалар, һәрберсенең аерым сызып ясалган «оялары» була. Оясыз бер бала читтә басып тора, ул – «күке».

Тәрбияче: «Кошлар очтылар», – дигәч, кошлар ояларыннан чыгалар да теләсә кайда очып йөриләр. Күке дә алар белән бергә оча. «Өйгә!» дигән сүзгә барысы да (күке дә) ояларга таба оча башлыйлар, үзләренә оя алып калырга тырышалар. Оясыз калган бала «күке» була.

*Уенга күрсәтмә*

• Уенның эчтәлеген аңлатканда, тәрбияче ни өчен күкенең үз оясы булмавын, ни өчен ул күкәйләрен башка кошларның

ояларына салуы турында әңгәмә кора ала. Балаларда күке турында начар фикер калмасын өчен, «Күкенең хәтере бик начар икән, ул шуңа күрә үз балаларын үзе үстерә алмый, гомере буе аларны эзләп йөри икән», – дияргә мөмкин.

## Куяннар һәм аучылар

Санамыш ярдәмендә ике бала «аучы» итеп билгеләнә. Калган балалар «куяннар» булалар. Аучылар мәйданчыкның төрле урыннарында таралып йөриләр. Куяннар мәйданчык буйлап йөгерешәләр, сикерәләр. Тәрбияченең «Аучылар!» дип әйтүенә, куяннар теләсә нинди торышта катып калалар һәм шул килеш селкенмичә торалар. Аучылар туктап калган урыннарыннан куяннарга аталар – аларга кар йомарламнары ыргыталар. Аучы кемгә карны тидерсә, шуны, үзе белән алып китеп, билгеле бер урынга (читлеккә) утырта. Уен 2–3 тапкыр кабатланганнан соң, һәр аучының ничә куян атканлыгы санала. Аннан соң, яңа «аучылар» сайланып, уен яңадан кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Бу уен күбрәк урамда, саф һавада уйнала. Бүлмәдә уйнаганда, уенның шартларын бераз үзгәртергә мөмкин: катып калган куянның кайсысы беренче булып селкенә, аучылар шуны тоткан булып санала.
- Кар йомарламнары каты булмаска тиеш.

## Чыпчыклар һәм мәче

Зур түгәрәк сызыла (диаметры 5–6 м). Түгәрәкнең уртасында «мәче» тора. Бу – аның «өе». Ул үз янына берәр «чыпчык» очып килмәсме дип көтеп утыра. Ә чыпчыклар түгәрәкнең аргы ягында сикерәләр, уйныйлар, орлык чүплиләр. Аларның түгәрәк эченә дә керәселәре килә, ләкин мәченең тотуыннан куркалар.

Мәче йоклаганга салышып утыра. Чыпчыклар шатланалар,

түгәрәк эченә кереп, мәче тирәсендә сикерешәләр. Кинәт мәче чыпчыкларны эләктереп ала. Чыпчыклар чыелдашып качарга тырышалар.

Мәче алдан сөйләшкән санда чыпчыкларны тотканга кадәр, уен шулай дәвам итә. Уен кабатлана, тотылмый калган чыпчыклар арасыннан яңа «мәче» сайлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Түгәрәк уртасына мәче йоклагач кына керергә.

• Чыпчыкларны түгәрәкнең тышкы ягында булганда тотарга ярамый.

• Тотылган чыпчыкларны җибәрәләр, ләкин ничә чыпчык тотканын мәче санарга тиеш.

• 5–6 чыпчык тотылгач, икенче «мәче» сайлана.

## Хоккей уены

Бу уен өчен кардан чистартылган тигез урын, бер хоккей таягы (кәшәкә) һәм кечерәк резин туп кирәк. Уйнаучылар арасыннан бер әйдәүче сайлана, аңар туп һәм кәшәкә бирелә.

Сигнал булуга, балалар мәйдан буйлап йөгерешеп китәләр. Әйдәүче бала, кәшәкә белән тупны тәгәрәтеп, аны йөгерүче балаларның аякларына тидерергә тырыша. 2–3 баланың аягына туп тигәч, аякларына туп тимәгән балалар арасыннан яңа әйдәүче сайлана, һәм уен дәвам итә.

Әгәр уйнаучылар күп булса яки кәшәкә белән яхшы уйный белмәсәләр, ул вакытта уенга ике әйдәүче сайлана һәм аларга ике кәшәкә, ике туп бирергә мөмкин.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уен үткәрелә торган урын тайгак булмаска тиеш.

• Уен өчен гади резин туп бирелә, чөнки хоккей тубы (шайба) балаларның аягын авырттырырга мөмкин.

• Балалар саны күп булганда, уен берничә төркемгә бүлеп уйналына, чөнки уйнаучылар күп булса, хәрәкәтләнергә тыгыз һәм җайсыз була.

• Әйдәүчене баштарак, балалар уенга яхшы төшенеп җитмәгәндә, ешрак алмаштырырга кирәк.

• Уенга төшенеп җиткәннән соң, яңа кагыйдәләр һәм яңа биремнәр кертергә мөмкин, мәсәлән, тупны чокырга төшерү; бер тапкыр бәрү белән, аны билгеле сызыктан тәгәрәтү һ. б.

## Туп кайда?

Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана. Балалар түгәрәккә басалар. Алып баручы уртада басып тора. Уйнаучылар, алып баручыга сизелмәслек итеп, арттан туп бирешәләр. Әгәр алып баручы тупның кемдә икәнен сизсә, аның янына килеп: «Кулларыңны күрсәт», – ди. Әлеге бала, учларын өскә каратып, кулларын югары күтәрә. Әгәр аның кулында туп булса (яки ул тупны төшереп җибәрсә), уен тәмам була. Әгәр туп анда булмаса, ул кулларын яңадан артка куя, һәм уен дәвам итә. Туп белән 2–3 бала тотылгач, алып баручы алышына.

## Козгын һәм чебиле тавык

Санамыш ярдәмендә «козгын» һәм «чебиле тавык» билгеләнә. Калган балалар – «чебиләр». Чебиле тавык үзенең чебиләре белән мәйданчыкның (бүлмәнең) бер ягында, ә козгын икенче ягына урнаша. Чебиләр бер-бер артлы, берберсенең билләренә тотынышып, тавык артыннан колонна булып тезеләләр. Тәрбияче сигналы буенча, козгын килеп чыга һәм чебиләрнең иң арттагысын тотарга тырыша. Чебиле тавык, канатларын җәйгән шикелле итеп, кулларын янга сузып, чебиләрне тоттырмаска тырыша. Козгын арттагы бер чебине тота. Берничә чеби тотылганнан соң, уен бетә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны аз санда гына булган балалардан төзелгән төркемнәр белән үткәрергә мөмкин, чөнки чебиләргә бер-бер артлы тотынып йөрү читен була.

• Чебиле тавык, чебиләрен козгыннан саклаганда, козгынны кулы белән тотмый, бәлки, кулларын җәеп, тотарга комачаулый гына.

• Уенны музыка белән дә үткәрергә мөмкин.

## Күбәләк тоту

Уенда катнашучылар – очып йөрүче бөҗәкләрне гәүдәләндерүче балалар – мәйданчыкның төрле җирләрендә йөриләр. Дүрт бала, ике пар булып, кулга-кул тотынышып, мәйданчыкның бер башына барып басалар. Алар – бөҗәк тотучылар. Уенда катнашучыларның һәрберсе, үзе нинди бөҗәк булырга теләсә, шуны сайлый (чебен, күбәләк, коңгыз һ. б.). Бөҗәкләр мәйданчык буйлап йөриләр. Тәрбиячченең «Бөҗәк тотучылар!» дигән сигналын ишетү белән, ике бала кулга-кул тотынышып йөгереп чыга һәм очраган бер бөҗәкне камап алып тотарга тырыша (кара-каршы тотынышып, бөҗәкне уртада калдыралар). Тотылган бөҗәкне бер читкә илтеп куялар – «тартмага урнаштыралар». Уйнаучыларның берсе тотылу белән, бөҗәк тотучыларның икенче пары чыга (беренче пар бу вакытта ял итә). Уен шулай дәвам итә.

Уен ахырында ничә һәм нинди бөҗәкләр тотылганы санала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Бөҗәкләрне кул белән тотмыйча, әйләндереп, камап алырга кирәк.

• Тәрбияче тотучыларның артык күп йөгермәүләрен күзәтә. Бөҗәк тотучыларның бер пары бөҗәкләрне озак тота алмый йөгерсә, аларга булышырга икенче пар килә.

## Тупны тотып ал!

Уенда катнашучы балаларның өчтән бер өлеше түгәрәк эчендә кала, калган балалар түгәрәкләнеп тезеләләр.

Түгәрәккә тезелгән балалар тупны бер-берсенә (каршы як-

тагы балаларга) ыргыталар. Ә түгәрәк эчендәге балалар тупны тотып алырга тырышалар. Әгәр кем дә булса тупны тотып алса, ул, түгәрәккә басып, туп ыргытуда катнаша башлый. Түгәрәк эчендәге балаларның күпчелеге түгәрәккә тезелеп беткәч, уен тәмамланган булып санала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче уен башында тупны ничек тотарга һәм ничек ыргытырга икәнен күрсәтә.

• Тупны кем тотып ала, шул икенче кешегә ыргыта.

• Бер-берсенә ыргытканда туп җиргә төшсә, туп уң ягына төшкән бала аның артыннан йөгерә.

## Бозларны тизрәк керт

Уен өчен төрле боз кисәкләре һәм кәшәкә (хоккей таягы) кирәк булачак. Балалар төркемнәргә бүленәләр. Төркем санына карап, уен үткәрелә торган урынга 3–4 түгәрәк сызыла. Төркемнәр түгәрәкләрдән 15–25 адым ераклыкта ярымтүгәрәк булып тезеләләр. Һәр балага кәшәкә һәм төсле бер боз кисәге бирелә.

Сигнал булгач та, балалар таяклары белән үзләренең бозларын каршыларындагы түгәрәкләренә тизрәк кертергә тырышалар.

Бозларын түгәрәкләргә башкалардан алда кертеп бетергән төркем беренчелекне ала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Һәр төркемнең бозлары билгеле бер төскә буялган булырга тиеш.

## Тупны җибәрмә!

Балалар, бер-берсенә кул сузарлык ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр дә кулларын артка куеп, җилкә киңлегендә аякларын аерып басалар. Әйдәүче түгәрәк уртасына керә һәм тупны кайсы да булса бер уйнаучының аяк арасыннан тәгәрәтеп

җибәрергә тырыша. Туп үзенә таба тәгәрәп килгән бала, аякларын тиз генә янәшә куеп, аны аяклары арасыннан чыгармаска тиеш. Тупны аяк арасыннан үткәргән бала түгәрәктән бер адым артка китә. 2–3 бала тупны аяклары арасыннан җибәргәч, уен тәмамланган санала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Әйдәүче тупны бер балага җибәргән булып күренергә, чынлыкта исә бөтенләй башка якка яки башка балага җибәрергә мөмкин.

• Башта тәрбияче үзе әйдәүче булырга тиеш.

## Боҗраны кидер!

Җиргә кечкенәрәк таяк (биеклеге 30 см, юанлыгы 3 см) кагып кертелә.

Шуннан, берникадәр ераклыкта ара калдырып, сызык үткәрелә. Уйнаучылар сызык артына тезелеп басалар. Беренче уйнаучының кулында 3–5 серсо боҗрасы була. Ул боҗраларны таякка кидерергә тырышып ыргыта, аннан соң аларны җыеп ала да икенче балага бирә. Уйнаучылар боҗраларны, уң куллары белән ыргытып, таякка кидерергә тырышалар. Боҗраларны таякка кем күбрәк кидерә ала, шул бала бәяләнә.

## Әйберне сакла!

Балалар, аякларын аерып басып, кулларын артка куйган хәлдә, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала түгәрәкнең уртасында тора. Һәр баланың алдында нинди дә булса берәр уенчык ята. Әйдәүче балалар алдындагы уенчыкны алырга тырыша, ә балалар ул килә башлагач чүгәлиләр дә аны куллары белән каплыйлар. Әйдәүче читкә китү белән торып басалар һәм кулларын артка куялар. Уенчыгын алдырган бала түгәрәктән арткарак чигенеп китә (уенчыгын саклап кала алса, кире урынына кайта). 2–3 бала әйберен алдыргач, яңа әйдәүче сайлана. Уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Әйдәүче яшергән әйберне балаларның кулыннан тартып алмаска тиеш.

• Әйдәүче якында булмаганда, балалар һаман бөкрәеп тормасын.

• Әйдәүченең уенчыгын саклый алмаган (түгәрәктән артка чигенгән) балалар янына да килүен тәрбияче күзәтергә тиеш.

## Мәче һәм тычканнар

Уенчылар арасыннан 5–6 бала – «тычкан», бер бала «мәче» итеп билгеләнә. Калган балалар түгәрәкләнеп басалар. Мәче түгәрәкнең уртасына, тычканнар тышына басалар. Балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:

Безнең мәче бигрәк ак,
Койрыгы да бик йомшак,
Үзе тагын бик җитез,
Тычканнарны тота тиз.
Тычканнарны күрү белән,
«Шып» итеп килеп җитә,
Зирәк мәче монда чакта,
Тычканнарга көн бетә.

Җырның соңгы сүзләрен әйтү белән, балалар җитәкләшәләр һәм кулларын ычкындырмыйча югары күтәрәләр – «капкалар» ясыйлар. Мәче исә, капкалар аркылы йөгереп йөреп, тычканнарны тота башлый. Тычканнар, түгәрәк эченә бер кереп, бер чыгып, мәчедән качалар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тычканнарны тоту белән, уен беткән булып санала.

• Тычканнарны түгәрәкнең эчендә дә, тышында да тотарга мөмкин.

## Инеш аркылы

Уен үткәрелә торган урынның уртасына «инеш» – борылмалы ике сызык үткәрелә: төсле буяулы ике бау сузып салына, яки «инеш»не төсле, юка, озын төзү материалларыннан ясыйлар. Ике сызыкның арасы 40–60 см киңлегендә була. Балалар йөрергә чыккан булалар, аларга юлда инеш очрый, алар бөтенесе яки төркемләп (әгәр урын тар булса) рәткә тезелеп басалар, шушы урыннан торып яки йөгереп, инеш аркылы сикереп чыгалар. Инешне чыгып яланга күчкәч, балалар таралып, йөгереп уйныйлар. Балалар уйнаган арада, тәрбияче инешнең читләрен киңәйтә (инеш яңгырдан соң 50–70 см га киңәйде). Сигнал булуга, балалар яңадан инеш янына җыелып, су буйлап тезеләләр һәм яңадан аны икенче якка аркылы сикереп чыгалар. Ниһаять, тәрбияче, балалар сикереп чыга алмастай итеп, инешне тагын да киңәйтә төшә һәм аның аркылы, бераз гына күтәртелеп, киң такта салына (күпер ясала): балалар инештән шушы күпер аркылы яланга чыгалар һәм нинди дә булса тыныч уен уйныйлар яки җыр җырлыйлар.

## «Җитезләр мәктәбе»

Уен 3–4 бала белән уйнала. Балалар бер рәткә тезелеп басалар. Һәр бала алдына 40х40 см лы 5 шакмак сызып куела. Һәр шакмак бер сыйныфны аңлата. Бу «җитез балалар мәктәбе» була. Бу мәктәпкә керүче һәрбер бала тәртип буенча рәттән 5 биремне үтәргә тиеш. Беренче биремне үтәгән бала 1 нче сыйныфка кабул ителә, әгәр икенче биремне үти алса, ул 2 нче сыйныфка күчә һ. б.

«Җитезләр мәктәбе» өчен алдан түбәндәге биремнәр әзерләнә:

1 нче сыйныф – 1,5–2 метр озынлыктагы тигез сызык буйлап аяк белән читкә чыкмыйча үтәргә кирәк.

2 нче сыйныф – монда бер аяк өстендә сикерергә һәм, шакмаклардан үтми торып, ике аякка басмаска (барлык озынлыгы 2 метр).

3 нче сыйныф – 1 нче сыйныфтагы кебек, сызык буйлап барырга кирәк. Барганда, кул учында (учны җәеп торкан хәлдә) туп яки шар тотып, аны төшерми үтәргә кирәк.

4 нче сыйныф – соңгы шакмакка төшәрлек итеп, таш ыргытырга.

5 нче сыйныф – 1,5 метр ераклыктан тартмага бер тапкыр сул кул белән, икенче тапкыр уң кул белән туп ыргытырга.

Балалар бөтен сыйныфлар аркылы чиратлап үтәләр. Мәктәпне беренче тәмамлаучы иң җитез бала була һәм ул, уенны кабатлаганда, «укытучы» була, ягъни һәр сыйныфта нәрсә эшләргә кирәклекне беренче күрсәтә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны барлык балалар да 1 нче сыйныфтан башлыйлар. 1 нче сыйныфны уңышлы үткән бала 2 нче сыйныфка күчә, 2 нче сыйныф аркылы үтүче 3 нчегә күчә һ. б. Ялгышканга кадәр яки бөтен сыйныфларны үтеп беткәнгә кадәр шул рәвештә дәвам итә.

• Әгәр бала ялгышса, үз сыйныфына әйләнеп кайта.

• Уенны тизләтү өчен, параллель сыйныфлар яки ике мәктәп ясарга мөмкин. Уенны болай үткәргәндә, һәр мәктәпкә аерым «укытучы» билгеләргә кирәк, ул кемнең 2 нче сыйныфка күчүен, кемнең шул ук сыйныфта калуын һәм, үз чираты җиткәч, яңадан уйнарга тиеш булуын күзәтергә һәм хәл итәргә тиеш.

• Бу уенга, кыршаулар, шарлар, туплар белән хәрәкәтләнү өчен, бик күп кызыклы биремнәр кертергә мөмкин.

• Төрле биремнәр кертеп, уенны төрлеләндерергә һәм балаларның үсеш дәрәҗәләренә һәм кызыксынуларына карап катлауландырырга мөмкин.

• Үрнәк өчен түбәндәге биремнәрне тәкъдим итәргә була:

1) Кыршауны бер этәреп җибәрү белән, этәрүчедән 2–3 метр ераклыктагы сызыкка тәгәрәтеп җиткерергә.

2) Кыршауны, читкә чыгармый, тар юлдан (арасы 10–20 см ераклыктагы ике сызык арасыннан) тәгәрәтергә.

3) Кыршауны аудармыйча тәгәрәтеп барганда, урындыкка куелган флагны ала китәргә.

4) Шарны чокырга тәгәрәтеп төшерергә.

5) Бер җиргә өелгән шарларны бер тапкыр шар бәрү белән таратырга һәм чокырга тәгәрәтеп төшерергә (тәгәрәтергә, ә ыргытырга ярамый) һ. б.

## Табышмаклы уен

Берничә бала – табышмак әйтүче, ә калганнары җавап табучы була.

Табышмак әйтүчеләр, бер читкә китеп, үзләренең хәрәкәтләре белән нәрсәне гәүдәләндерәчәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән, барысына да берьюлы урманда җиләк җыюны, бакчада түтәлләр казуны, чәчәкләргә су сибүне һ. б.ны күрсәтергә мөмкин.

Нәрсә күрсәтү турында сүз куешканнан соң, барысы да җавап табучылар янына баралар һәм исәнләшәләр:

– Исәнмесез, балалар!

– Исәнмесез! Сез кайда булдыгыз?

Балалар үзләренең табышмакларына бәйләнешле җавапны (мәсәлән, урманда булганлыкларын) хәрәкәтләр белән күрсәтәләр. Җавап табучылар, дөрес җавап биргәннән соң, сорау бирәләр:

– Сез анда нәрсә эзләдегез?

Табышмак әйтүчеләр җиләк җыюны хәрәкәтләр ярдәмендә уйнап күрсәтәләр. Әгәр җавап табучылар табышмакка җавап таба алсалар, табышмак әйтүчеләр алар яныннан йөгерешеп китәләр, ә җавап табучылар аларны куалар. Әгәр табышмакның җавабын белә алмасалар, беренче төркем балалар яңадан табышмак әйтергә баралар.

Тотылган бала үзен тоткан балалар төркеменә күчә. Аннан соң рольләр алмашына – табышмакка җавап табучылар хәзер инде үзләре табышмак әйтүче булалар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тотучылардан котылу өчен, балалар алдан сызык белән билгеләнгән өйләре янына йөгерәләр.

• Табышмакның җавабын табарга мөмкин булсын өчен, хәрәкәтләрне дөрес күрсәтергә кирәк.

• Табышмакны тапканчы йөгереп китәргә дә, тотарга да ярамый. Сызыкка килеп җиткәнче генә тотарга мөмкин.

• Уенны өйрәнеп беткәнче, баштарак табышмак һәм хәрәкәтләр сайлауда балаларга ярдәм итәргә кирәк. Аннан соң әкренләп балалар үзләре дә хәрәкәтләрне уйлап чыгара башлыйлар.

## Кыршаулар белән уеннар

**1. Кыршауларны түгәрәктә тәгәрәтү**

Тәрбияче, түгәрәк уртасына баскан хәлдә, балаларга таба кыршауны тәгәрәтә. Балалар кыршауны кире тәрбиячегә таба чиратлап тәгәрәтәләр.

Уенны катлауландыру өчен, бер-бер артлы ике кыршауны тәгәрәтергә мөмкин.

**2.** Балалар ике төркемгә бүленәләр, арада зур гына буш урын калдырып, кара-каршы басалар. Бер төркем балаларның кулларында кыршаулар. Тәрбиячененң «Бер, ике, өч!» диюенә яки башка берәр сигнал буенча, балалар кулларындагы кыршауларны үзләренә каршы баскан балаларга тәгәрәтәләр. Уен шул рәвештә берничә тапкыр кабатлана.

**3. Кыршауларны алмашу**

Бу уен югарыда күрсәтелгән уен шикелле үк үткәрелә, тик монда уенда катнашучыларның һәрберсенә кыршау бирелә һәм һәр бала кыршауны үзенең каршысындагы балага (парына) тәгәрәтеп җибәрә. Кара-каршы баскан ике бала бер үк вакытта кыршауларын бер-берсенә тәгәрәтәләр. Кыршаулар каршы килеп бәрелмәсеннәр өчен, һәр бала үз кулындагы кыршауны уң кулы белән тәгәрәтергә тиеш.

**4. Кыршауны кем ераграк тәгәрәтер?**

Уенга катнашучылар барысы да бер сызык өстенә басалар һәм, тәрбияче сигнал бирүгә, кулларындагы кыршауларны тәгәрәтәләр. Кемнең кыршавы ераграк тәгәрәсә, тәрбияче шул баланы искә ала.

**5. Куышып узышу**

Ике станция билгеләнә. Тәрбияче сигналы буенча, бер станциядән «велосипедлар» (кыршау тәгәрәтүче балалар) чыгалар һәм, куышып, тизрәк икенче станциягә җитәргә тырышалар. Бу куышу 2–3 бала һәм шулай ук 10–12 бала арасында да булуы мөмкин. Шул ук уенны уйнаучыларны бер рәткә тезеп тә үткәрергә була.

**6. Тимер юл**

Озын туры сызык – «тимер юл» сызыла. Бу юлдан «поездлар» йөриләр. Тәгәрәтеп җибәрелгән кыршау шушы сызыктан гына барырга тиеш. Сызыктан читкә чыккан кыршау «ремонтка» бирелә – юлдан кире кайтарыла.

**7. Юлда барганда шалтырат!**

*1 нче вариант.* Уенга катнашучы балаларның һәрберсе җиргә сызылган түгәрәккә бер-берсеннән 1 м чамасы ераклыкта ара калдырып басалар. Алда 2–3 метр чамасы ераклыкта бауга тагылган кыңгырау була. Кыршауны тәгәрәтеп баручы һәр бала, бу бау астыннан үткәндә, кулы белән бауга тотынып, кыңгырауны шалтыратып үтә. Бу шалтырату артта баскан балага кыршавын тәгәрәтеп йөрергә мөмкинлекне белдергән сигнал була – балалар бер-бер артлы, кыршауларын тәгәрәтеп, кыңгыраулы бау астыннан чыгалар.

Балаларга төрле төстәге тасмалар тагылган матур кыршаулар бирелә. Тасмаларга кечкенә кыңгыраулар тагылса бигрәк тә яхшы.

Уенда катнашучы барлык балалар зур түгәрәк ясыйлар – басалар да кыршауларын җиргә бастырып куялар (кабыргасы белән). Тәрбияче сигнал бирүгә, барлык балалар, баскан

урыннарыннан кузгалмыйча, кыршауларын бергә әйләндереп җибәрәләр. Кемнең кыршавы аумыйча озак әйләнеп торса, шул бала искә алына һәм ул, уенны яңадан кабатлаганда, сигнал бирүче була.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны башлап җибәргәнче, тәрбияче балаларга кыршауны ничек итеп әйләндереп җибәрергә (бер урында бөтергеч шикелле) кирәклекне күрсәтә.

*2 нче вариант.* Югарыда күрсәтелгәнчә бизәкләнгән бер зур кыршау алына. Балалар түгәрәкләнеп басалар, ә тәрбияче, кыршауны тоткан хәлдә, түгәрәк уртасына баса. Тәрбияче кыршауны бөтергеч шикелле әйләндереп җибәрә дә шулвакытта түгәрәккә баскан балалардан берсенең исемен әйтә. Чакырылган бала түгәрәкне йөгереп әйләнә һәм, әйләнүдән туктап, кыршау ауганчы, аны тотып өлгерергә тиеш. Әгәр бала кыршау ауганчы аны тотып өлгерсә, уенны кабатлаганда, бу бала, кыршауны тотып алу өчен, үзе теләгән баланы сайлый. Әгәр бала кыршау ауганчы тотып өлгермәсә, ул яңадан үз урынына барып баса, һәм түгәрәктән икенче баланы тәрбияче үзе чакырып чыгара.

## Гөр-гөр

Уенда дүрт бала катнаша. Аларның берсенең муенына кечкенә кыңгырау тагыла, ә калган өчесенең күзләрен бәйлиләр. Идәнгә зур түгәрәк сызыла. Уйнаучылар түгәрәккә тезелеп басалар. Кыңгырау тоткан бала урталыкта йөгереп йөри, ә күзләрен бәйләгән балалар, кыңгырау тавышы буенча, аны куып тотарга тырышалар. Кыңгырау таккан бала тотылгач, яңа уйнаучылар сайлана.

*Уенга күрсәтмә*

• Уенны башлаганчы, аның кагыйдәләрен аңлатырга кирәк: кыңгыраулы бала түгәрәктән читкә чыкмаска тиеш;

күзләре бәйләнгән балалар кыңгырау тавышы буенча гына хәрәкәтләнәләр (яулыкны ачып карарга ярамый).

## Бау (сикергеч һ. б.) белән уеннар

Бу уеннарны балаларга түбәндәгечә биремнәр бирү рәвешендә үткәрергә мөмкин:

1. Ике аяклап бер урында сикерү – санап һәм санамыйча.
2. Ике аяклап сикерә-сикерә, алга таба бару.
3. Санамыйча һәм санап, бер аякта сикерү.
4. «Кем күбрәк өзеп алыр?»

Балаларның куллары җитәрлек итеп сузылган бауга төрле озынлыктагы кәгазь тасмалар тагыла. Балалар, бау астыннан йөгереп үткәндә, бу тасмаларны сикереп өзәләр һәм алып китәләр. Тасмалар алынып беткәч, кайсы балада күпме тасма барлыгы санала, иң күп санда тасма алып өлгергән баланы тәрбияче билгеләп китә.

5. Бауны баланың тезе биеклегендә сузып, аңа кыңгырау бәйләргә мөмкин. Балалар, йөгереп килеп, кыңгырауга кагылмаска тырышалар, бау астыннан үрмәләп үтәләр.

## Почмак алыш

Уйнаучылар җиргә сызылган түгәрәкләр эченә («почмакларга») басалар.

Уйнаучыларның берсе почмаксыз кала. Ул, түгәрәк эчендә басып торучыларның берсе янына килеп: «Тычкан, тычкан, почмагыңны миңа бир!» – ди. Бала почмагын бирми. Аннан соң ул, икенче бала янына барып, шул ук сүзләрне кабатлый. Калган балалар бу вакытта тиз генә урыннарын алмашалар, ә уртада торучы бала шул арада йөгерүчеләрдән берсенең урынын алып калырга тырыша. Әгәр ул урынны ала алса, «почмак»сыз калучы бала уртага чыгып баса, һәм уен дәвам итә.

Әгәр уртадагы бала почмакны озак вакыт ала алмаса,

тәрбияче: «Мәче килә!» – дип кычкыра. Шулвакытта барысы да берьюлы, түгәрәк буенча уңга таба йөгереп, түгәрәктән түгәрәккә күчәләр, ә уртада торучы бала шул арада берәрсенең урынын алып калырга тырыша.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Урынны алмашырга теләүчеләр тавыш-тынсыз гына үзара алдан килешәләр (күз кысышалар, ым кагалар һ. б.).

• Урын алмашу турында аңлашкач, тиз генә йөгереп китәргә кирәк.

## Узышчылар

Һәр бала узышырга үзенә пар (иптәш) сайлый. Парлылар бер-бер артлы тезеләләр. Кая кадәр йөгерәчәкләре алдан билгеләнә (бу урынга флаглар яки нинди дә булса уенчык куела). Барлык уйнаучылар берьюлы: «Бер, ике, өч!» – дип саныйлар. Санап бетерүгә, иң алга баскан беренче пар тиз генә йөгереп китә, билгеләнгән чиккә кадәр барып, тизрәк кире әйләнеп кайтып җитәргә тырыша. Парлап йөгерүче балалар бер-берсен узарга тырышалар. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, тәрбиячнең сигналыннан соң икенче пар йөгерә һ. б. Барысы да икешәр тапкыр узышканнан соң, яңа парлар билгеләнә, һәм уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Балалар бары тик сигналдан соң гына йөгерергә, билгеләнгән чиккә барып җиткәннән соң гына борылып кайтырга тиешләр.

• Башта балалар үзләренә иптәшне (парны) теләкләре буенча сайлыйлар, ләкин уенны кабатлаганда тәрбияче парларның көчләре ягыннан тигез булуларын исәпкә алырга тиеш була.

• Әгәр, уйнаучылар күп булып, чират көтеп тору артык озакка сузылса, балаларны ике рәткә тезеп, берьюлы ике парны узыштырырга мөмкин. Кайвакыт барлык балаларны берьюлы узыштырырга мөмкин, уенны бу рәвештә оештыру балаларны тагын да җанландырып җибәрә.

## Буш урын

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Балалардан берсе әйдәүче булып сайлана, ул, кулына яулык алып, түгәрәкнең тышкы ягына чыга. Калган балалар, түгәрәкләнеп, идәнгә утыралар. Әйдәүче бала түгәрәкнең тышкы ягында йөри һәм берәр баланың җилкәсенә кагыла. Әлеге бала тиз генә урыныннан торып, әйдәүчегә каршы түгәрәк буйлап (уң якка таба) йөгереп китә. Әйдәүче, буш урынны алдан алып калырга теләп, теге баланың каршысына йөгерә. Бушаган урынга кем беренче килеп җитсә, шул утырып кала, ә урынсыз калган бала әйдәүче була.

*Уенга күрсәтмә*

• Түгәрәктә утыручылар артларына әйләнеп карамаска тиешләр; яулык белән сугылган бала уңга, ә әйдәүче сулга таба йөгерергә тиеш.

## Акула

Уйнаучылар арасыннан 2–3 «акула» сайлана. Калган балалар – «моряклар». Зур корабль өстендә (мәсәлән, кардан ясалган яисә тезелеп куелган урындыкларда) капитан (тәрбияче) басып тора. Ул диңгездә йөзүче морякларны күзәтә: алар корабльдән сикереп төшәләр һәм йөзгән кебек хәрәкәтләр ясап йөгерешеп йөриләр.

Бераз вакыттан капитан: «Акулалар!» – дип кычкыра. Моряклар тиз генә корабльгә менәләр, ә акулалар аларга ташланалар. Берәүне дә тота алмыйча яки, киресенчә, тотып, акулалар диңгез эченә (алдан билгеләнгән урынга) «йөзеп китәләр». Моряклар яңадан суга төшәләр. Уен берничә тапкыр кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Морякларны «Акулалар!» дигән сигналдан соң гына тотарга ярый.

• Акулалар корабль өстенә менмиләр.

• Акулалар тотылган баланы алдан билгеләнгән урынга – бүлмәнең бер читенә яки мәйданчыкның кырыена алып китәләр (бу чикне сызык сызып та билгеләргә мөмкин). Бу балалар уенга бер тапкыр катнашмый кала.

• Акулаларның морякларны аулау вакытын тәрбияче билгели (алдан сөйләшенгәнчә сигнал бирә ). Ул бик озак булмаска тиеш.

• Моряклар диңгезгә артык югары булмаган биеклектән генә (40 см тирәсе) сикереп төшәләр.

• Капитан ролен башта тәрбияче үзе, соңыннан балалар башкара. Балаларны уен арасында ял иттерү өчен, мондый өстәмә кертергә мөмкин: диңгездә бик каты давыл күтәрелә – акулалар диңгез төбенә качалар, ә моряклар корабльдә ял итеп утыралар, капитанның хикәя сөйләгәнен тыңлыйлар.

## Сәяхәт

Уйнаучы балалар өчәрләп-дүртәрләп төркемнәргә бүленәләр һәм «сәяхәткә» китәләр. Һәр төркем алдан кая һәм нәрсә белән бару турында (атта, поездда һ. б. да) килешә.

Сәяхәткә бару хәрәкәтләр ярдәме белән гәүдәләндерелә (бу вакытта мәйданчыктагы спорт җайланмаларын – гимнастика баскычын, трибуна, эскәмияләр һ. б. ны файдаланырга мөмкин). Көтмәгәндә сигнал тавышы ишетелә. Бу – радио белдерүе, ул сәяхәтчеләргә өйгә кайтырга вакыт икәнлекне хәбәр итә. Барысы да алдан әзерләнгән урындыкларына утырырга ашыгалар. Тәрбиячегә алар кая барулары, ниләр күрүләре, нәрсәгә утырып барулары турында сөйлиләр.

Һәр төркемдәге дүрт баладан берсе генә сөйли, барыннан да алда килгән төркемгә беренче сүз бирелә.

Аннан соң балалар тагын сәяхәткә бару турында сөйләшәләр, һәм уен дәвам итә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Бу уенны ачык һавада, иркен урында үткәрергә кирәк.

• Әгәр балалар күп булса, алар төркемнәргә бүленәләр, аз икән – һәр бала сәяхәткә үзе аерым бара.

• Сигнал булгач та, бик тиз җыелырга кирәк; башкалар эшләгәнне кабатламаска, һәр уйнаган саен, икенче урынга сәяхәткә баруны уйлап табарга; сөйләгәндә чират тәртибен сакларга кирәк.

## Аксак төлке

Санамыш ярдәмендә балаларның берсе – «Аксак төлке», икенчесе «өй хуҗасы» – «аю» итеп билгеләнә. Башка балалар, «тавыклар» булып, зур бер түгәрәк сызыкка кереп торалар. Аксак төлке «өненнән» чыгып, аксаклый-аксаклый (бер аягын күтәреп) сикереп килә һәм өй хуҗасы янында туктый. Аю белән Аксак төлке кара-каршы сөйләшәләр:

– Төлке, Төлке, Түләнтәй, төнлә кая барасың?

– Мамай улы Бикчәнтәй, әбиемә барамын.

– Әбиеңдә ниең бар?

– Мич артында туным бар.

– Туның янса нишләрсең?

– Суга илтеп салырмын.

– Туның акса нишләрсең?

– Үкереп елап калырмын.

– Төлке, Төлке, Түләнтәй, тунсыз ничек йөрерсең?

– Мамай улы Бикчәнтәй, йөргән чакта күрерсең.

Шулай әйтешкәннән соң, аю тынычланып «йокларга ята». Төлке, сыңар аяклап, тавыклар оясына керә дә аларны куа башлый. Куып җиткәненә кулы белән кагыла. Әлеге бала «аксак төлке» була.

*Уенга күрсәтмә*

• Аксак төлке, ялгышып, икенче аягы белән дә җиргә басса, хуҗа, күреп, аның үзен куа башлый. Әгәр төлке үз оясына җиткәнче тотылса, ул яңадан төлке булып уйнарга тиеш була.

## Аю һәм балалар

Балалардан берсе «аю» була. Ул үзенең «өн»ендә – махсус сызылган түгәрәк эчендә утыра. Уйнаучылар барысы да урманга җиләк яки гөмбә җыярга баручы балаларны гәүдәләндерәләр.

Көтмәгәндә тәрбияче: «Аю килә, селкенмәгез!» – ди. Балалар туктап калалар. Аю үзенең өненнән чыгып, һәрбер баланы җентекләп карап йөри. Селкенгәннәрне үзенең өненә алып китә. Барысын карап, тикшереп чыккач, аю өненә кайта. Балалар яңадан җиләк җыя башлыйлар.

Аю 4–5 баланы тоткач, уен тәмамлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Әгәр уен бинада үткәрелсә, балалар, аюдан котылу өчен, палас өстенә яталар.
- Әгәр уйнаучылар күп булса, ике «аю» сайларга мөмкин.

## Аучылар, куяннар һәм этләр

Балалар «куяннар» булалар һәм мәйданчыкның бер читендәге «оя»ларга (сызылган түгәрәкләргә) урнашалар. Ояларга каршы якта ясалган өйгә ике «эт» һәм «аучы» урнаша. Аучы, өеннән чыгып, куян үтеп бармый микән дип, як-ягына карана. Ул өенә кире кереп китә, ә куяннар тиз генә ояларыннан чыгалар һәм сикергәләп йөриләр. Аучының «Тотып ал!» дигән сүзен ишеткәч, этләр качып баручы куяннарны тотып алалар һәм тотылган куяннарны аучы өенә алып китәләр. Ә ояларына кереп качкан куяннарга тияргә ярамый. Алар теләсә кайсы ояга яшеренергә мөмкин. Алдан сүз куешканча, 4–6 куян тотылгач, уен бетә. Тотылмаган куяннар арасында яңа «аучы» һәм «эт»ләр сайлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Бу уенны саф һавада да, бүлмәдә дә үткәрергә мөмкин.

• Аучы ролен башта тәрбияче үзе үти, аннан соң берәр балага тапшыра.

• «Тотып ал!» дигән команданы бары тик тәрбияче генә бирә ала.

## Курыкмыйм!

Балалар кулга-кул тотынмый гына, түгәрәк ясап басалар. Бер бала «тотучы» итеп сайлана һәм түгәрәк уртасында басып тора. Калган балалар, кулларын әле як-якка җәеп, әле аркаларына куеп: «Курыкмыйм, курыкмыйм», – дип, ике аякта сикерәләр. Түгәрәк уртасында торучы бала, балалар кулларын як-якка сузган чакта, аларга тотынырга тырыша. Куллар аркага куелганда тотынырга ярамый. Уртадагы бала кемгә кулы белән тотынса, шул бала, уртага чыгып, «тотучы» була.

*Уенга күрсәтмә*

• Тотучы әйләнгән яки киткән арада, кулларны сузарга яки һаман кулны аркага куеп торырга рөхсәт ителми.

## Тупка бәреп тидер

Балалардан кем дә булса берсе зур тупны югарыга ыргыта. Бу вакытта калган балалар кечкенә туплары белән һавадагы тупка тидерергә тырышалар. Кем тупка тидерә алса, шул, зур тупны алып, уртага чыга һәм аны югарыга ыргыта.

*Уенга күрсәтмәләр*

• «Бер, ике, өч!» дигәннән соң гына, зур тупны һавага ыргыталар.

• Балалар төзәп атарга өлгерсеннәр өчен, зур тупны мөмкин кадәр югары ыргытырга кирәк.

## Куыш уены

Мәйданчыкның кара-каршы якларында ике озын сызык үткәрелә. Бу – «өйләр». Уйнаучылар өйләрнең берсенә (сызык артына) урнашалар. Уен урынының читендә, ике өй арасында, 1–2 тотучы басып тора. Өй эчендәгеләр түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без, шаяннар, яратабыз
Йөгереп, сикереп уйнарга,
Әйдә, безне куып кара,
Көчең җитсә тотарга,
Тот!

Соңгы сүзләрне әйткәч, балаларның барысы да, бу өйдән чыгып, каршыдагы өйгә йөгерәләр. Әйдәүчеләр йөгерүчеләрне куып тотарга тырышалар. Аннан соң икенче тотучылар сайлана, һәм уен яңадан башлана.

## II БҮЛЕК

# Уйнап күңел ачабыз

**Без уйныйбыз, уйныйбыз,**
**Якты көннән туймыйбыз.**
**Кулны кулга чаба-чаба**
**Көләбез дә җырлыйбыз.**
***(С. Миңлекәй)***



# АЗ ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР

## Кулда нәрсә бар икәнен бел!

Балалар түгәрәккә басалар яки, түгәрәк ясап, урындыкларга утыралар да кулларын артка куялар. Тәрбияче балалар арасыннан үтеп йөри һәм чиратлап барысының да кулларына кечкенә шакмак, шар, кәгазь һәм башка шундый берәр әйбер (уенчык) салып китә.

Әйберне алган бала, капшап карап, шул әйбернең исемен әйтә, соңыннан барлык балаларга күрсәтә. Әгәр бала әйберне ялгыш атаган булса, шул чагында балалар барысы да бер авыздан ул әйбернең исемен әйтәләр. Балаларга таныш әйберләр генә бирелә.

## Кайда шалтыратканны бел!

Бер бала тәрбиячегә йөзе белән килеп баса да күзен йома. Калган балалар бу баланың артына берничә адым читтә тезелеп утыралар. Балаларның берәрсенә шалтыравык яки кыңгырау бирелә. Тәрбияче аңа шалтыратырга куша. Күзләрен йомган бала кайда шалтыраганлыкны кулы белән төртеп күрсәтә. Әгәр бала дөрес күрсәтсә, аның урынына икенче бала килеп баса. Юнәлешне дөрес күрсәтмәсә, шул ук бала белән икенче кабат уйнарга кирәк.

## Нәрсә яшерелде?

Балалар түгәрәкләнеп утыралар. Уртага (җиргә яки өстәлгә) берничә төрле (3–5) әйбер куела.

Балалар әйберләрне яхшылап карыйлар. Тәрбияченең әйтүе буенча, бер бала артка әйләнеп, күзен йомып утыра. Шул арада бер әйберне яшерәләр. Теге бала, әйләнеп карап, нәрсә яшерелгәнне әйтә. Уен өчен төрле уенчыклар, табигый материалларны файдаланырга мөмкин.

## Төймә салыш

Балалар барысы да палас өстендәге урындыкларда ярымтүгәрәк формасында тезелешеп утыралар. Һәрберсе учларын бергә куялар, башкаларга сизелмәслек итеп кенә, төймә салырлык урын калдыралар.

Балалардан берсе, кулына төймә тоткан килеш, уйнаучыларның кулларына салган кебек хәрәкәтләр ясап, түгәрәкне әйләнеп чыга. Ул, башкаларга сиздерми генә, уйнаучыларның берсенә, чыннан да, төймәне салырга тиеш. Аннан соң ул бераз читкәрәк китә һәм: «Кемдә төймә, сикереп чык!» – ди. Кулына төймә салынган бала, уртага чыгып, төймәне күрсәтә. Хәзер ул үзе төймә салучы була.

*Уенга күрсәтмәләр*

- Төймәнең кемдә икәнен берәү дә белмәсен өчен, аны башкаларга сиздерми генә салырга кирәк.
- «Кемдә төймә, сикереп чык!» дигәннән соң гына, төймәне күрсәтергә кирәк.
- Бу уенның варианты – «Йөзек салыш» уены. Бу очракта төймә урынына йөзек (я башка берәр кечкенә предмет) алына, ә сүзләр «йөзек» дип әйтелә.

## Мәче балалары һәм балалар

Балалар ике төркемгә бүленәләр. Аларның бер өлеше – «мәче балалары», икенче өлеше – балалар. Һәр баланың бер мәче баласы була. Мәче балалары «койма» өстендә (урындыкларда) утыралар. Балалар өйләрендә (бүлмә буйлап) йөриләр. Алар, кечкенә табаклар алып, мәче балаларын ашатырга китәләр, аларны эзлиләр, чакыралар. Мәче балалары койма өсләрендә утырган хәлдә мияулыйлар. Балалар, мәче балаларын күрү белән, сөт салынган табакларны идәнгә куялар һәм «пес-пес» дип чакыра башлыйлар. Мәче балалары коймадан төшеп, һәрберсе үз хуҗасы янына килеп «ашый башлый». Ашап бетерүгә, мәче балалары яңадан коймага менеп утыралар, ә балалар өйләренә кайталар.

## Атлар һәм колыннар

Балалар үз теләкләре белән «атлар», «колыннар» һәм «ат караучылар» булалар. Ат караучылар атларны җигәләр һәм эшкә китәләр. Колын үзенең «әнисе» артыннан йөри. Өйгә кайткач, ат караучылар атларны ашаталар, эчертәләр, аннан соң, атларны чирәмгә җибәреп, үзләре ял итәләр. Ялдан соң атларны тотып җигәләр, уен кабатлана.

## Аю, мине таны!

Балалар ярымтүгәрәк булып утыралар. Аларга каршы берникадәр ераклыкта балаларга аркасы белән «аю» утыра. Тәрбияче аюның күзләрен каплый (яки бәйли) һәм балаларның берсенә аны чакырырга куша. Бала: «Аю, мине таны!» – дип эндәшә. Шуннан соң аю ул баланы эзли башлый. Бу вакытта тәрбияче, аюны кулыннан тотып, балалар әйләнәсендә йөртә. Аю, иснәнә-иснәнә, үзенә эндәшкән баланы эзләп табарга тырыша. Аны тапкач, баланың тезләренә «тәпиләрен» куя. Уен кабатлана.

## Әби, уян!

«Әби» (тәрбияче) балалар белән йөрергә чыга. Балалар мәйданчык буйлап, төрле урыннарда таралышып йөгерәләр. Алар чәчәкләр җыялар, күбәләкләр куалар. Әби мәйданчык уртасындагы урындыкка утыра һәм йокыга китә.

Балалар, әбинең йоклаганын күргәч, әкрен генә янына барып, аның тирәсенә түгәрәкләнеп тезеләләр дә түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Әби, әби, әбекәй,
Уян инде, әбекәй!

Әби «йокысыннан» уяна да балалардан кайларда булуларын сораша, аларның җыйган әйберләрен карый. Аннан соң уен кабатлана.

## Кемгә теләсәң, шуңа бир

Уйнаучы балалар өстәл яки кечкенә палас әйләнәсенә түгәрәкләнеп утыралар. Уртага балалар санынча төрле уенчыклар куела. Тәрбияче бер баланы чакырып ала да сайлаган уенчыгын үзе теләгән балага бирергә куша. «Бүләк» алган бала бүләк бирүчегә рәхмәт әйтә, үз чиратында шулай ук бер уенчыкны теләгән балага алып бирә. Шул рәвешле, балалар берберсенә бүләк биреп чыккач, тәрбияче балаларга уенчыклары белән уйнарга тәкъдим итә. Сигнал тавышына уенчыкларын урынына куеп, яңадан түгәрәккә утыралар. Уен кабатлана.

Уенга хәрәкәтле уенчыклар (туплар, арбалар, машиналар, тәгәрәткечләр, кыршаулар һ. б.) бирү яхшы.

## Очты, очты...

Уйнаучылар кулларын тезләренә куеп утыралар. Бер бала, уртага чыгып, уенны алып бара. Ул, һәртөрле оча һәм очмый торган әйберләрнең исемнәрен буташтырып әйтеп, «очты» дигән саен, кул күтәрә. Балалар оча торган нәрсәләргә генә кул күтәрергә тиешләр. Ялгышып, очмый торган әйбергә кулларын күтәргән бала уеннан чыгарыла. Мәсәлән:

– Очты, очты, каргалар очты!
– Очты, очты, арбалар очты!..
– Очты, очты, торналар очты!
– Очты, очты, тырмалар очты!
– Очты, очты, чыпчыклар очты!
– Очты, очты, очкычлар очты!
– Очты, очты, ябалаклар очты!
– Очты, очты, тагараклар очты!
– Очты, очты, сандугачлар очты!
– Очты, очты, алмагачлар очты!
– ...

## Артта кем тора?

Балалар бер-берсенең иңбашларына тотынып, бер-бер артлы (колонна булып) тезелеп басалар. Әйдәүче бала колоннаның каршына арты белән баса. Шул вакытта балалардан берсе иң артка килеп баса. Ул, артта кем торганны әйдәүче белмәсен өчен, аннан яшеренебрәк тора. Бала яшеренгәч, балалар: «Булды», – дип кычкыралар. Әйдәүче бала колоннага йөзе белән әйләнә һәм артта кем торганны белергә тырыша. Арттагы баланы әйдәүчегә күрсәтмәскә тырышып, колонна һаман боргаланып тора.

Әгәр әйдәүче артта кем торганын белсә, бу бала әйдәүче ролен ала, артка икенче бала яшеренә. Яңа әйдәүче кем яшеренгәнне күрмәскә тиеш.

## Ак аю һәм аның балалары

Барлык балалар «ак аю балалары» булалар. Тәрбияче үзе «аю» ролен үти. Аю балалары уен өчен билгеләнгән урынның төрле җирләрендә кар өемнәре өстендә торалар. Тәрбияченең әйтүе белән, аю балалары йөрергә, бозлар арасыннан балык тотарга китәләр. Сигнал буенча – аю улаган тавышка – барлык аю балалары бозлар янына барып, аюны көтеп торалар. Аю, балалары янына килеп, аларга балык ашата.

## Болай ярый, болай ярамый

Уенда катнашучы барлык балалар түгәрәккә басалар. Тәрбияче дә балалар белән түгәрәккә баса һәм төрле хәрәкәтләр ясый. Балалар бу хәрәкәтләрне кабатлыйлар. Нинди хәрәкәтләрне кабатларга ярамаганын уен башында алдан сөйләшеп, билгеләп куялар, мәсәлән, кулны югары күтәрергә һ. б. Тыелган хәрәкәтләрне кабатлаучы балалар, башкалардан бер адым артка чыгып, уенны дәвам итәләр.

Бер адым артка чыгу бары тик тыелган хәрәкәтләрне ясау-

чы балаларга гына рөхсәт ителә. Ялгышкан бала, уенны кабатлаганда хәрәкәтләрне дөрес ясаса, яңадан түгәрәккә кереп, уенны дәвам итә. Уен башында хәрәкәтләрне тәрбияче күрсәтә, аннан соң балалар үзләре дә күрсәтә ала.

## Төньякка бару

Уйнаучылардан берсе «ак аю» итеп билгеләнә. Уенга катнашучылар барысы да «пароходка» (тезелеп куелган урындыкларга) утыралар. Ак аю пароходка каршы якта тора.

Тәрбияче күрсәтүе буенча, балалар куллары белән ишкәк ишкән (яки пароход хәрәкәтенә охшашлы) хәрәкәтләр ясыйлар һәм пароход тирбәлгән шикелле тирбәләләр. Пароход туктауга, барысы да, пароходтан төшеп, бу урынны карарга китәләр: «боз кисәкләре өстеннән сикерәләр, лом белән бозларны ваталар, чаңгыларда (имитацион хәрәкәтләр) баралар». Көтмәгәндә (тәрбияче сигналы буенча) килеп чыгучы аюны күрәләр. Аюны камап алалар. Аны үзләре белән пароходка алып керәләр. Пароход яңадан юлын дәвам итә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны ачык һавада үткәрү яхшы. Кыш көне һавада үткәргәндә, кардан зур пароход ясарга мөмкин.

• Аю тәрбияченең сигналы булгач кына күренә.

• Аюны кулга-кул тотынган хәлдә камап алалар.

## Сәгать

Балалар, бер-берсе арасында берникадәр буш ара калдырып, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала «сәгать» була. Ул түгәрәкнең уртасына баса. Балалар түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Уңга таба «Тик-так!»
Сулга таба «Тик-так!»
Мин шулай өйрәнгән:
«Тик-тик, тик-так!»

Сүзләрнең ритмына туры китереп, сәгать маятнигы хәрәкәтенә охшашлы хәрәкәт ясыйлар – гәүдәләре белән як-якка иеләләр яки кулларын алга һәм артка таба селкиләр. Түгәрәк уртасына баскан бала, кулларын алга сузган хәлдә, әкрен генә үз тирәсендә әйләнә, һәр сүзне әйтүгә, ул кулын уйнаучыларга чиратлап күчерә. Сүзләрне әйтеп бетерүгә, сәгать угы хәрәкәте туктала. Ук кем турысында туктаса, шул бала сәгать сугуына охшашлы берәр төрле хәрәкәт ясый: үз тирәсендә әйләнеп кул чаба һ. б. Калган балалар бу хәрәкәтне кабатлыйлар.

Тәрбияче әйтүе яки алдан сөйләшеп кую буенча (хәрәкәтне берничә кат ясагач), хәрәкәт туктала, һәм яңа «сәгать» сайлана, уен кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Хәрәкәтләр сүзләрнең ритмы буенча ясалалар.

• Сәгать сугу, сүзләр беткәннән соң башланып, тәрбиянең күрсәтүе буенча туктала.

• Тәрбияче хәрәкәтләрнең ритм буенча ясалуын күзәтә.

## Мәзәкче

Барлык балалар урындыкларда утыралар. Балалар арасыннан берсе «мәзәкче» итеп сайлана. Ул башка балаларның каршыларына килеп баса һәм, нинди дә булса берәр кызыклы хәрәкәт ясап яки көлке сөйләп, аларны көлдерергә тырыша. Мәзәкче ни генә сөйләсә һәм нинди генә кызыклы хәрәкәтләр күрсәтсә дә, бер генә бала да көлмәскә тиеш. Көлгән яки елмайган бала «штраф» түли яки мәзәкче ролен үти. Мәзәкче уртага яңа чыккан бала урынына барып утыра.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенда балаларның көлкеле хәрәкәтләр эшләргә, кызыклы сүзләр сөйләргә булган осталыклары, тапкыр сүзләр, төрле халык әкиятләрен, такмак һәм такмазаларын белүләре, зирәклек

һ. б. сәләтләре ачыклана. Шул ук вакытта уен балаларда шатлыклы күңел халәте тудыра.

• Тәрбиячenең такмаклар, такмазалар, кызыклы шигырьләрне күп белүе мөһим шартлардан санала.

## Кем яшеренде?

Балалар түгәрәк ясап утыралар. Арадан берсе уенны алып баручы була. Тәрбияче түгәрәктән 3–5 баланы аерып ала да алып баручыга шушы балаларны хәтердә калдырырга кирәклеген искәртә. Шуннан соң алып баручы бүлмәдән чыгып китә. Тәрбиячeнең күрсәтүе буенча, билгеләнгән төркемнән бер бала яшеренә. Ул яшеренеп беткәч, алып баручы бүлмәгә керә. Ул кем яшеренгәнне белә алса, аңа барлык бала кул чаба, һәм ул яңа алып баручы билгеле. Әгәр яшеренгән баланы белмәсә, бүлмәдән тагын чыга, шул арада яшеренгән бала үз урынына килеп утыра. Кергәч, алып баручы кем яшеренгән булганны белергә тиеш.

Уен, яңа алып баручы сайланып, яңа төркем балалар белән дәвам итә.

## Нәрсә оча?

Балалар, утырган яки баскан килеш, түгәрәккә тезеләләр. Тәрбияче балалар каршына баса һәм нинди дә булса бер тереклек яки әйбер исемен атап, бер-бер артлы әйтеп тора. Әгәр ул оча торган нәрсәне әйтсә, балалар, кулларын югары күтәреп: «Оча!» – диләр. Мәсәлән, тәрбияче «коңгыз» дигәндә, балалар барсы да: «Оча!» – дип, кулларын күтәрәләр. Әгәр ул «ат» дисә, балалар кулларын күтәрмәскә, «юк» дияргә тиешләр. Тәрбияче, һәр сүзне әйткәндә, кулын югары күтәрә, бу – балаларны игътибарлы булырга мәҗбүр итә. Кулын дөрес күтәрмәгәннәр отылган булып саналалар. Әгәр алар түгәрәктә басып торган булсалар, уенны түгәрәктән бер адым читкә китеп дәвам итәләр, әгәр инде утырып уйнаган булсалар, отылганнар уен беткәнче басып уйныйлар.

## Музыканы тыңлый бел!

Балалар, бер-берсе арасында бераз буш ара калдырып, үзләре теләгән тәртиптә утыралар. Арадан берсе бүлмәдән чыгып китә (яки бер читкә китеп утыра). Шул арада балалар чыгып киткән баланың кем янына килеп тукталырга тиеш булуын билгелиләр һәм берәр җыр җырлый башлыйлар. Бүлмәдән чыккан бала керә һәм җырлап утырган балалар янына килә. Билгеләнгән балага якынлашкач, җыр көчәя, ераклаша башлагач, җыр әкренәя. Җырның көчәюенә карап, ул үзенең кем янына килергә тиеш булуын белергә тиеш. Аннан соң икенче бала бүлмәдән чыга. Уен яңадан кабатлана.

Уенны берәр уенчык яшереп, музыка уйнау, бубен кагу астында да үткәрергә мөмкин.

## Тынлык уены

Балалар көчле музыка астында бүлмә буйлап атлап йөриләр. Музыка көчле һәм кызу темпта уйный. Бераздан ул әкренәя башлый, салмаграк темпка күчә, балалар йөрешләрен әкренәйтәләр. Музыка тәмам әкренәеп беткәндә, балалар да, кайсы кая чүгәләп, утырып яки читтәрәк сөялеп, йоклаган төсле күзләрен йомып, тәмам тынып бетәләр. Балалар барысы да тынычланып беткәч, музыка туктый. Балалар ял итәләр. Бераз вакыттан музыка тавышы янә әкренләп кенә ишетелә башлый. Тәрбияче, бер бала янына килеп, башкалар ишетмәслек итеп, шыпырт кына аның исемен атый, баланы «уята». Уянган бала икенче баланы уята, анысы – өченче баланы, һәм, шулай берсе артыннан берсен уята-уята, уен дәвам итә. Музыка тавышы да көчәйгәннән-көчәя бара. Балалар барысы да, «уяныпˮ беткәч, түгәрәккә җыелалар. Музыка астында бүлмә буйлап таралып, уен кабат уйнала.

## Фантлар

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Арадан берсе алып баручы була. Ул түгәрәкнең уртасына баса. Уен башлангач, алып баручы һәр бала янына чиратлап килә һәм: «Сезгә йөз сум акча җибәрделәр, теләгән нәрсәгезне сатып алыгыз. Сатып алганда «кара» белән «ак»ны алмагыз, «әйе», «юк» дип әйтмәгез. Нәрсә алырга телисез?» – ди. Сатып алучы үзенә кирәкле әйберләрнең исемнәрен әйтә, мәсәлән, курчак яки күлмәк, ди. Алып баручы нинди төстәге күлмәк кирәклеген сорый, ак яки кара төстәгене алырга киңәш бирә. Әгәр сатып алучы, уенның шартларын онытып, бу уенда тыелган сүзләрне әйтсә, ул фант түли (үзенең нинди дә булса бер әйберен бирә).

Аннан соң «фантлар уйнала»: фант иясенә нәрсә эшләргә кушылса, ул шуны үтәргә (җыр җырларга, шигырь сөйләргә, күрсәтелгән урынга йөгереп барырга, биергә) тиеш була.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Сораулар бирү балаларга кыен булганлыктан, алып баручы ролен башта тәрбияче үти. Уен берничә тапкыр уйналганнан соң, балалар үзлекләреннән уйный алалар.

• Балаларны артык озак көттереп ялыктырмас өчен, бу уенны аз сандагы балалар белән уйнарга тәкъдим ителә.

• Җәза – җыр башкару, шигырь, мәзәк сөйләү, бию һ. б.

## Рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне бел!

Балаларга төрле предметлы рәсемнәр (хайваннар, үсемлекләр һ. б. сурәтләнгән) өләшенә. Һәр бала, янында утыручыга күрсәтми генә, үзенең рәсемен карый. Тәрбияче соравы буенча, бер бала, рәсемендә сурәтләнгән әйбернең исемен әйтмичә генә, аның төрле билгеләрен атый, аңлатма бирә. Калган балалар рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне белергә тиешләр.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны оештырганда, тәрбияче рәсемнәрне, балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, дөрес сайларга тиеш.

• Уенны икенче тапкыр уйнаганда, рәсемнәрне башкалары белән алмаштырырга кирәк.

## Бака белән челән

Мәйданчыкта уен өчен билгеләнгән урынның уртасына 4 кечкенә казык кагыла. Аларны бер-берсенә бау белән тоташтырып, квадрат ясала. Квадрат якларының озынлыгы 4–6 м, бауның биеклеге җирдән 10–15 см чамасында була. Әлеге квадрат – «сазлык». Уен үткәрелә торган урынның бер ягында «челән өе» билгеләнә. Санамыш ярдәмендә «челән» билгеләнә. Калган балалар – «бакалар». Алар сазлыкта (квадрат эчендә) басып торалар.

Тәрбиячене̦ң сигналы буенча, челән сазлыкка бара (аякларын югары күтәреп атлый-атлый), бакаларны тотар өчен, бау аркылы атлап керә. Бакалар, челәннән котылыр өчен, ике аяклап сикереп, бау аркылы (сазлыктан) чыгалар. Челән аларны тотып алырга тырыша. Тотылган (кулы белән кагылган) бакаларны челән үз «өенә» алып китә, һәм алар, яңа челән алмашканга кадәр, вакытлыча уеннан чыгып торалар. Челән 2–3 баканы тоткач, уен беткән булып санала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Челән, сазлыктан тыш, башка урында да бакаларны тота ала.

• Әгәр бакалар бауны аркылы сикермичә, атлап кына чыксалар, ул вакытта барыбер тотылган булып саналалар.

## Тап һәм эндәшмә

Тәрбияче балаларга нинди дә булса берәр әйбер (мәсәлән, ачык төскә буялган бөҗра яки башка берәр уенчык) күрсәтә һәм, ул әйберне яшереп, балаларның аны табарга тиеш булулары турында аңлата. Бөҗраны күреп алган һәр бала аны тапканлыгын башкаларга белдермәскә, бары тәрбиячене̦ң, янына

килеп, колагына әкрен генә әйтергә тиеш. Тәрбиячедән башка берәүгә дә бу турыда әйтергә ярамый.

Күпчелек балалар божраны тапканнан соң, тәрбияче беренче башлап кемнең, аннан соң икенче һәм өченче булып кемнең тапканын әйтә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче әйберне күренеп торырлык, ләкин күзгә артык бәрелмәслек итеп яшерү турында балалар белән алдан сөйләшә.

• Яшерелгән әйбернең кайдалыгын тәрбиячедән башка берәүгә дә әйтергә һәм күрсәтергә ярамый.

• Әйберне күрү кыен булмаслык итеп яшерергә кирәк. Әгәр уйнаучы балалар саны күп булмаса, барлык балаларның да әйберне табуларын көтәргә кирәк, әгәр уйнаучылар күп булса, әйберне тапкан балаларны озак көттереп ялыктырмас өчен, аларның бер өлеше тапкач та, уенны чикләргә мөмкин.

## Эндәшмә!

Барлык уйнаучылар бергәләп нинди дә булса берәр кызыклы такмак яки шигырь әйтәләр. Соңгы сүзне әйткәннән соң, бер бала да эндәшергә, көләргә һәм елмаерга тиеш түгел. Әгәр берәр бала түзә алмый көлсә яки берәр сүз әйтсә, ул «штраф» түли: билгеләнгән урынга кадәр бер аякта сикереп барырга, җырларга, шигырь сөйләргә, табышмак яисә мәкаль әйтергә тиеш була.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенны төрле шартларда (экскурсиядә вакытта, урамда һ. б. да) үткәрергә була.

• Таныштырганнан соң, бу уенны балалар үзлекләреннән дә уйный алалар (тәрбияченең катнашуы мәҗбүри түгел).

# ҖЫРЛЫ-БИЮЛЕ УЕННАР

## Уенга җыю җыры

Балалар төрлесе төрле шөгыль белән мәшгуль вакытта, уен башлаучы бала уенга җыю җырын башкара. Башка балалар, әкрен-әкрен генә уенчыкларын, эш коралларын җыеп, иптәшләре янына уенга җыелалар, җырга кушылып җырлыйлар.

***Уен башлаучы***

Әйдәгез, дуслар, җыелыйк,
Җитәкләшеп тезелик.
Түгәрәктә бергәләп
Күңелле уйныйк, көлик!

Зурлар безгә соклансын,
Читтән карап торсыннар,
Безнең дуслыкка сөенеп,
Бертуган дип белсеннәр.

***Балалар***

Чү, әйдәгез, без теләгәнчә
Уйныйк, шау-шу килик,
Яшь чагыбыз, шат чагыбыз –
Шатланыйк, сөеник, көлик!

Чү, тыймагыз, тик торыгыз
Карап сез читтә генә,
Нинди матур гөр киләбез,
Чабып-сикереп менә!

Дәртле, җанлы, без күңелле,
Безгә ямьле Җир йөзе,
Безгә карап елмая
Күкнең кояшы, ай-йолдызы.

## Безнең капка төбендә

Уйнаучылардан «чебен», «озынборын», «чикерткә» һәм «кырмыска» сайлана. Алар түгәрәкнең тышкы ягында торалар. Калган балалар, кулга-кул тотынышып, җырлый-җырлый, әле сул якка, әле уң якка таба йөриләр. Чебен, озынборын, чикерткә һәм кырмыска җыр барышында әкрен генә, бер-бер артлы түгәрәк уртасына керәләр һәм җырның эчтәлегенә ярашлы хәрәкәтләр ясыйлар.

1. Безнең капка төбендә,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә,
   Капкабызның төбендә,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә.

2. Чебен көйләп утыра,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә,
   Ничек көйләп утыра,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә.

3. Озынборын кулында,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә,
   Скрипка сыздыра,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә.

4. Биеп китә чикерткә,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә,
   Кырмыска тора читтә,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә.

5. «Кырмыска дус, әйдә әле,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә,
   Бергәләп биик әле,
   Лә-лә-лә, лә-лә-лә».

6. «Биер идем шатланып,
Ар(ы)дым, аяк атламый,
Лә-лә-лә, лә-лә-лә,
Ар(ы)дым, аяк атламый».

Беренче, икенче һәм өченче куплетларның һәр юлы икешәр тапкыр җырлана. Дүртенче, бишенче һәм алтынчы куплетларның кушымталары гына кабатлана («лә-лә-лә...»).

Икенче куплетны җырлаганда, чебен түгәрәк уртасына керә һәм безелди. Өченче куплет вакытында озынборын керә, «скрипкада уйный».

Дүртенче куплетны җырлаганда, бии-бии, чикерткә керә һәм ишарә белән кырмысканы биергә чакыра.

Бишенче куплетны чикерткә үзе генә җырлый. Бу вакытта, җилкәсенә авыр әйбер күтәргән кебек, кырмыска керә.

Алтынчы куплетны кырмыска җырлый. Җырның өченче, дүртенче юлларын җырлаганда, арыганлыктан чүгәләп утыра.

Җырны җырлап бетергәннән соң, чебен, озынборын, чикерткә һәм кырмыска түгәрәк уртасында йөриләр һәм үзләренә алмаш сайлыйлар.

Уен кабатлана.

## Үрмәкүч

Уен түгәрәктә уйнала. Уртада бер бала «үрмәкүч» булып чүгәләп утыра. Балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр. Җырның соңгы сүзеннән соң үрмәкүч сикереп тора, түгәрәктәге балалар берьюлы чүгәлиләр.

Менә чебеннәр парлашып, туйганчы биеделәр,
Йөри торгач, барысы да арыдылар, талдылар.

Әйләнделәр, борылдылар, як-якка күз салдылар,
Үрмәкүчне күргәннән соң, хушларыннан яздылар.

## Парлашып калу

Балалар түгәрәккә басып, җырлап йөриләр:

Сандугачлар, былбыллар,
Тургайлар парлы була.
Кем уенда парсыз кала,
Шундук җәзасын ала.

Җыр бетүгә, бию көе башлана. Балалар бииләр. Бию көе туктагач, тиз генә парлашып басалар (балалар саны так булырга тиеш). Так калган балага җәза бирелә (җырлый, бии һ. б.).

## Ак калач

Балалар зур түгәрәк ясап басалар. Бер бала түгәрәк уртасында басып тора.

Балалар, түгәрәк эчендәге баланың исемен әйтеп, түгәрәк буйлап җырлап йөриләр: «җәелгән» сүзендә түгәрәкне киңәйтәләр; «кабарган» дигәндә, кулларын бергә күтәрәләр; «кечкенә» дигәндә, барысы бергә уртага керәләр (кысылалар); «зур» сүзендә янә түгәрәкне киңәйтәләр һәм ахыргы сүзләрдә, тиз-тиз җырлап, кулларын чәбәклиләр. Бу вакытта уртадагы бала уйнаучылардан берәүне уртага чыгара. Уен, икенче баланың исемен әйтеп, кабат башлана.

Галиянең туган көненә
Без пешердек ак калач,
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кабарган,
Менә шулай кечкенә,
Менә шулай зур гына.
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!

## Коймак

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала уртада басып тора.

Беренче куплетта балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр.

Икенче куплетның беренче һәм икенче юлларын җырлаганда, балалар кулларын, ычкындырып, өскә күтәрәләр; өченче юлында – як-якка җәяләр; дүртенче юлда ике кул тоташа.

Өченче куплетта балалар кул чабып торалар, ә уртадагы бала түгәрәктән бер баланы сайлап ала. Алар, кулларын тотышып, кара-каршы басалар һәм әйләнәләр.

Булатның туган көненә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.

Коймакларга карасаң,
Менә шулай кабарган,
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган.

Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнең сайлап ал.

## Сукыр тәкә

Бер баланы, күзен бәйләп, уртага бастыралар. Ул – «сукыр тәкә». Калган балалар кырыйда җырлыйлар:

Сукыр тәкә йөгерә,
Күрми ул бернәрсә дә.
Йөгермичә нишләсен,
Тота алмый берсен дә.

Җыр беткәч, балалар сукыр тәкәгә якын килеп, кагылып китәләр. Сукыр тәкә куа. Кемне дә булса тотса, тотылган бала «сукыр тәкә» була.

Уен шулай дәвам итә.

## Наза

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала ялгыз кала, ул уенчыларның каршына чыгып баса. Балалар, җырлый-җырлый, баскан җирдә аяк-кулларын хәрәкәтләндерәләр.

Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән.
«Наза» дигән уенны без
Уйныйбыз чын күңелдән.

*Кушымта:*
Наза, Наза,
Наза – матур кыз бала.
Наза – тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бала.

Кушымталарны җырлаганда, каршыдагы уенчылар арасыннан ялгыз калган бала биеп үтә, үзенә пар сайлый һәм аның белән икенче башка барып баса. Үзе генә калган бала уенны дәвам итә.

Уенны башка сүзле җырлар белән дәвам итәргә дә мөмкин.

Роза, Роза
Роза – гөлнең чәчәге.
Хәзерге матур тормышның
Күңелле киләчәге.

## Яулык алыш

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

Талым, талым, талчыбык,
Уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык,
Бир син миңа бер яулык, –

дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

## Капкалы

Ике бала «капка» ясап (кулларын өскә күтәреп) басалар. Башка балалар, «Әнисә» көенә (татар халык бию көе) бии-бии, капка аша узалар. Кинәт кенә капка ябыла (ике бала кулларын төшерәләр). Капкага эләгүчегә җәза бирелә (шигырь сөйләргә, мәкаль әйтергә һ. б.).

## Кунаклар

Уенның сүзләре балалар белән алдан өйрәнелә.

Балалар түгәрәкләнеп басып торалар. Бер бала, кулларын чәбәкли-чәбәкли, җырның беренче куплетын җырлый. Калган балалар аңа җавап кайтаралар – җырның калган өлешен җырлыйлар. Уен барышында төрле хәрәкәтләр ясала. Мәсәлән, «өйләре бик тә ямьле» дигәндә, балалар кулларын өскә күтәрәләр, «очтылар, киттеләр» дигәндә, кулларын, як-якка җәеп, очкан кебек итәләр, «башыма килеп кунды» дигәндә, кулларын башларына куялар һ. б.

***Бала***

Чәбәк, чәбәк, чәптеки –
Чәмәк авылы Әптеки.
Сез кайларга бардыгыз?
Ничек кунак булдыгыз?

***Балалар***

Әбиебезгә бардык без,
Кунак булдык, кундык без,
Ашатты безгә ашлар,
Эчертте ул әйрәннәр.

Өйләре бик тә ямьле,
Ашлары бик тә тәмле,
Әйрәннәре бик татлы,
Ә кошлары канатлы –

Очтылар, киттеләр,
Башыма килеп кундылар!
Очтылар, киттеләр,
Башыма килеп кундылар!

## Куаклар, кошлар һәм тилгән

Уйнаучылардан бер бала – «тилгән», берничә бала «кошлар» итеп билгеләнә. Калган балалар – «куаклар». Алар түгәрәктә тезелеп, кулларын югары күтәреп басалар, салмак кына як-якка чайкалып җырлыйлар. Бу вакытта кош итеп билгеләнгән балалар түгәрәк уртасында «очып йөриләр». «Куаклар» җырлап бетергәч, «кошлар» җырлый башлый. Аннан янә «куаклар» җырлыйлар. Бу вакытта тилгән түгәрәк тышында йөри. «Куаклар» җырлап бетерүгә, «Тилгән килә!» дигән сигнал була – тилгән кошларны куа башлый. Кошлар куаклар артына (балалар янына) качарга тырышалар.

***Куаклар***

Яшел болында куаклар үсә.
Күктә, биектә яшь кошлар оча.
Яшь кошлар уйный, яшь кошлар җырлый,
Җырны куаклар тибрәнеп тыңлый.

***Кошлар***

Безнең бит яшь чак, уйныйбыз бергә,
Дус-ишләр белән күңелле безгә.
Күңелле, кызык очуы күктә,
Канатлар җилпеп уйнау иркендә.

### *Куаклар*

Яшь кошлар уйный, яшь кошлар җырлый,
Җырны куаклар тирбәнеп тыңлый.
Белмиләр алар анда ни көтә,
Явыз бер тилгән кошлар күзәтә –
Ул әкрен генә, сакланып кына
Күзәтә аларны, күз салып кына.
Куак астына качыгыз, кошлар,
Очыгыз тиз-тиз, тимәсен тилгән!

## Куянкай

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына баскан бала «куян» була. Ул бер кулын иягенә куеп, моңаеп тора. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр:

Ак куянга ни булган,
Әллә инде авырган?
Иптәшен дә табалмый,
Урыннан да торалмый,
Куян, куян, син сикер,
Иптәшең табып китер!

Куян биленә таянып сикерә башлый. Аннан бер иптәшен уртага алып әйләнәләр дә, чакырылган бала куян булып кала. Уен яңадан башлана.

## Нәни булышчылар

Балалар, ике төркемгә бүленеп, кара-каршы тезеләләр. Бер яктагылар, җырдагы сүзләргә туры килгән хәрәкәтләр ясап, җырлый-җырлый, каршыдагы төркемгә таба баралар, аннан соң артка, үз урыннарына кире кайталар. Икенче төркем белән уен шул рәвешчә кабатлана. Җыр беткәнче, уен шулай дәвам итә.

– Шиңгән матур чәчәкләр, су сибәргә кирәк,
Әй бакчачылар, килегез су сибәргә тизрәк!
– Бакчачылар менә без, су сиптергеч белән без,
Шиңгән матур чәчәкләргә су сибәргә киләбез.
– Юл-сукмаклар коелган яфрак белән чүпләнгән,
Әй сез, дуслар, килегез, тазартыгыз чүпләрдән.
– Булышырга әзер без, көрәк тотып киләбез,
Карагыз сез: себерәбез себеркеләр белән без.
– Өлгергәннәр алмалар агачлардан коелырга,
Әй сез, нәни дусларыбыз, килегез алма җыярга!
– Без эшләргә яратабыз, алмаларны коябыз,
Кызарып пешкән алмаларны җирдән алып җыябыз.

## Өч кош

Санамыш ярдәмендә өч кош билгеләнә. Калган балалар түгәрәк ясап басалар да җырлый-җырлый әйләнеп йөриләр. Бу вакытта уртадагы өч кош түгәрәк уртасында утыра. «Берсе очты» дигәндә, берсе очып, түгәрәктән чыгып китә (шулай итеп, икенчесе, өченчесе түгәрәктән чыга). Җыр азагында, кошларга ияреп, барысы да очып таралалар.

Өч кечкенә кош утыра куакта,
Берсе очты-очты еракка...
Очты еракка, ул җылы якка,
Тик ике кош кына калды куакта.
Ике нәни кош утыра куакта,
Берсе очты-очты еракка...
Очты еракка, ул җылы якка,
Бер генә кош калды инде куакта.
Бер кечкенә кош утыра куакта,
Менә инде ул да очты еракка...
Очты еракка, ул җылы якка,
Калмады бер кош та инде куакта.

Әйдәгез, без дә барыбыз бергә
Очыйк кошлар күк, очыйк еракка,
Әйдәгез, әйдә, барыбыз бергә
Очыйк кошлар күк, җылы якларга-а-а-а!..

## Куян белән эт

Балалар, җитәкләшеп, түгәрәк ясыйлар. Бер бала кулларын баш өстенә куеп, «куян» булып, чүгәләп утыра. Икенче бала – «эт», түгәрәкнең тышкы ягында йөри. Балалар бергәләшеп түгәрәк буйлап җырлап йөриләр.

***Балалар***

Куян, нишләп ятасың,
Авырыйсыңмы әллә син,
Я качтыңмы явыз эттән,
Я яттыңмы ялга син?

Ятма, дускай, яле, тор,
Ач күңелеңне, сикер, *(Куян әкрен генә тора.)*
Синең өчен җырлыйбыз,
Тор, тор, дускай, тор, сикер! *(Куян ике аякта сикереп йөри.)*
Сикер, сикер, сикер, уйна,
Тик саклан усал эттән,
Килеп чыгып тешләмәсен,
Күрмәгәндә ул читтән.

Аның теше бик үткен,
Ертмасын кабырганны,
Ура аны, тиз кач син!
Күрде синең торганны.

Кач, куяным, кач, тиз бул,
Синең өчен ачтым юл!

Балалар, туктап, кулларын югары күтәрәләр, эт белән куянга куышыр өчен юл бирәләр. Үзләре, куян тотылганчы, соңгы ике юлны җырлап торалар.

## Коймаклар

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:

Ямьле бәйрәм көн иде,
Чакырдык без кунаклар.
Кунакларны сыйларга
Салдык майлы коймаклар.
Чыж-чыж итеп коймаклар *(Балалар кулларын як-якка*
Җәелде, әй, җәелде. *җәяләр,*

Менә тагын кечкенә *кысылалар,*
Булып калды, җыелды.

Аннан ары кабарды, *кулларын югары күтәрәләр,*
Кабарды, әй, кабарды.

Шиңде, юп-юка калды. *чүгәлиләр,*
Пеште инде коймаклар.
Сыйландылар кунаклар,
Тордылар, баш иделәр, *баш ияләр,*
Таралдылар, әй, шатлар,
Бииләр, әй-әй, шатлар. *бииләр.)*

## Нардуган

Бер бала уртага чыгарыла. Башка балалар аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, шушы нардуган җырын җырлап әйләнәләр. Ул үзенә бер көйгә җырлана.

Син уртада, без кырыйда,
Әйләнәбез, Нардуган,
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Мин дә шуны булдырам!

Җыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар да шул хәрәкәтне ясыйлар. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара, һәм уен баштагыча дәвам итә.

## Түбәтәй

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр. Җыр ахырында түбәтәй кемдә булып кала, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, шигырь сөйли, әтәч булып кычкыра һ. б.). Уен шулай дәвам итә.

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ерактан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатыриййм дигәнсең.
Түп-түп-түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

## Мәче белән тычкан

Түгәрәктә балалар бергәләп җырлап йөриләр. Түгәрәк эчендә «тычкан» чүгәләп утыра. Тышкы якта «мәче» тычканны күзәтеп йөри. Үз нәүбәтләрендә мәче белән тычкан бер-берсенә кара-каршы җырлыйлар. Җыр тәмам булгач, мәче тычканны куа башлый, тычкан кача. Җитәкләшеп баскан балалар, тычканны яклап, мәчене түгәрәк эченә кертмәскә тырышалар. Әгәр мәче эчкә керсә, тычканга чыгу өчен мөмкинлек бирәләр,

мәчене чыгармаска тырышып, кулларын кабат төшерәләр. Уен тычкан тотылганчы дәвам итә.

***Балалар***

Мәче йөри тын гына,
Тычкан эзләнеп кенә.
Болгап куя койрыгын,
Сыйпап куя мыегын.
Кысып куя тешләрен,
Сузып куя тырнагын,
Уйлап куя, эләктереп
Тешләвен һәм тырнавын.
Тычкан күрми мәчене,
Әйтә: «Чи-чи-чи, мәче!
Тырнакларыңны кайрап,
Юкка саклап йөрмәче!»

***Мәче***

Мияу, мияу, мыр-мыр-мыр!
Сездәйләрне аулавы
Түгелдер бер дә кыен.

***Балалар***

Тукта, мәче, тукта, чү,
Мактанып мыраулама!
Без саклыйбыз тычканны,
Тоталмассың, аулама!

***Тычкан***

Чи-чи-чи-чи, әй мәче,
Юкка саклап тормачы!

***Мәче***

Саклармын да тотармын,
Мин бит батыр ир мәче!

*Балалар*
Тукта, мәче, тукта, чү,
Мактанып мырауламачы.
Тоттырмабыз, сакларбыз,
Без – тычканны яклаучы!

## Ялкау мәче

Бер бала «ялкау мәче» булып, битләрен юып, иснәп, киерелеп утыра. Калган балалар, «тычканнар» булып, урындыкларда утыралар, җырлыйлар. Җыр бетүгә, тычканнар, урыннарыннан торып, төрле якка йөгерешеп китәләр. Мәче тычканнарны куа башлый һәм берсен тота. Тотылган бала «мәче» итеп билгеләнә, уен яңадан башлана.

Мич башында мәче
Утыра, җырлап.
Юа битен ул,
Иренеп, мырлап.
Ул ялкау көндез –
Йокыда була.
Тора да юына,
Киерелеп сузыла.
Килсен төн генә –
Тычканга каршы
Китә ул мәче
Сугышырга менә!

## Күрсәт әле, Габдулла!

Балалар түгәрәк ясап басалар. Бер бала «Габдулла» була. Ул уртага баса. Балалар, җырлап, Габдулладан төрле хәрәкәтләр күрсәтүен сорыйлар. Габдулла балалар сораган хәрәкәтләрне күрсәтә. «Менә шулай, менә шулай», – дип, балалар Габдулла күрсәткән хәрәкәтләрне кабатлап җырлыйлар.

– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек китап укыйлар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай китап укыйлар.
– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек язу язалар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай язу язалар.
– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек печән чабалар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай печән чабалар.
– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек утын яралар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай утын яралар.
– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек камыр басалар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай камыр басалар.
– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек гармун уйныйлар?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай гармун уйныйлар.
– Күрсәт әле, Габдулла,
Ничек кызлар бииләр?
– Менә шулай, менә шулай,
Шулай кызлар бииләр...

*Уенга күрсәтмә*

• Бу уенны шушы үрнәктә дәвам итәргә мөмкин. Ләкин балалар талчыкканчы озакка сузарга ярамый.

## Габдулла

Балалар бер-берсенең кулларына тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Бер бала уртада тора. Түгәрәктәгеләр, җырлый-җырлый, бер якка хәрәкәт итәләр:

Син уртада, без кырыйда
Әйләнәбез, Габдулла.
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Шуны эшләргә була.

Җыр туктагач, уртадагы бала берәр төрле хәрәкәт ясый, башкалар аның хәрәкәтләрен кабатлыйлар. Әгәр бу хәрәкәтне дөрес ясамаучылар булса, аның берәр әйберен алалар. «Гаепләнүчеләр» саны 3–4 кә җиткәнче, уен шулай кабатлана. Соңыннан аларга берәр төрле җәза бирелә (җырларга, биергә, әкият сөйләргә, мәкаль әйтергә һ. б.).

## Мәк

Балалар, ике төркемгә бүленеп, кара-каршы басалар. Бер төркем – «әни», ә икенче төркем «балалар» була. Алар, берберләренә сорау-җавап бирү юлы белән, җырның сүзләренә туры китереп, төрле хәрәкәтләр ясыйлар.

– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, җанкаем,
Ничек соң, ничек соң чәчәләр мәк?
– Менә шулай, балакаем, менә шулай, гөлкәем,
Чәчәләр, чәчәләр, чәчәләр мәк.
– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, бәгырем,
Ничек соң, ничек соң үсәдер мәк?
– Менә шулай, балакаем, менә шулай, күз нурым,
Үсәдер, үсәдер, үсәдер мәк.
– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, җанкаем,
Ничек соң, ничек соң җыялар мәк?
– Менә шулай, балакаем, менә шулай, гөлкәем,
Җыялар, җыялар, җыялар мәк.

– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, бәгырем,
Ничек соң, ничек соң пешерәләр мәк?
– Менә шулай, балакаем, менә шулай, күз нурым,
Пешерәләр, пешерәләр, пешерәләр мәк.
– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, җанкаем,
Ничек соң, ничек соң ашыйлар мәк?
– Менә шулай, балакаем, менә шулай, аппагым,
Ашыйлар, ашыйлар, ашыйлар мәк.

*Уенның 2 нче варианты.* Төркемнәр, бер-берсеннән ераграк басып, җырлый-җырлый, кара-каршы киләләр һәм янә артка чигенәләр. Уен шулай дәвам итә.

## Гөл утыртканда

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртада башына кызыл чәчәкләр белән бизәлгән такыя кигән бер бала чүгәләп утыра. Аның өстенә карарак төстәге җәймә ябалар. Әлеге бала тирәсендә берничә бала гөл утырткан хәрәкәтләр ясыйлар. Түгәрәктәге барлык башка балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:

Балчык йомшартып
Утыртамын гөл,
Шытып, яшәреп
Чыгар әле ул.

Көн саен карап,
Мин сибәрмен су,
Чәчкә атар ул
Кызылсу-алсу.

Канатын җәеп, аңа
Кунар бер былбыл.
Моңланып сайрар:
– Син, дип, матур гөл!

Җыр тәмам булганнан соң, җәймә астыннан «гөл» күтәрелә. Сандугач киемендәге бер бала түгәрәккә кереп җырлый:

Ай-яй, матур гөл,
Ямьле, ал-кызыл.
Сөямен, сиңа
Гашыйк мин, былбыл.

Җырлар тезәмен
Сиңа, ал гөлем,
Син үскәндә тик,
Ямьле бу илем.

*Уенга күрсәтмә*

• Әлеге уенны, киемнәр киеп, концерт номеры буларак, бәйрәмнәрдә дә башкарырга мөмкин.

## Бала белән кош

Ике бала кара-каршы җырлыйлар. Берсе – «бала», берсе – «кош».

***Бала***

Әй матур кош, азык эзләп
Йөрмә әле син салкын көздә.
Әзерне ашап, матур читлектә
Ят рәхәтләнеп син өебездә.

***Кош***

Юк, юк, дускаем, сәламәт чакта,
Әзерне ашап, эшсез ята алмыйм,
Матур читлек, рәхәт тормыш өчен
Сөйгән ирегемне ташлый алмыйм.

## Бию җыры

Көләбез без, уйныйбыз,
Шат күңелле, җырлыйбыз,
Без биибез,
Безнең яшь чак, шат чак,
Шуңа биеп, кул чабабыз чап-чап!

Атам-анам биегән,
Ямь тапкан ул биюдән,
Агам-тутам биегән,
Күңел ачкан биюдән.

Карап торсын дус-иш,
Үрнәк алсын бездән,
Без биибез, биибез,
Тартынмыйбыз биюдән.

Уйнап-җырлап биемәгән –
Җебегән ул, җебегән,
Уйнап-җырлап биемәгән –
Җебегән ул, җебегән!

## Утыр, утыр, Мәликә

Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, түгәрәк уртасында утыра. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә җырлап әйләнәләр.

Утыр, утыр, Мәликә,
Алмагачның төбенә,
Кем утырган каршыңа –
Әйтеп бирче тиз генә!

Берәү аның янына килеп утыра. Уртадагы бала аны капшап таныргa һәм исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

## Тамчы, там!

Уенчылар, пар-пар булып, кулга-кул тотынышып, бер-бер артлы басалар. Алар түбәндәге җырларны бергәләп җырлыйлар һәм бию хәрәкәтләре ясыйлар:

Там, там, тамчы, там,
Тамганыңны яратам.
Тамган тамчыларга карап,
Мин җырларга яратам.
Тамчы тама, тамчы тама,
Тамчы тама түгелме?
Тамчы тамса, матур язлар
Килеп җитә түгелме?
Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз.
Кулны кулга чаба-чаба
Көләбез дә җырлыйбыз.

*(Балалар алга баралар, артка таба чигенәләр, кара-каршы басып кул чабалар).*

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

## Яшерәм яулык

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында – кулъяулык. Ул түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:

Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

Сүзләрне әйткәндә, бер баланың үч төбенә кулъяулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салынганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.

## Төймә

Балалар, түбәндәге сүзләрне җырлап, түгәрәктә йөриләр һәм, туктап, кушымтасында бииләр.

Яңгыр ява сибәләп,
Төймә-төймә төймәләп.

*Кушымта:*
Их, төймә, төймә, төймә,
Төймә була егерме.
Бергә җырлыйк, бергә уйныйк,
Бергә яшәү күңелле.

Җепкә тезгән төймә кебек,
Без дә яшик бергәләп.

*Кушымта:*
Их, төймә, төймә, төймә,
Төймә була бер җептә.
Җепкә тезгән төймәләрнең
Матурлыгы берлектә.

## ИДЕЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫ УЕННАРЫ
*(Күпмәдәниятле тәрбия уеннары)*

### Әбәк-күбәк
*(башкорт халык уены)*

Балалар арасыннан «көтүче» сайлана. Калганнар бер-бер артлы тезелеп басалар. Көтүче үз алдындагы баланың кулына кагыла (әкрен генә суга) һәм болай ди:

Әбәк-күбәк, алтын савыт,
Куып тотсаң – алтын кашык,
Әгәр тота алмасаң,
Эзеңә җитмеш көрәк көл.

Бу сүзләрне әйтеп бетергәннән соң, ул йөгереп китә. Кулына кагылган бала аның артыннан куа. Әгәр көтүче, йөгереп барып, колонна артындагы бала артына басарга өлгерсә, куучы җиңелгән санала, һәм ул көтүче була. Әгәр өлгермәсә, уен нәкъ шул тәртиптә кабатлана. Уен балалар арыганчы дәвам итә.

### Энә белән җеп
*(башкорт халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп тезеләләр. Бер бала – «энә», икенчесе «җеп» итеп билгеләнә. Тәрбияченең сигналы буенча, энә балалар арасыннан төрлечә йөгереп йөри, җеп аның артыннан иярә, куып җитәргә тели. Энә җепне бутарга, ә җеп, киресенчә, энәдән калышмаска тырыша. Җеп энәне куып тотканнан соң, рольләр алмашына: җепне уйнаучы энә була.

Бу уен игътибарлылыкка, тизлеккә өйрәтә.

### Давыл
*(башкорт халык уены)*

Балалар, ике төркемгә бүленеп, урындыкларда кара-каршы утыралар. Тәрбияче: «Яшен яшьни!» – дисә, балалар кулларын

чәбәклиләр; «Яңгыр ява!» – дигәндә, куллары белән тезләренә сугалар; «Күк күкри!» – дигәндә, аякларын тыпырдаталар; «Давыл чыкты!» – дигәндә, һәр бала үз урындыгы тирәли әйләнеп чыга һәм кире урынына утыра. Кайсы төркем урындыкларга алданрак утырышып бетә, шул җиңүче дип табыла.

## Без унике кыз идек!

*(башкорт халык уены)*

Бу уенны, гадәттә, кызлар гына уйный. Теләсәләр, уенга малайлар да катнаша ала.

Балалар идәнгә түгәрәк ясап, бер-берсенең баш бармакларына тотынышып утыралар. Барысы бергә түбәндәге сүзләрне әйтә:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Тактага без җыелдык,
Таң атканда юк булдык!

Шигырьнең беренче юлында балалар башларын ияләр, икенче юлында, киресенчә, башларын күтәрәләр, тураялар. «Юк булдык!» – дигәндә сикерешеп торалар да төрле якка йөгерешә башлыйлар. Куучы кыз аларның артыннан йөгерә. Тотылган бала уеннан чыга.

## Үгез-йөзек

*(башкорт халык уены)*

Балалар, бер рәт булып тезелеп, урындыкларга утыралар. Уйнаучылар арасыннан «үгез» билгеләнә. Ул башка балалардан аерым, аларга каршы урындыкта утыра. Алып баручы билгеләнә (баштарак тәрбияче үзе).

Алып баручы куш учына кечерәк бер әйбер (йөзек, кечкенә таш яки вак акча) тота һәм, тезелешеп утырган балаларның һәрберсенең учына кагылып, йөзек салган кебек хәрәкәт ясый,

башкаларга белдерми генә, берсенә йөзекне сала. «Үгез» алып баручының хәрәкәтләрен игътибар белән күзәтеп утыра. Алып баручы аннан сорый:

– Үгез, әйт әле: йөзек кем кулында?

Һәр бала йөзекне үзендә дип күрсәтергә тырыша. «Үгез» бер баланың исемен атый. Әгәр йөзек, чыннан да, аның кулында булса, «үгез» әлеге уйнаучы урынына утыра. Йөзек табылган бала алып баручы итеп билгеләнә, ә элеккеге алып баручы «үгез» була. Йөзекнең хуҗасы дөрес аталмаган очракта, уен элеккечә дәвам итә. Әгәр берничә тапкыр уйнаганнан соң да «үгез» йөзек хуҗасын атый алмаса, аңа җәза бирелә (җырларга, биергә, шигырь сөйләргә һ. б.).

Шул рәвештә уенны берничә тапкыр кабатларга мөмкин.

## Буяу сатыш

*(башкорт халык уены)*

*Уенга әзерлек.* Санамыш ярдәмендә «сатучы» һәм «көтүче» билгеләнә. Сатучы бер рәткә тезелешеп утырган балалар тирәсендә йөри һәм һәрберсенең колагына берәр төсне атый. Бу вакытта көтүче читтәрәк тора.

Көтүче уйнаучылар янына килә һәм түбәндәге сүзләрне әйтә:

Буяулары бар микән?
Зәңгәр микән, ал микән?
«Төсем матур, мине ал», – дип
Әйтүчеләр бар микән?

Шуннан соң ул: «Тук-тук-тук!» – дип, сатучы янына килеп, «ишек» шакый. Сатучы белән көтүче арасында түбәндәге сөйләшү була:

– Кем бар анда?

– Хуҗалар өйдәме?

– Әйдә, әйдә, узыгыз!

– Сатучы, син буяу сатасыңмы?

– Сатуын сатар идем дә, сиңа кирәкле буяу бар микән соң үземдә?

Көтүче берәр төсне атый, мәсәлән: «Миңа кызыл төс кирәк», – ди. «Кызыл төс» итеп билгеләнгән бала сикереп тора да йөгереп китә. Көтүче аны куа башлый. Әгәр тота алса, үз янында калдыра, әгәр дә тота алмаса, «кызыл буяу» кире үз урынына барып утыра, аңа башка төрле буяу исемен кушалар (мәсәлән, шәмәхә һ. б.).

Уен барлык буяулар сатылып беткәннән соң гына тәмам була.

## Исемен ата!

*(башкорт халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртадагы бер баланың күзләрен яулык (тасма) белән бәйлиләр. Аның каршысына икенче бер баланы бастыралар, ә калганнар болай диләр:

Бик яхшылап уйла әле:
Кем ул каршыңда тора?
Белә алсаң, исемен әйт,
Киемен тотып кара.

Күзләре бәйләнгән уенчы, кулы белән әлеге баланың киемнәрен, гәүдәсен капшап караганнан соң, аның исемен атарга тиеш. Әгәр дә ул аның исемен әйтә алса, исеме дөрес аталган шул баланың күзләрен бәйлиләр. Әгәр исем дөрес аталмаса, күзе бәйләнгән бала каршына икенче бер баланы китереп бастыралар. Уен берәр баланың исеме дөрес аталганчы дәвам итә.

Уенны кабатлап уйнаганда, күз бәйләр өчен, икенче бала сайлана.

## Чыршы

*(рус халкының җырлы уены)*

Балалар түгәрәк ясап, җырлап йөриләр. Җырның сүзләренә туры китереп, төрле хәрәкәтләр ясала. Мәсәлән, «Бәү, бәү» дигәндә, барысы да ике куллары белән бала тирбәткән төсле кыланалар; «Абау!» дигәндә, бармакларын селтәп торалар һ. б.

Урманда туды да чыршы,
Үз ирегендә үсте.
Ямь-яшел уздырадыр
Яз, җәй, көз, кышын.
Җил уйнап җыр җырлыйдыр:
«Йокла, чыршы, син, бәү-бәү!
Бәсле карлар яуса да,
Һич катма, син, ди, абау!
Яшь куянчыклар шаярып,
Сикерешеп астан үтә.
Кайсы чакта ач бүре дә
Шуннан ук үтеп китә.
Ботакларга күчә-күчә
Уйныйдыр тагын тиен.
Тукран килеп тукылдата,
Калынрак, диеп, киен!»

* * *

Атын җигеп, нык чаптырып,
Безнең бабай килде дә,
Матур гына яшь чыршыны
Кисте дә алды менә.
Ул чыршы, бик киенеп,
Безгә бәйрәмгә килгән.
Бәйрәм белән котлар өчен,
Безгә бүләк китергән.

## Зур туп

*(рус халык уены)*

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртадагы баланың аягы янында зур туп. Ул аягы белән тупны түгәрәктән тибеп чыгарырга тырыша.Тупны уздырган уенчы түгәрәктән читкә чыга, ә уртада уйнаган бала аның урынына баса. Түгәрәктәге балалар барысы да түгәрәкнең үзәгенә аркалары белән борылып басалар һәм бу юлы тупны эчкә уздырмаска тырышалар. Читтә калган бала исә тупны эчкә уздырырга тиеш.

Уен вакытында балалар тупны бер генә тапкыр да кулларына алмаска тиешләр. Әгәр кем дә булса тупны кулына ялгыш ала икән, ул вакытта уен туктатыла, һәм түгәрәк уртасына яңа уенчы билгеләнә, уен яңадан башлана.

## Бәйләгән аяклар белән йөгерү

*(рус халык уены)*

Уенда катнашучыларның аяклары калын тасма яки яулык белән бәйләнә. Балалар бер сызыкка тигезләнеп басалар һәм, тәрбияче сигнал биргәннән соң, финишка таба йөгерә башлыйлар. Иң беренче барып җиткән бала җиңүче була.

Уен башланган сызык (старт) белән финиш арасындагы ераклык бик зур булмаска тиеш.

## Аю янында, урманда

*(рус халык уены)*

Бу уенны иң нәни балалар белән дә уйнарга мөмкин. Катнашучылар арасыннан бер бала «аю» итеп билгеләнә. Мәйданчыкта ике түгәрәк сызыла, беренчесе – «аю өне», икенчесе – зуррагы – балалар өчен «өй».

Уен башлану белән, балалар өйләреннән чыгалар һәм җырлыйлар:

Аю янында урманда
Җиләк, гөмбәләр җыям,
Аю үзе йокламый,
Безне тотарга тели.

Балалар шул сүзләрне әйтү белән, аю өненнән йөгереп чыга һәм балаларны куа башлый. Үз өйләренә кереп өлгергән балаларга аю тия алмый, ә тотылган баланы үз өненә алып китә.

## Киек җәнлекләр өйрәтүче

*(рус халык уены)*

Бүлмә буйлап, идәнгә «агач төпләре» (кечкенә келәмнәр яки катыргыдан ясалган түгәрәкләр) тезеп куела. Агач төпләренең саны балалар санына караганда бергә азрак булырга тиеш. Төп эләкмәгән бала – «җәнлекләр өйрәтүче», барлык башка балалар «җәнлекләр» булалар. Уен башланганчы, балалар үзләре кайсы да булса бер җәнлекне сайлыйлар: кемдер – «куян», кемдер «бүре» һ. б. була. Җәнлекләр агач төпләренә утыралар, өйрәтүче алар тирәсендә йөри һәм берәр җәнлекнең исемен атый. Ул бер-бер артлы берничә җәнлекнең исемен атарга мөмкин. Җәнлекләр аның артыннан ияртәләр. Җәнлекләр өйрәтүче: «Игътибар, аучылар!» – дию белән, җәнлекләр дә, өйрәтүче дә агач төпләренә утырып калырга тырышалар. Кемгә урын калмый, шул «өйрәтүче» була, һәм уен дәвам итә.

## Балык тоту

*(рус халык уены)*

Уйнаучылар түгәрәкләнеп басалар. Уртада уенны алып баручы – «балык тотучы». Аның кулында бау (сикергеч тә ярый). Алып баручы, иелеп, җирдән якын гына арада бауны үз тирәли әйләндерә башлый. Башка балаларның (балыкларның) максаты, – бауга тими генә, аның аша сикереп чыгу. Әгәр дә аягы белән бауга тия яки баса икән, ул тотылган булып исәпләнә.

Уенны ике вариантта дәвам итәргә мөмкин.

*1 нче вариант.* Балык тотучы алышынмый. Кармакка эләккән «балык»лар уеннан чыга. Уен түгәрәктә иң җитез 2–3 уенчы калганчы дәвам итә.

*2 нче вариант.* Балык тотучы алмашына. Кармакка эләккән «балык» әйләнә уртасына керә, һәм ул «балык тотучы» була. Ә элеккеге балык тотучы «балык» була.

Баштарак балык тотучы ролен тәрбияче дә башкарырга мөмкин.

## Тилгән

*(рус халык уены)*

Уйнаучылар арасыннан «тилгән», «тавык» сайлана, калган балалар «чебиләр» булалар. Чебиләр бер-бер артлы тезелеп басалар, тавык аларның алдында тора. Тилгән бер читтә утыра, «чокыр казый». Тавык чебиләре белән аның тирәсендә әйләнеп йөри. «Тавык» белән «тилгән» сөйләшәләр:

– Тилгән, тилгән, син нишлисең?

– Чокыр казыйм.

– Сиңа чокыр нәрсәгә?

– Акча эзлим.

– Сиңа акча нәрсәгә?

– Энә сатып алырга.

– Сиңа энә нәрсәгә?

– Капчык тегәргә.

– Сиңа капчык нәрсәгә?

– Синең балаларыңны салырга.

Шуннан соң тилгән иң арттагы чебине тотып ала да, читкәрәк илтеп, «капчыкка» сала. Капчыктагы балалар шул урыннан китә алмый, уенны күзәтеп торалар. Тавык чебиләрнең алдына барып баса, балаларын саклый. Әмма тилгән башка чебиләрне дә тотып бетерә. Барлык чебиләр тилгән кулына эләгеп беткәннән соң, уен тәмамлана.

## Шаян казлар

*(рус халкының җырлы уены)*

Уйнаучы балалар арасыннан бер «әби» һәм ике «каз» сайлыйлар. Калган балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Барысы да, җырлый-җырлый, уң якка таба түгәрәктә әйләнәләр. Әби һәм казлар, уртада торып, җыр сүзләренә туры китереп, төрле хәрәкәтләр ясыйлар.

Авылда бер әбинең
Ике казы бар иде.
Соры иде берсе,
Ак иде икенчесе.
Икесе дә – шаян каз,
Андый шаян казлар аз.

Әби казларны болынга куа. Казлар булып уйнаучы балалар кулларын аркаларына куялар, каз канатларын җилпегән шикелле хәрәкәтләр ясыйлар. Әби урындыкта утыра, ә казлар аның тирәсендә йөри.

Муеннарын сузалар,
Бер-берсен уздыралар,
Соры иде берсе,
Ак иде икенчесе.
Кайсыгызның муены озын?
Карагыз әле сузып!

Балалар муеннарын казлар шикелле сузып йөриләр. Аннан соң йоклаганга салышып утыручы әби яныннан ераграк китәләр.

Су читенә бардылар,
Тәпиләрен юдылар,
Соры иде берсе,
Ак иде икенчесе.
Шаярдылар, йөрделәр,
Суга кереп чумдылар.

Балалар, казлар кебек, аякларын юган төсле хәрәкәтләр ясыйлар, аннан соң түгәрәккә тезелгән балалар артына яшеренәләр. Әби йокысыннан уяна һәм казларын эзли башлый. Бу вакытта түгәрәктә йөрүчеләр тик тора, бары тик әби генә җырлый:

Эзлим-эзлим казларны,
Кайдан табыйм аларны?
Соры иде берсе,
Ак иде икенчесе.
Каян табарга инде?
Югалырлар микәнни?

Балалар, яңадан кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр, казлар, уртага чыгып, әбигә башларын ияләр, әбинең йөзендә шатлык билгесе беленә.

Казлар чыкты каршыга,
Башын иеп барсы да.
Соры иде берсе,
Ак иде икенчесе.
«Ачуланма, әби!» – дип
Торды алар, баш иеп.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уенның мәгънәсе образларның бала тарафыннан иҗади рәвештә сурәтләнүләреннән гыйбарәт. Шунлыктан балаларга әзер хәрәкәтләрне тәкъдим итүнең кирәге юк. Балага үзенчә хәрәкәтләнергә мөмкинлек бирергә кирәк.

• Уен үткәрү өчен, әбигә яулык, казларга борыннар әзерләнә.

## Шалкан

*(рус халык уены)*

Уйнаучылар арасыннан алдан ук «шалкан», «әби», «бабай» һәм әкиятнең башка геройлары билгеләнә. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Уртада – шалкан. Калган ба-

лалар түгәрәк буенча хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларның эчтәлеге түгәрәк уртасында хәрәкәт белән гәүдәләндерелә.

Бабай шалкан утырта,
Шалкан үсә, зур була.
Зур була, бик зур була,
Бабай йолкырга килә.
Тарта бабай шалканны –
Ала алмый суырып.
Чакыра ул ярдәмгә
Әбине, шунда күреп.
Әби тотына бабайга,
Бабай тотына шалканга,
Икәүләп, тирләп-пешеп,
Менә тарталар инде,
Тарталар, әй, тарталар –
Ала алмыйлар суырып.
Чакыра әби ярдәмгә
Малаен, шунда күреп.
Малай тотына әбигә,
Әби тотына бабайга,
Бабай тотына шалканга,
Менә тарталар инде,
Тарталар, әй, тарталар –
Ала алмыйлар суырып.
Чакыра малай маэмайны
Ярдәмгә, шунда күреп.
Маэмай тотына малайга,
Малай тотына әбигә,
Әби тотына бабайга,
Бабай тотына шалканга,
Тарталар, әй, тарталар –
Ала алмыйлар суырып.
Чакыра маэмай ярдәмгә
Мәчене, шунда күреп.

Мәче тотына маэмайга,
Маэмай тотына малайга,
Малай тотына әбигә,
Әби тотына бабайга,
Бабай тотына шалканга,
Менә тарталар инде.
Ала алмагач суырып,
Чакыра тычканны мәче.
Тычкан тотына мәчегә,
Мәче тотына маэмайга,
Маэмай тотына малайга,
Малай тотына әбигә,
Әби тотына бабайга,
Бабай тотына шалканга,
Тарттылар, әй, тарттылар –
Һәм чыгардылар йолкып.

Шалканны йолкып чыгаргач, барысы да тәгәрәп китәләр. Уен шулай тәмам була.

## Бүре һәм куян

*(чуваш халык уены)*

Уен, гадәттә, җәй көне урамда, җәйге мәйданчыкта уйнала. Шулай ук бүлмәдә дә уйнарга мөмкин.

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Бер бала әйдәүче итеп билгеләнә. Ул түгәрәк тирәли әйләнеп йөри һәм тиз-тиз әйтә: «Учак яна, самавыр кайный, шулай кирәк. Бабай, син нишлисең?» – ди һәм, бер баланың арткы ягында тукталып, аның җилкәсенә җиңелчә генә кагыла. Теге бала күзләрен куллары белән каплый. Шул рәвешле, уен түгәрәктәге барлык балаларның күзләре капланып беткәнче дәвам итә. Шуннан соң әйдәүче түгәрәк тирәли икенче якка әйләнеп йөри башлый һәм, берәр баланың җилкәсенә кагылып: «Бүреме, куянмы?» – дип сорый, шул баланы үзенә таба каратып, кулларын йөзләреннән ала. Әгәр баланың йөзе кырыс, усал булса,

ул йөзләрен җыерып торса, әйдәүче аны «бүреләр» ягына, киресенчә, юаш булып, елмаеп торса, «куяннар» ягына җибәрә. Шулай итеп, һәр уйнаучы бала теге яки бу якка бүленеп бетә. Иң соңгы бала үз урынына барып җиткәч, бүреләр куяннарны куа башлыйлар. Бүрегә бер дә тотылмаган куян җиңүче дип билгеләнә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тәрбияче уен барышында балаларга бер-берсенә карарга ярамаганлыкны аңлата.

• Күпме куян һәм бүре барлыгын белдертмәс өчен, төркемнәргә аерылган балалар тавыш-тынсыз гына торырга тиешләр.

• Бүре «кулы» белән кагылган куян тотылган дип исәпләнелә. Уен башланганчы ук, куяннар һәм бүреләрнең тотар урыннары билгеләнә.

## Таралыгыз!

*(чуваш халык уены)*

Балалар, кулларын тотышып, түгәрәк ясыйлар. Нинди дә булса таныш җыр җырлап, түгәрәк буйлап йөриләр. Уенны алып баручы уртада басып тора. Кинәт ул: «Таралыгыз!» – ди. Уенчылар төрле якка йөгереп китәләр. Алып баручы аларны куа. Тотылган бала уенны алып баручы була.

## Чәчәкләр

*(чуваш халык уены)*

Уенда так сандагы балалар катнаша. Балаларның яртысы түгәрәк ясап, чүгәләп утыралар. Һәрберсенең артында берәр бала басып тора. Ялгыз калган бала әйдәүче була. Ул түгәрәк тирәли әйләнеп йөри һәм басып торган уенчының берсеннән сорый:

– Синең ничә чәчәгең бар?

Уенчы берәр сан әйтә. Сораучы да, җавап бирүче дә капма-каршы якка йөгереп әйләнә башлыйлар. Алар әйтелгән сан кадәрчә (мәсәлән, биш тапкыр) түгәрәкне әйләнеп чыгалар. Ялгыз утырган баланың артына иң беренче булып кайсы килеп баса һәм аңа куллары белән кагыла, шул җиңгән санала. Соңга калганы әйдәүче була.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Балаларның бер үк вакытта йөгерә башлауларын күзәтергә кирәк. Калганнар аларга комачау итмәскә тиешләр.

• Уенга кадәр үк иң күбе ничә тапкыр әйләнергә мөмкин булу сөйләшенә.

• Чүгәләгән балалар әйләнү санын бергәләп кычкырып әйтеп торалар.

## Урындык

*(уен варианты)*

Уенны сүзсез генә уйнарга мөмкин. Кара-каршы әйләнүче балаларның кайсы буш урындыкка беренче килеп утыра, шул җиңүче була.

## Туп һәм чокыр

*(удмурт халык уены)*

Уенда 3–5 бала катнаша. Уен җәй көне урамда уйнала. Җиргә 1,5–2 м диаметрлы әйләнә сызыла, әйләнә эченә уйнаучылар санынча кечкенә чокырлар казыла. Һәр уенчы үз чокырын билгели – төрле төстәге таш, таяк, яфрак h. б. ны сала.

Бер уенчы, әйләнәдән 3–4 м ераккарак китеп, тупны тибеп җибәрә. Туп кемнең чокырына төшә, шул бала туп тибүче итеп билгеләнә. Уен балалар арыганчы уйнала.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Әгәр туп бер чокырга да төшмәсә, ул бала тупны яңадан тибә.

• Әгәр туп чокырга төшеп кире чыкса, аны типкән бала тагын бер тапкыр туп тибәргә хокуклы.

## Су анасы

*(удмурт халык уены)*

Җиргә зур түгәрәк сызыла. Бу – «күл» («елга»). Санамыш ярдәмендә «су анасы» сайлана. Ул күл эчендә утыра.

Уйнаучылар күл тирәли йөгереп йөриләр. Күл янына якын килгән балаларны су анасы тота (кулы белән кагыла). Тотылган бала күл эченә керә.

Уен берничә тапкыр (күпчелек бала тотылганчы) кабатлана.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Су анасы сызыктан чыгарга тиеш түгел.

• Тотылган балалар су анасына калган балаларны тотарга булышалар.

## Куышу

*(удмурт халык уены)*

Балалар түгәрәк ясап басып торалар. Араларыннан берсе санамыш әйтә:

Биш сакал, алты сакал,
Җиденче – сакаллы бабай!

Соңгы сүз туры килгән бала төрле якка йөгереп киткән балаларны куа. Әгәр берәр балага кулы белән кагыла алса, «Тоттым!» – ди. Тотылган бала уеннан чыга.

*Уенга күрсәтмәләр*

• «Бабай» сүзеннән соң барлык балалар төрле якка йөгереп китәләр.

• 4–5 бала тотылгач, алар кабат түгәрәккә басалар. Санамыш ярдәмендә куучы сайлана.

## Кулъяулык белән уен

*(удмурт халык уены)*

Балалар парлашып түгәрәккә басалар. Ике алып баручы билгеләнә, берсенә кулъяулык бирелә. Сигнал булгач, кулъяулыклы алып баручы йөгереп китә, ә икенчесе аны куа. Алар түгәрәкнең тышында куышалар. Кулъяулыклы алып баручы парлашып басып торучы балаларның берәрсенә кулъяулыкны тапшыра, үзе аның урынына баса. Шулай итеп кулъяулыклы алып баручы алмашына. Парсыз калган алып баручы кулъяулыклы баланы куып китә.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Уйнаучы, кулъяулыкны алганнан соң гына, йөгереп китә ала.

• Уен сигнал булгач кына башлана.

## Туп тәгәрәтү

*(мари халык уены)*

Уен өчен йон тутырылган туп кирәк булачак. Мәйданчыкның бер башына сызык үткәрелә. Уйнаучылар шул сызык артына басалар. Сызыктан 3–5 см ераклыкта зур булмаган бер чокыр казыла (диаметры һәм тирәнлеге туптан бераз зуррак).

Беренче уенчы, чокырга кертергә тырышып, тупны тәгәрәтеп җибәрә. Әгәр тупны чокырга кертә алса, аңа бер очко бирелә һәм ул тупны тагын тәгәрәтә. Кертә алмаган очракта, тупны икенче уенчы тәгәрәтә. Иң күп очко җыйган бала җиңүче була.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тупны чокырга ыргытырга ярамый, аны тәгәрәтергә кирәк.

• Тупны тәгәрәтеп җибәргәндә, сызыктан чыгу тыела.

• Тупны тәгәрәтү чираты турында алдан сөйләшеп куярга кирәк.

## Түгәрәктә

*(мордва халык уены)*

Җирдә зур түгәрәк сызыла. Уйнаучылар ике командага бүленәләр һәм команданың берсе – түгәрәк эченә, икенче командада уйнаучылар түгәрәкнең тышына урнашалар. Түгәрәкнең тышында басып торучы балалар тигез итеп бүленәләр һәм, түгәрәк эчендәге балаларга тидерергә тырышып, туп ыргыталар. Әгәр дә түгәрәк эчендә басып торучы балаларның берәрсе тупны тотып ала икән, ул аны тышта басып торучыларга таба ыргыта. Әгәр дә ул тупны кемгә дә булса тидерә алса, аңа бер очко бирелә; тидерә алмаган очракта, ул уеннан чыга. Түгәрәк тышында басып торучыларның барысына да туп тидерелгәннән соң, уенчылар урыннары белән алышыналар.

*Уенга күрсәтмәләр*

• Тупны һавада вакытта тотарга кирәк. Җиргә бәрелгән туп саналмый.

• Туп тигән балалар уеннан чыга баралар.

• Тупны тотып ала һәм кемгә дә булса тидерә алган бала (уртадагы), түгәрәктә кала.

III БҮЛЕК

# Уйнап һич тә туймыйбыз...

**Әйдәгез, дуслар, җыелыйк,**
**Җитәкләшеп тезелик.**
**Түгәрәктә бергәләп**
**Күңелле уйныйк, көлик!**
***(С. Миңлекәй)***



# ФИЗКУЛЬТМИНУТЛАР

## Яшел бакча

| | |
|---|---|
| Безнең яшел бакчага | *(Балалар түгәрәкләнеп басалар,* |
| Әйдә, бергәләп барыйк. | *бер урында атлап бару* |
| | *хәрәкәтләре ясыйлар,* |
| Гөлләр ничек үсә икән, | *иеләләр,* |
| Әйдәгез, бергә карыйк. | |
| | |
| Инде безнең гөлләребез | *күтәреләләр,* |
| Менә шулай үскәндер. | |
| | |
| Аһ, безнең гөлләребез | *кулларын өскә күтәреп,* |
| Менә шулай үскәндер. | *аяк очларына басалар.)* |

## Чәбәк-чәбәк

| | |
|---|---|
| Чәп-чәп-чәбәкәй, | *(Нәниләр кулларын күтәреп* |
| Кулларыбыз бәләкәй, | *чәбәклиләр,* |
| | |
| Ә хәзер тизрәк-тизрәк | *кулларны тезләргә* |
| Чәбәклик күңеллерәк. | *җиңелчә генә сугалар.)* |

## Үсәм

| | |
|---|---|
| Мин әле бик кечкенә, | (*Балалар алга таба иеләләр,* |
| Миңа бары өч кенә. | *күтәреләләр,* |
| | |
| Үсә-үсә зур булам, | *ике кулның да имән бармакларын* |
| Бик матур малай (кыз) | *бит урталарына куеп, башларын* |
| булам. | *чайкыйлар.)* |

## Кошлар

Кошлар булып очабыз, *(Балалар кулларын як-якка җәеп*
Аннан җиргә кунабыз, «*очалар*», *чүгәлиләр,*

Бераз ял итәбез дә
Тагын очып китәбез. *кулларын як-якка җәеп* «*очалар*».)

## Нәниләр

*Балалар бер рәткә тезелеп, чүгәләп утыралар.*
*Тәрбияче балалар каршында чүгәләгән һәм җырлый:*

Әй нәниләр, нәниләр,
Арыдык без, дип әйтмиләр. *(Балалар әкрен генә торалар,*

Аякларын күтәреп,
Матур итеп атлыйлар. *йөрү хәрәкәтләре ясыйлар,*

Хәзер барабыз артка, *артка таба йөриләр,*
Егылмыйча, син атла.

Бер, ике, бер, ике!
Егылмыйча, син атла. *алга таба киләләр.)*

## Без шулай ял итәбез

*Балалар хәрәкәтләрне сүзләргә туры китереп ясыйлар.*

Без әле бераз арыдык,
Ял итәргә уйладык.
Башны иябез алга,
Ә аннары – артка.
Уңга, сулга борабыз,
Аннан карап торабыз.

Иң өсләрен сикертәбез,
Кулларны биетәбез.
Бер алга, бер артка сузып,
Күңелле ял итәбез.

## Үсеп китте

| | |
|---|---|
| Үчтеки, үчтеки, | *(Балалар чүгәлиләр,* |
| Үсмәгәнгә кечтеки. | |
| | |
| Үсә-үсә зур булыр, | *акрын гына күтәреләләр,* |
| Бигрәк матур кыз булыр, | *бармакларын бит уртасына куеп,* |
| Бик батыр егет булыр. | *башларын як-якка чайкыйлар,* |
| | |
| Үчти, үчти, үчтеки, | *аяк очларына басып,* |
| Үсте китте кечтеки. | *кулларын өскә күтәрәләр.)* |

## Матур тубым

| | |
|---|---|
| Минем тубым бигрәк җитез, | *(Балалар кулларын чәбәклиләр,* |
| Матур итеп сикерә. | *сикерәләр,* |
| Әгәр тотып өлгермәсәң, | *кулларын өскә күтәрәләр,* |
| Әллә кая йөгерә. | *бер урында йөгерәләр.)* |

## Уңган балалар

| | |
|---|---|
| Безнең нәни аяклар | *(Балалар йөгерү* |
| Шәп итеп йөгерәләр. | *хәрәкәтләре ясыйлар,* |
| | |
| Куллар да калышмыйлар, | |
| Чәп-чәп итеп бииләр. | *кулларын чәбәклиләр,* |
| | |
| Шушы нәни балалар | *чүгәләп, уенчык җыю* |
| Уенчыкларны җыя. | *хәрәкәтләре ясыйлар,* |

Уенчыклар җыялар да
Урыннарга куялар.

*басып, «уенчыкларны куялар»,*

Апа әйткәч, балалар
Беркая да бармыйлар.
Тыныч кына утырып,
Әкиятләр тыңлыйлар.

*әкрен генә урыннарга утыралар.)*

## Бармаклар

Менә минем бармаклар,
Шаян алар, шук алар.

*(Балалар кулларын сузып, кул чукларын әйләндерәләр,*

Бармаклар гел уйныйлар,
Уйный-уйный туймыйлар.

*бармакка бармак сугалар,*

Менә минем бармаклар:
Баш бармак, имән бармак,
Урта, атсыз һәм чәнчә –
Бик дус алар, гел бергә.

*кулларын күрсәтеп, уң куллары белән сул кулның бармакларын берәм-берәм тотып чыгалар, кул чабалар.)*

## Коңгызлар

Коңгызлар оча жуылдап,
Бж-бж, бж-бж быжылдап.

*(Балалар «жу-жу» дип жуылдап, бүлмә буйлап йөгерәләр,*

Оча торгач арыдылар,
Идәнгә егылдылар.

*аркаларына яталар, аяк-куллары белән төрле хәрәкәтләр ясыйлар,*

Коңгызлар ял иттеләр,
Тагын очып киттеләр.

*очу хәрәкәтләре ясыйлар.)*

## Карагыз

Менә минем уң кулым, *(Уң кулларын күрсәтәләр,*
Менә минем сул кулым, *сул кулларын күрсәтәләр,*

Менә идән, менә түшәм, *өскә-аска карыйлар,*
Менә шулай зур үсәм. *аяк очларына күтәреләләр.)*

## Без атлап барабыз

Без атлап та барабыз, *(Балалар атлап баралар,*
Йөгереп тә барабыз, *йөгерәләр,*

Арып китсәк, утырып, *туктап, бер урында*
Аякларны язабыз. *тыпырдыйлар.)*

## Без рәсем ясадык

Без рәсемнәр ясадык, *(Йодрыктагы бармаклар*
Безнең бармаклар арыды. *бер ачыла, бер ябыла;*

Без хәзер ял итәбез, *кулларын аска төшереп,*
*бармакларын селкетәләр,*
Аннан тагын ясыйбыз. *рәсем ясау хәрәкәтләре ясыйлар.)*

## Куянкай

*Тәрбияче*. Ап-ак куян утырган,
Колакларын селкетә.

*Балалар.* Менә шулай, менә шулай *(Балалар баш өстенә*
Колакларын селкетә. *кулларын куеп*
*селкетәләр,*

*Тәрбияче*. Куян, туңа башлагач,
Тәпиләрен җылыта.

| | | |
|---|---|---|
| *Балалар.* | Менә шулай, менә шулай<br>Тәпиләрен җылыта. | *әле бер, әле икенче куллары белән кул ар-каларын сыйпыйлар,* |
| *Тәрбияче.* | Куян тагы да туңа,<br>Сикергәләп тә куя. | |
| *Балалар.* | Менә шулай, менә шулай<br>Сикергәләп тә куя. | *куяннар кебек сикерәләр,* |
| *Тәрбияче.* | Кем куянны куркытты?<br>Куян сикереп качты. | |
| *Балалар.* | Менә шулай, менә шулай<br>Куян сикереп качты. | *ике аякта сикереп баралар.)* |

## Бакчачылар

| | |
|---|---|
| Бакчачылар, әйдәгез,<br>Менә бакча юлыбыз. | *(Балалар кулларын алга сузалар,* |
| Әйдә, барыйк, сулар сибик,<br>Шиңгән булса гөлебез. | *атлап баралар,* |
| Су тутырып савытларга,<br>Кулларыбызга алыйк. | *башта бер, аннары икенче кул белән су сибү* |
| Рәхәтләнсеннәр чәчәкләр –<br>Сулар белән сугарыйк! | *хәрәкәтләре ясыйлар,* |
| Бакча юлы чүпләнгән,<br>Чирәм белән капланган. | *алга таба иеләләр,* |
| Көрәк, себеркеләр кирәк<br>Эшләргә безгә тизрәк! | *көрәк, себерке белән эшләү хәрәкәтләре ясыйлар.)* |

## Туганым

Балалар кара-каршы тезелеп басалар һәм, һәр әйтелгән сүзгә яраклаштырып, төрле хәрәкәтләр ясыйлар. «Бер, ике, бер, ике» дигәндә, кулларга тотынышып, әле бер якка, әле икенче якка берәр адым ясыйлар. Аннан соң үз тирәләре буйлап әйләнеп куялар. «Тук, тук» дигәндә, аякларны тыпырдаталар; «шап, шап» дигәндә, кул чабалар; «тик, тик» дигәндә, бармакларны селкетәләр; «мик, мик» дигәндә, башларны ияләр.

Өйрән биергә, туганым,
Менә бирәм кулымны.
    Бер, ике, бер, ике,
    Әйләнеп куй, бер, ике!
Аяк белән тук, тук, тук!
Кулың белән шап, шап, шап!
    Бер, ике, бер, ике,
    Әйләнеп куй, бер, ике!
Бармагың белән тик, тик!
Башың белән мик, мик, мик!
    Бер, ике, бер, ике,
    Әйләнеп куй, бер, ике!
Кабатла тагын, туганым!
Менә бирәм кулымны.
    Бер, ике, бер, ике,
    Әйләнеп куй, бер, ике!
Инде әйтә аламын:
Син бик матур биисең!
    Бер, ике, бер, ике,
    Әйләнеп куй, бер, ике!

## Кыен эш түгел бер дә!

Аякларың тыпырдат, *(Балалар аякларын тыпырдаталар,*
Кулларыңны чапылдат, *кул чабалар,*
Бер монда, бер монда –
Кыен эш түгел бер дә, *кулларын бер уңга,*
Бер уңга, бер сулга – *бер сулга чәбәклиләр,*
Кыен эш түгел бер дә.

Башыңны аска иеп ал, *башларын аска ияләр,*
Кул бармагың янап ал! *бармак яныйлар,*
Бер алга, бер артка – *әйләнеп алалар,*
Кыен эш түгел бер дә,
Бер уңга, бер сулга – *уңга, сулга бармак яныйлар;*
Кыен эш түгел бер дә.

Уң дустыңа кулың бир, *уң якта басып торган балага*
*кул бирәләр,*
Сул дустыңа кулың бир. *сул якта басып торган балага*
*кул бирәләр,*
Бер монда, бер монда – *кулларын бер уңга,*
Кыен эш түгел бер дә
Бер уңга, бер сулга – *бер сулга чәбәклиләр.)*
Кыен эш түгел бер дә.

## Аш пешерү

Ярдәм көтеп тормыйбыз, *(Балалар гәүдәләрен*
Яшелчәләр турыйбыз; *уңга-сулга боралар,*
Чиста итеп юабыз, *алга бераз иелә төшеп,*
*кул юу хәрәкәтләре ясыйлар,*
Без кәбестә турыйбыз. *«турыйлар»,*
Бераз кишер кырабыз, *учларын каплап, бармакларын*
*бер-берсенә ышкыйлар,*

| | |
|---|---|
| Ваклап суган турыйбыз, | *«турыйлар»,* |
| Тозлап, майлап алабыз, | *уң кул бармакларын уйнаталар,* |
| Яхшылап болгатабыз. | *кулларын беләзектән әйләндерәләр,* |
| Бигрәк тәмле, ашагыз! | *кулларын алга сузалар.)* |

## Кар бөртеге

| | |
|---|---|
| Кар бөртеге өйгә керде, | *(Балалар бер урында кулларын* |
| Өй эчендә очып йөрде, | *җилпеп әйләнәләр,* |
| | |
| Менә шулай, менә шулай, | *очып йөрү хәрәкәтләре* |
| Менә шулай, менә шулай. | *ясыйлар,* |
| | |
| Кар бөртеге бик аз очты, | *бер урында торып, кулларын* |
| Суздык аңа җылы учны, | *җилпиләр, кулларын алга сузалар,* |
| Менә шулай, менә шулай, | *чүгәлиләр,* |
| Менә шулай, менә шулай. | *башларын ияләр.)* |

## Кышкы урманда

| | |
|---|---|
| Кышкы урманга килдек, | *(Балалар бер урында атлап торалар,* |
| Матур урыннар күрдек. | *кулларын як-якка җәяләр,* |
| Тун кигән каен – уңда, | *уңга күрсәтәләр,* |
| Ямь-яшел чыршы – сулда. | *сулга күрсәтәләр,* |
| | |
| Кар бөртекләре оча, | *кулларын өскә күтәреп* |
| Әйләнеп җирне коча. | *әйләнәләр,* |
| Әнә куян сикерә, | *ике аякта сикерәләр,* |
| Ул бүредән элдертә. | *бер урында йөгерәләр,* |
| | |
| Кызылтүшләр очалар, | *кулларын җилпиләр,* |
| Бигрәк тә матур алар. | *кулларын як-якка җәяләр,* |

Урманда рәхәт булса да, *бер урында атлап торалар.)*
Өйгә кайтыйк, балалар.

## Чәчәкләр

Гөлчәчәкләр күренде *(Балалар басалар,*
Һәм кояшка үрелде. *кулларын югары күтәрәләр,*
Аларга җылы кирәк, *кулларын як-якка җәяләр,*
Кояш астында рәхәт!

Җил исте. *чайкалалар,*
Чәчәкләрне селкетте:
Уңга бөгелделәр, *уңга иеләләр,*
Җиргә иелделәр. *чүгәлиләр,*
Сулга бөгелделәр, *торып, сулга иеләләр,*
Җиргә иелделәр. *чүгәлиләр,*

Бар син, җил, моннан кит, *торып, кулларын селкиләр,*
Чәчәкләргә тими үт.
Алар зур булып үссен, *кулларын югары күтәрәләр,*
Безгә шатлык китерсен. *кул чабалар.)*

## Куллар

*Балалар парлашып, бер-берләренә карап басалар.*

Менә сиңа уң кулым, *(Икесе дә кулларын шапылдаталар һәм уң кулларын бер-берсенә сугалар,*
Менә сиңа сул кулым. *кул чабалар, сул кулларын сугалар,*
Уң кулым, сул кулым, *кул чабалар, уң һәм сул кулларын чиратлашып чабалар,*
Менә сиңа куш кулым. *кул чабалар, кулларын бер-берләренә сугалар.)*

## Утырып арыдык

*Балалар сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.*

Утырып инде арыдык,
Бераз ял итеп алыйк.
Кулларны билгә куеп,
Башларны чайкап карыйк.
Куллар билгә, өскә, янга,
Утырып-торып алыйк.
Кушаяклап сикерик тә
Урыныбызга утырыйк.

## Без инде хәзер зурлар

| | |
|---|---|
| Без инде хәзер зурлар, | *(Балалар, аяк очларына басып, кулларны югары күтәрәләр,* |
| Күп эшли безнең куллар. | *кулларны төрле якка хәрәкәтләндерәләр,* |
| Без идән дә юабыз, | *аска иелеп, идән юу хәрәкәтләре ясыйлар,* |
| Без керләр дә уабыз, | *куллар белән кер юу хәрәкәтләре ясыйлар,* |
| Гөлләргә су сибәбез. | *гөлгә су сибү хәрәкәтләре күрсәтәләр,* |
| Менә шундый уңган без, | *аяк очларына басып,* |
| Менә шундый булган без. | *түгәрәктә әйләнәләр.)* |

## Без яздык

| | |
|---|---|
| Без яздык, без яздык, | *(Балалар йодрыктагы бармак-* |
| Безнең бармаклар талды. | *ларын бер ачалар, бер ябалар,* |
| Без хәзер ял итәбез, | *кулларын аска төшереп, бармакларын селкетәләр,* |
| Аннан язып китәбез. | *язу хәрәкәтләре ясыйлар.)* |

## Һәркайсының үз эше

*Исеме әйтелгән һәр бармак бөкләнә бара.*

| | |
|---|---|
| Баш бармак бау ишә. | *(Балалар бау ишү хәрәкәтен,* |
| Имән бармак имән кисә. | *агач кисү хәрәкәтен,* |
| Урта бармак ут кабыза. | *шырпы сызу хәрәкәтен,* |
| Атсыз бармак ат җигә. | *атта йөрү хәрәкәтен,* |
| Чәнти бармак чәй эчә. | *чәй эчү хәрәкәтен ясыйлар.)* |

## Кер юу

*Балалар түгәрәкләнеп басалар һәм җыр сүзләренә туры килгән хәрәкәтләр ясыйлар.*

Мин тик тормыйм, эш эшлим,
Җиң сызганып, кер уам.
Керләр уам, керләр уам,
Керләр чайкыйм, керләр юам.

Керләрем инде агарган,
Мин аларны җилгә эләм.
Керләр эләм, керләр эләм,
Кипсеннәр кояш белән.

Керләрем кипкән, кулыма
Кер җыям, керләр җыям.
Аннары бер үтүк алып
Үтүкләп, төреп куям.

Юдым, чайкадым, элдем,
Керләрем кипкәч җыйдым,
Үтүгемне кыздырып,
Үтүкләп, төреп куйдым.

## Кер юучылар

*Хәрәкәтләр шигырь эчтәлегенә туры китереп ясала.*

Без – яхшы юучылар!
Без керләрне уабыз,
Менә ничек, менә ничек
Без керләрне уабыз!

Без – яхшы чайкаучылар!
Без керләрне чайкыйбыз,
Менә ничек, менә ничек
Без керләрне чайкыйбыз.

Киптерергә кирәк бит!
Керне бауга эләбез,
Менә ничек, менә ничек
Керне бауга эләбез!

Кипкәчтен, без аларны
Баудан җыеп алабыз,
Менә ничек, менә ничек
Баудан җыеп алабыз.

Кипкән ап-ак керләрне
Үтүклибез, төрәбез,
Менә ничек, менә ничек
Матур итеп төрәбез.

## Атлап йөргәндә

Дуслар белән бергә җырлашып,
Тезелеп йөреп, бергәләп басып,
Башны күтәреп, күкрәк киереп,
Кулларны селкеп, басабыз дөп-дөп!

Кыр казлары күк тип-тигез генә
Тезелеп барабыз, күрәсез менә!
Болай җыелып, тезелеп бергә,
Күңелле, кызык, шәп булыр безгә.

## Мәрьям әби малайлары

*Уйнаучылар түгәрәккә тезеләләр. Бер бала түгәрәк уртасында басып тора.*

| | |
|---|---|
| Мәрьям әби янында | *(Балалар түгәрәк буенча йөриләр,* |
| Җиде малай утыра, | |
| | |
| Бар да сары кашлылар, | *туктыйлар,* |
| Менә шундый башлылар, | *башларын ике куллары белән тотып як-якка чайкыйлар,* |
| Колаклары – шундыйрак, | *колакларын ышкыйлар,* |
| Ә күзләре – мондыйрак, | *баш һәм имән бармактан боҗра ясап, күзләренә куялар,* |
| Борыннары – мондыйлар, | *борын өстенә йодрыкларын куялар,* |
| Җидесе дә – шундыйлар. | *кулларын як-якка җәяләр.)* |

## Гимнастика уеннары

Уң аягың дөп-дөп бас, дөп-дөп бас!
Сул аягың дөп-дөп бас, дөп-дөп бас!

Кулларыңны чап уңга, чап сулга, куй алга!
Кулларыңны чап алга, чап артка, куй алга!

Уңга борыл, алга атла бер адым,
Сулга борыл, алга атла бер адым!

Алга кара, кулларыңны куй янга!
Кулларыңны суз алга, куй янга!
Кулларыңны суз артка, куй янга!

Я, башыңны уңга бор, алга бор!
Я, башыңны сулга бор, алга бор!
Я, башыңны уңга сал, турыга ал!
Я, башыңны сулга сал, турыга ал!

Я, башыңны артка сал, алга ал!
Я, башыңны алга сал, урынына ал!

Алга атла өч адым: бер адым, ике адым, өч адым!
Артка атла өч адым: бер адым, ике адым, өч адым!
Уңга атла өч адым: бер адым, ике адым, өч адым!
Сулга атла өч адым: бер адым, ике адым, өч адым!

Уңга борыл, алга атла бер адым!
Артка әйлән, алга атла бер адым!
Сулга борыл, алга атла бер адым!
Артка әйлән, алга атла бер адым!

Уңга атла, артка атла бер адым!
Сулга атла, алга атла бер адым!
Сулга атла, артка атла бер адым!
Уңга атла, алга атла бер адым!

Уңга борыл, артка әйлән, сулга борыл,
Сулга борыл, артка әйлән, уңга борыл!

## САНАМЫШЛАР

*(Дәресләрдә, уен вакытларында, физкультура шөгыльләрендә файдалану өчен)*

Бер, ике, өч,
Әнә тегендә көч.

Бер, ике, өч,
Сиңа көч,
Син моннан күч.

Ипи, тоз,
Матур кыз.

Карга, чыпчык,
Берең кал да,
Берең чык.

Җепсез орчык,
Чәүкә, чыпчык,
Кара балчык,
Син кал, бу чык!

Ун, тугыз, сигез –
Әй симез үгез.
Җиде, алты, биш –
Бүре килә ич.
Дүрт, өч, ике, бер –
Тиз качып өлгер!

100, 90, 80 –
Калырсың исән.
70, 60, 50 –
Тизрәк кач инде.

40, 30, 20 –
Әйтмәдең димә, яме,
10 – абзарыңда кун!

Өйгә кергән бер чыпчык,
Очып йөри чык-чырык.
– Чыпчык, чыпчык, син, чыпчык!
Атлап түгел, очып чык!

Тор, тор, тургай,
Таң ата бугай,
Тургай, чыпчык,
Син кал, бу чык!

Аладан, боладан,
Песи бара колгадан.
Песи түгел, ата каз,
Ата каздан тизрәк кач!

Әке, пәке, эремчек,
Син калып тор, ә бу чык.

Әлчи, бәлчи,
Әни күлмәк үлчи,
Үлчи торгач җитмәде,
Кисә торгач бетмәде.
Чәүкә, чыпчык,
Син кал, бу чык!

Ыргада, мыргада,
Мәче йөри елгада.
Эремчек, төн чык,
Син кал, бу чык.

Песи-песи поскан,
Ике күзен кыскан,
Кысса, безне тота алмый,
Тотар иде – җитә алмый.
Пес-пес-пес.

Җыелганнар кошкайлар –
Безнең нәни дускайлар:
Песнәк, чәүкә, саескан,
Күгәрчен артка поскан.
Син, карга, син, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык!

Мияу, мияу мышлаган,
Мич башында кышлаган.
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде – йоклаган.

Саескандай чайкалып,
Мин йөримен, өй саклап.
Каздай булып, кыйгаклап,
Сиңа тиям, син әбәк!

Ыргадан, мыргадан,
Мәче йөри колгадан.
Мәче түгел, ата каз,
Ата казның башы таз.
Сыртыңа төшкәнче таш,
Тизрәк моннан чыгып кач!

Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алты, җиде, сигез, тугыз, ун.
Байлар кия төлке тун.
Төлке тунның бәясе –
Йөз дә кырык сигез сум.

Саесканның койрыгы –
Саный китсәң – унике,
Сыңар аяк, сыңар чык,
Син калып тор, ә син чык!

Елгада бар бер басма,
Син анда ялгыш басма.
Әгәр бассаң китереп,
Кырыйга чык, сикереп.

Гөр-гөр гөлдер бу,
Гөрләр күгәрчендер бу.
Карыйк-карыйк каргалар,
Шыгырдаган арбалар.
Торыйк-торыйк торналар,
Тау башында юргалар.
Чут-чут сандугач,
Тәрәзәдә карлыгач.
Чырык-чырык куар чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык!

Кулда уймак,
Табада коймак,
Мичтә бәлеш –
Ал да ябыш.
Чүрәкәй үрдәк
Чум да чык!

Берәм, берәм, берәмләп,
Әби йөри, кеше әрләп,
Кәҗәләрен кешәнләп,
Бабай бара басуга,
Сулга карый ун агай,
Уңга карый ун агай,
Бар чыгып кит син, агай!

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде.
Тау башлары ачылды,
Ак ташлары чәчелде.
Сайрыйлар тургайлар,
Шалтырыйлар сабаннар.
Моңая сыерчык,
Җыр җырлый чыпчык,
Син тор, бу чык!

Каенда – карга,
Имәндә – чыпчык,
Җирдә – елан,
Һавада – кош,
Бар син дә оч!

Әлчи, бәлчи,
Әни күлмәк үлчи,
Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң очып чык!

Алачык, салачык,
Салачыкта калачык,
Калачыкта балачык,
Балачык – малайчык,
Качма алай, малай, чык!

Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

Чәйнеккә акча салдым.
– Ничә булды?

– Йөз булды.
Әтәлчек, мәтәлчек,
Синә туры килде, чык!

Чистай – чигәнәк,
Алабуга – бигәнәк.
Мин йөримен, күзаллап,
Шап!

Саескандай чайкалып,
Мин йөримен, өй саклап.
Син йокыңнан уян,
Озын колаклы куян.

Бер тай, ике тай,
Өч тай, дүрт тай,
Монда торма, чыгып тай.

Аладай, каладай,
Чистай, Чикәнәй,
Алабуга – ак балык,
Син кал, бу чык.

Мин барамын базарга,
Алтын-көмеш сайларга.
Ал чук, зәңгәр чук,
Монда торма, тизрәк чык.
Ялкау, чытык, мактанчык,
Мактанчыкка – буш капчык.
Буш капчык, уеннан чык!

Кырма чыбык, сары янчык,
Карчык, кызчык,
Син кал, бу чык.

– Зәйни, Зәйни, Зәйнәбем,
Атны кайда бәйләдең?
– Алмагачка бәйләдем.
– Алма төште шап итеп,
Зәйнәп чыкты ялт итеп.

Алма, шикәр, бавыр, агач,
Тик торма син, ал да кач.

Уйдык, уйдык урман,
Урманда тормам;
Типтәр, мишәр, башкорт,
Сиңа җитте, бар чык.

Ыргада, мыргада,
Мәче йөри колгада,
Сыер йөри елгада,
Ары чык, бире чык,
Монда торма, йөгереп чык.

Ары алачык, бире алачык,
Кыр капкасы шар ачык.
Умырык, томырык,
Монда торма, йөгереп чык.

Алатыр, булатыр,
Тау ягыннан таң атыр,
Аны көтеп торганчы,
Алга таба бара тор.

Алатыр, булатыр,
Тау ягыннан таң атыр,
Эремчегең эретер.
Эремчек, биремчек,
Син кал, бу чык.

# БАЛАЛАРНЫ УЕНГА ҖЫЮ ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР, ҖЫРЛАР

*(«Әйләнә-тирә дөнья белән таныштыру» дәресләрендә файдалану өчен материаллар[1])*

## Бакча балалары

Барча балалар
Бергә җырлашып,
Тезелеп барабыз.
Бергәләп басып,
Башны күтәреп,
Күкрәкне киереп,
Кулларны селкеп,
Басабыз дөп-дөп!
Әйдәгез, сез дә
Кушылыгыз җырга,
Бакчага барыйк,
Тезелегез бергә,
Көн буе эшсез,
Өйдә күңелсез,
Бакчада кызык,
Барыйк, күрерсез!
Апа күңелле
Әкият сөйли,
Балалар тып-тын –
Апаны тыңлый.
Әкият бетә,
Менә уйныйбыз,
Уенга кушылып,
Җырлар җырлыйбыз.

---

[1] Бу бүлеккә кертелгән шигъри үрнәкләр С. Миңлекәйнең «Балалар өчен җырлы уеннар» (1925), «Тезмә сүзләр» (1931) һәм З. Салихованың «Мәктәпкә кадәр тәрбия өчен кулланма» (1925) китапларыннан алынды.

Бакчабыз матур,
Рәсемле, ямьле,
Уенчыклар күп,
Анда күңелле.
Ясыйбыз буяудан
Без рәсемнәр,
Шакмактан – йортлар,
Балчыктан – сыннар.
Гөл үстерәбез
Кызылсу-алсу,
Үзебез пешерәбез
Ашарга аш-су.
Савыт-сабаны
Үзебез юабыз,
Бакчаны ямьле
Итеп җыябыз.
Әйдәгез, әйдә,
Кош-корт, мал-туар,
Куян, эт, мәче –
Анда барысы бар.
Уйнарбыз атлы,
Уйнарбыз туплы,
Яулык салышу,
Куыш-куышлы.
Әйдәгез, сез дә
Тезелегез бергә,
Бакчага барыйк,
Кушылыгыз безгә!

## Җәй көне

Яз җиткәч, җир кипкәч,
Саф аяз көннәрдә
Чыгарбыз юл буйлап
Зәңгәрсу кырларга.
Чәчәкләр җыярбыз,
Күбәләк куарбыз,
Шундый саф һавада
Бик рәхәт җырларбыз.
Күп йөрсәк, уйнасак,
Эсселәп тирләсәк
Чумарбыз тиз генә
Көмештәй күлләргә.
Уйнашып-көлешеп,
Йөгерешеп кайтырбыз,
Куанып-куанып,
Әнкәйне үбәргә.

## Бала һәм сандугач

***Бала***

Сары сандугачкаем,
Башың игәнсең!
Сайрамыйсың да,
Бик моңайгансың?

***Сандугач***

Яшел агачта сайрап,
Мин көн кичердем,
Ә алтын читлектә
Ничек гомер итим?
Яшел агач ботагы
Рәхәт сайрарга,

Алтын читлек эчендә
Мин зур кайгыда.
Яшел агач ботагы
Гомер иттерә.
Алтын читлек эчләре
Үлем көттерә.
Яшел сахрада, елап,
Балакаем көтә.
Һәммә туганкайларым
Миңа аһ итә...

*Бала*

Сөекле кошчыгым,
Инде мин аңладым,
Синең сүзләреңне
Чыннан да тыңладым.
Алтын читлек ишеген
Ачамын мин сиңа,
Котылдың син хәзер –
Рәнҗемәче миңа!

## Күке

Ишетеләдер кайчакта
Ерак елга артында:
«Күк-кү, күк-кү!»
Ерак елга артында.

Кечкенә кошчык сайрый
Яшел яфрак астында:
«Күк-кү, күк-кү!»
Яшел яфрак астында.

Югалткан балаларын,
Кычкырып эзли аларны:
«Күк-кү, күк-кү!»
Кычкырып эзли аларны.

Ямансулый бичара,
Яңгырата моң даланы:
«Күк-кү, күк-кү!»
Яңгырата моң даланы.

## Күгәрченнәр

– Гөлдер-гөлдер-гөлдергү,
Бигрәк матур, кемдер бу?
Тарап үргән чәчләрен,
Өсте-башы бик ару.
– Гөлдер-гөлдер-гөлдергү,
Бер әдәпле кыздыр бу,
Мәктәп атлы бакчаларда
Чәчәктер бу, гөлдер бу!

## Кошлар җыры

Без, кошлар, ирекле, яратабыз ирекне,
Очарга, уйнарга киңлекне, киң күкне.
Оябыз урманда – нинди күңелле анда!
Урман тын булганда һәм шаулап торганда,
Челтер-челтер чишмәләр сөйләшеп көлгәндә,
Кош-кортлар, кайнашып, шау да гөр килгәндә.
Әй дустым, бармы соң урманда йөргәнең?
Тын урман, шат кошлар, шат чишмә күргәнең?
Урманның шаулавын, чишмәләр гөрләвен,
Шат кошлар җырлавын бармы тыңлап торганың?

## Бозау

Кичкә таба, сузып-сузып, кечкенә бозау кычкыра.
Сагынган ул әнкәен, бакырып, шуны чакыра.
Мөгри-мөгри, анасы кайтып керде көтүдән,
Йөгереп барды баласы, имеп туйды сөтләрен.
Имеп туйгач, шатлыгыннан уйный, чаба, сикерә,
Әнкәсенең тирәсендә әрле-бирле йөгерә.
Карап тора анасы: сикереп уйный баласы,
Нинди матур, нинди сылу баласы – күз алмасы!

## Хайваннар тавышы

Ат кешнидер: «Миһаһай!
Безнең Гали, ди, кайда?»
Кәҗә әйтә: «Мәэ, мәэ, мәэ!
Гали китте мәктәпкә».
Сыер әйтә: «Му, му, му!
Ул соң яхшы укыймы?»
«Ау, ау, ау! – дип эт өрә, –
Безнең Гали күп белә!»
Үрдәк әйтә: «Бак, бак, бак!
Күп белсә, аңа рәхмәт!»

## Хайваннар чакыру

Чакырамын мәчене мин:
«Пес, пес, пес, пес!»

Чакырамын Актабанны:
«Кес, кес, кес, кес!»

Чакырамын Алабайны:
«Маэ, маэ, маэ, маэ!»

Чакырамын туры атымны:
«Бах, бах, бах, бах!»

Чакырамын колынкайны-сылуны:
«Гүли, гүли, гүли, гүли!»

Чакырам сарыкны:
«Тәчтәй, тәчтәй, тәч, тәч, тәч!»

Чакырамын кәҗәне:
«Кәҗә, кәҗә, кәч, кәч, кәч!»

Сыерымны чакырмаганмын да әле!
«Түгәнәй, түгәнәй, түгәнәй, тәгәнәй
Тәй, тү!..»

## Әнә мәктәп, әнә балалар!

Әнә мәктәп, әнә балалар!
Портфельләр тотып, шунда баралар.

*

Гөрләп торган көчле умартадай,
Мәктәп эче шау да гөр килә,
Шат күңелле уен-көлке, чыр-чу,
Бала-чага тавышы ишетелә.

Чылтырады шунда кыңгырау,
Ә балалар тып-тын калдылар:
Алмаш-тилмәш китап укыдылар,
Дәфтәр алып, язу яздылар.

Ялга чыгып, тагын шауладылар,
Тагын җыелып, шигырь әйттеләр,
Укытучы сүзен тыңладылар,
Саубуллашып кайтып киттеләр.

Алар шулай көн дә киләләр,
Тырышып, сабакларын беләләр.
Үсеп җиткәч, алар, белемлеләр,
Илне төзүчеләр булырлар.

**Поезд**

Ул чабадыр бик каты, бик шәп кызып,
Артына бик күп вагоннарны тезеп.
«Пош, – ди ул, – пош-пош!» – ди ул, тынын ала,
Борыла-сызыла тик төтен сузылып кала.

Ул чаба тиз таулар-урманнар буйлап,
Тип-тигез уйсу, түбән җирләр буйлап.
Күп кала, авыллар үтеп ыргыла,
Барысы күз йомган арада юк була.

Ник чаба ул? Көн чаба һәм төн чаба
Зур шәһәрләрдән авылларга таба?
Кайбер урыннарда ялга туктала,
Туктала, пош-пош итеп, ул тын ала.

Бер караганда күрәсең син аның
Әйләнеп киткән юлыннан кайтканын.
Бу юлы да бик кызык, бик шәп чаба,
Тик авыллардан шәһәрләргә таба.

Ул чаба авылга бар көч-хәл белән,
Чәй, шикәр, тоз һәм ашамлыклар белән,
Икмәк игәрдәй машиналар килә
Эшчеләрдән күп сәламле хат белән.

Әйтергәме, әйләнеп, ул ник чаба
Баягы юлдан шәһәрләргә таба?
Ул төягән икмәк, ит һәм дә тире,
Авылдан шәһәрләргә кайта кире.

Авыллардан шәһәргә чаптыра,
Эшчеләр өчен ашамлык тараттыра.
Кемгә, кайчан ни кирәкне шәйли ул,
Эшче, игенчене шулай бәйли ул.

## Кармак салганда

Әкрен генә су ага
Яр буенда комлыкта,
Кармак салып утырабыз
Малай-шалай эш юкта.
Сөйләшкәлибез үзебез,
Калкавычта – күзебез;
Сабырсызлар сөйләнсә,
«Чүгез, дибез, түзегез!»
Балык озак капмаса,
Без җырлыйбыз, такмаклап:
«Тфү, тфү, балык кап!
Яр башында ялтырап ят!»
Вәли: «Чиртә, чиртә!»
Галәви: «Нәрсә бу?»
Вәли: «Әле чиртә, чумды бу!»
Галәви: «Карап торма, ачык авыз,
Ал тизрәк, йотты бу!»
Алды Вәли кармагын,
Калды балык шып итеп,
«Ал дип торам, ачык авыз,
Тордың әллә ни көтеп», –
Дип сукранды Галәви.
Вәли башын кашыды:
«Беләк буе бар иде,
Төште китте бит», – диде.
Янды Вәлинең йөрәге.

Бер зур гына корт саплап
Салды тагын кармагын,
Төкерә-төкерә такмаклап:
«Тфү, тфү, балык кап, кап, кап!
Яр башында ялтырап ят, ят, ят!»
Балык чиртми башлады,
Без аларга җим сибәбез,
Үзебез авыз эченнән
Әкрен генә көйлибез:
«Тфү, тфү, балык кап, кап, кап!
Яр башында ялтырап ят, ят, ят!»
«Шуны ала алмадың», – дип,
Вәлине гаеплибез.
«Иртә син салдың», – дибез,
«Юк, соңга калдың», – дибез.
Шунда шаулашып киттек.
Балык чиртми, аптыраш,
«Мин булсам, әй, мин булсам», –
Дибез без – акыллы баш.
Балык чиртми, көттек без,
Вәлине нык теттек без,
Бәлки, балык булыр диеп,
Таңга кадәр көттек без!

## Торналар җыры

«Торыйк, торыйк, торыкланып,
Канатларны селкеп, селкеп,
Киң һаваны җилләндереп,
Канатларны җилпеп-җилпеп
Очабыз без, җырлый-җырлый:
– Торылдырыйк, торыйк, торыйк!

Бергә-бергә гомер сөрик,
Бергә очыйк, йөрик, торыйк.
Очабыз без ил өстендә,
Нинди матур, нинди дуслык,
Торыйк-торыйк без дә менә!»

Шулай җырлап очучы
Торналарга карап торып
Исем китте, рәткә тезелеп,
Матур җырлауларын күреп!

## Каз бәбкәләр чыгаргач

– Кыйгак, кыйгак, кайчан чыгасың? – дип
Каңгылдады тышта ата каз.
– Хәзер, хәзер чыгам, чыгам, – диеп
Җавап бирде аңа ана каз.
– Пип, пип, әнкәй, кайда, кем кычкыра? –
Дип бәбкәләр сорый анасын.
Әнкәләре сөйли Тимербайның
Су буена алып барасын.
– Каңгылдыйдыр тышта, чыгыгыз дип,
Минем дустым – сезнең атагыз.
Су буена яшел чирәмлеккә
Чыгабыз, я, тизрәк ашагыз!
Исәйдегез инде, нык басасыз,
Балаларым, безгә өйдә тар.
Әрәмәле, сулы, аллы-гөлле
Чәчкәләргә бик бай дөнья бар.
Шунда Тимер безне алып барыр,
Җырлый-җырлый карап үстерер.
Су буенда яшел чирәмнәрдә
Сез үсәрсез, сезгә көч килер.

Усаллардан анда курку бетәр,
Киң суларда чумып уйнарбыз,
Канатларны җилпеп, һаваларда
Тезелеп, җырлый-җырлый очарбыз.
Их!
Балалар, дөнья нинди ямьле,
Алда нинди тормыш күңелле,
Алда шатлык, алда якты көннәр!
Кыйгак-гак!...
Җилкендерә дәртле күңелне!...

## Каз бәбкәләре саклаганда

Авыл читендә, ындыр янында
Яшел чирәмдә, чишмә буенда
Көмеш тавышлы казлар каңгылдый,
Яшь бәбкәләре шунда пипылдый.
Балалар уйный киртә чыгышлы,
Бераз ял иткәч, аннан – качышлы.
Тып-тын калалар, шаулап көлешәләр,
Посып торалар, чабышып куышалар,
Шатлык, ямь тулган, дөнья онытылган.
Туктагыз, көшшү! Әнә бит тилгән!
Балалар кинәт уйнамас булды,
Каз бәбкәләре куркып чыелдый.
Күктә, биектә, усал уй белән,
Теш-тырнак кайрап оча бер тилгән.
Балалар шунда барысы да бердәм
Һавага карап кычкыра җирдән:
– Тилгән, тилгән!
Бәбкә алырга килгән!
Бер аягы –тимердән,
Бер аягы – күмердән.
Көшшү, көшшү, көшшү!

## Кошларны чакыру

«Дөгә, дөгә», – дип чакырсам,
Казлар йөгерә, каңгылдап,
«Бетеш, бетеш» – дигәндә,
Үрдәк килә, бакылдап.
«Биби, биби», – дип чакырсам,
Бәбкәләр дия: «Пип-пи»,
Йөгерәләр тиз-тиз, куанып,
Безгә бирә су, җим, дип.
«Ти, ти, ти»,– дип чакырсам,
Тавыкларым кытаклап,
Канатларын җилпеп-җилпеп
Йөгерә тиз-тиз, шәпләп.
«Чеп, чеп, чеп», – дип чакырам,
Чебешләргә җим бирәм,
«Күк, күк, күк», – дип чакырам,
Күркәләр туендырам.
Мин – кошларның чын дусты,
Алар мине сөяләр,
«Җим бирәсең, туйдырасың,
Рәхмәт», – дип баш ияләр.

## Яңгыр һәм балалар

Җил җилләде. Таулар, урманнарның
Ары башыннан куе, караңгы
Зур болытлар, тирә-якка агыла-
Агыла, илне каплап таралды.
Урамнарда уйнап йөрүче
Бала-чага күккә карады.
Бер-берсенә алар эндәштеләр:
«Яңгыр килә, яңгыр, кара әле!»
Шатлыклары эчкә сыймады.

«Яңгыр, яу, яу, яу,
Ашлык, уң, уң, уң!» –
Дип, алар бердәм җырлады.
Дөбер-шатыр килеп күк күкрәде,
Ялт-йолт итеп яшен яшьнәде.
Болытлардан төймә-төймә яңгыр
Шыбыр-шыбыр ява башлады.
Шунда, биш минут та үтмәгәндер,
Гөрләвекләр ага башлады,
Төймә-төймә яңгыр вaклары
Сәйлән-сәйлән тама башлады.
Тагын дөбер-шатыр күк күкрәде,
Болытларны җилләр каулады.
Гөрләвекләр агып гөжләделәр,
Аккан сулар тагын шаулады,
Балакларын сызганган балалар
Лычкыл-лычкыл килеп чаптылар.
Болытларны куып, кояшны
Чакырырга такмак таптылар:
«Эт кояшы, кит, кит, кит!
Майлы ботка бирермен.
Тәти кашык базарда, базарда,
Майлы ботка казанда, казанда».
Кояш килеп чыкты, нурын сипте,
Иркәләнде дөнья, җанланды,
Җир йөзе яшел хәтфә юрганга
Төренде, тәмам нурланды.

## Буш уй

Әй уйный, сикерә яланда бер куян,
Мин тотарга омтылам, ул куркудан
Күз ачып йомганчы читкә сикерә, юк,
Миннән ул куркып ерак-ерак шылган...
Анда тыныч төсле, ашамлык та мул,
Анда да дерт-мерт итә, курка күңел!
Иснәнә, борынын күтәреп, як-ягын,
Ниндидер шомлык барын да сизенә ул.
Шунда мин аннан качып-посып кына киләм,
«Ә, куян, эләктең», – дип, эчтән көләм.

## Йорт казы белән ат

«Мин оча да беләмен,
Мин йөзә дә беләмен,
Тирән сулар өстендә
Эһ, димимен, йөзәмен», –
Дип мактанды йорт казы
Бервакыт ат алдында.
Җавап бирде, уйланып,
Башын селкеп, ат шунда:
«Ярар иде мактанырга,
Тәкәрлектәй йөгерә алсаң,
Торна кебек оча алсаң,
Балык кебек йөзә алсаң».

## Унга чаклы санау

Таҗи килде мәктәпкә
Иртән иртүк ялгызы.
Иптәшләре килмәгән,
Ялгызы ул, берүзе.

Шунда ишек ачылды,
Гата иптәше килде,
Укучылар мәктәптә,
Я, сана, ничә булды? (1+1=2)

Болар икәү торганда,
Тагын ишек ачылды,
Укучы Сара килде,
Я, сана, ничә булды? (2+1=3)

Өчәү алар сөйләшеп
Торганда, ишек ачып,
Укучы Сафа килде,
Я, сана, ничә булды? (3+1=4)

Дүртәү алар сөйләшеп
Торганда, ишек ачып,
Укучы Зәйнәп килде,
Я, сана, ничә булды? (4+1=5)

Бишәү алар сөйләшеп
Торганда, ишек ачып,
Укучы Сабир килде,
Я, сана, ничә булды? (5+1=6)

Алтау алар сөйләшеп
Торганда, ишек ачып,
Укучы Шакир килде,
Я, сана, ничә булды? (6+1=7)

Җидәү алар сөйләшеп
Торганда, ишек ачып,
Укучы Мәрьям килде,
Я, сана, ничә булды? (7+1=8)

Менә сигез янына
Тагын ишек ачылды –
Укучы Мирза килде,
Я, сана, ничә булды? (8+1=9)

Янә ишек ачылды,
Укучы Закир килде,
Барысы бергә мәктәптә,
Я, сана, ничә булды? (9+1=10)

Ярый, унау булдылар,
Икешәр тезелделәр,
Инде санап карачы,
Ничә ике булдылар? (5)

**Уннан кирегә санау**

Ун кош кыркылдап утыра куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (10–1=9)

Тугыз кош калды, диден, куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (9–1=8)

Сигез кош калды, диден, куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (8–1=7)

Җиде кош калды, диден, куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (7–1=6)

Алты кош калды, диден, куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (6 – 1 = 5)

Ярый, биш кош калды, диден, куакта,
Шуннан берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (5 – 1 = 4)

Ярый, дүрт кош калды, диден, куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (4 – 1 = 3)

Ярый, өч кош калды, диден, куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (3 – 1 = 2)

Ярый, ике кош калды куакта,
Шуның берәве очты еракка,
Очты еракка ул, җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (2 – 1 = 1)

Ярый, бер кош калды, диден, куакта,
Менә ул да очты еракка,
Иптәшләре очкан җылы якка,
Ничә кош калды инде куакта? (1 – 1 = 0)

## Бала белән ата

– Кем, ватып тауларны, таштан зур, биек йортлар сала?
Кем көче, кем кодрәте белән корыла зур кала?
– Эшче, тау-ташларны ватып, зур, бөек йортлар сала,
Эшче кулы, эшче көче белән корыла зур кала.
– Ничә миллион бу халыкларга ашарга кем бирә?
Өскә-башка яхшы киемнәрне кем кидерә?
– Ничә миллион бу халыкларны игенче туйдыра,
Өскә-башка яхшы киемнәрне эшче кидерә.

## Бала белән күке

***Бала***

Кая очасың, Күке бәгърем, күк-кү?
Кая очасың, җан тирәгем, күк-кү?

***Күке***

Очам, очам мин урманга, күк-кү,
Иркендә җырларга анда, күк-кү, күк-кү, күк-кү...
Әйдәгез сез дә урманга, күк-кү,
Күңелле һәм кызык анда, күк-кү, күк-кү, күк-кү!

## Беләмсез, без кем?

*(табышмак)*

Озын койрык, гәүдә кечкенә,
Беләмсез, кем без, уйлагыз менә!
Мәчеләр безгә дошман, куркабыз,
Идән астында тик тормыш корабыз.
Чүбе-чүпрәкне шунда ташыйбыз,
Бала-чагага урын ясыйбыз.
Икмәк-итне урлап кына ашыйбыз,
Кеше күзеннән куркып яшибез.

*(тычканнар)*

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


Агишева Р. Л. *Фольклор и литература Башкортостана:* учебная хрестоматия для детей дошкольного и младшего школьного возраста / Р. Л. Агишева. – Уфа: Китап, 2011. – 176 б.

*Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы* / М. А. Васильева, В. В. Гербова, Т. С. Комарова ред.; русча 4 нче басмадан К. В. Закирова, Р. Ә. Кадыйрова, З. Г. Ибраһимова һ. б. тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2006. – 286 б.

*Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү* (Программаның милли-төбәк компоненты юнәлеше) = Воспитание и обучение в детском саду (Национально-региональный компонент Программы) / төз.-авт.: К. В. Закирова, Р. А. Борһанова, Г. Ә. Галиева һ. б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 167 б.

*Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен* / төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984

*Башкирский детский фольклор* / авт.-сост.: А. М. Сулейманов, И. Г. Галяутдинов. – Уфа: Китап, 2011. – 184 с.

Галеев Э. Х. *Татарские народные игры и праздники*: кн. для учителя / Э. Х. Галеев, Я. И. Ханбиков. – 2-е изд., перераб. и доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 104 с.

Гарафиева Г. З. *Сөмбеләне кем белә?* Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен методик ярдәмлек. – Казан, ТаРИХ, 2003. – 191 б.

*Детские подвижные игры народов СССР*/ сост. А. В. Кенеман. – М., Просвещение, 1988. – 240 с.

Закирова К. В. *Уйный-уйный үсәбез*: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма / К. В. Закирова. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2010. – 175 б.

Закирова К. В., Гаффарова С. М. *Әткәм-әнкәмнең теле*. – Казан: Мәгариф, 1997.

*Иң матур сүз* / төз. К. В. Закирова. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

*Мәктәпкәчә тәрбия яшендә уеннар* /төз.-тәрҗ. Г. Сөләйман. – Казан: К. Якупов ис. тип., 1927. – 67 б.

*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен хәрәкәтле 16 уен һәм җәйге тәрбия мәйданында аларны үткәрү кагыйдәләре.* – Казан: Татгосиздат, 1933. – 16 б.

*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кагыйдәле хәрәкәтле уеннар* / төз.: Г. Шакирова, Г. Хуҗаханова. – Казан: Татгосиздат, 1940. – 119 б.

*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен хәрәкәтле уеннар* / төз.: Г. Х. Хуҗаханова, Р. М. Козлова. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 80 б.

Миңлекәй С. *Балалар өчен җырлы уеннар*. Кит. 1 / С. Миңлекәй. – Бөгелмә, 1921. – 14 б.

Миңлекәй С. *Тезмә сүзләр* / С. Миңлекәй. – Казан: Татиздат, 1931. – 42 б.

Миңлекәй С. *Балалар өчен җырлы уеннар*. – Тулыл. басма / С. Миңлекәй. – Казан, 1925. – 47 б.

Мортазина Л. Р. Җырлы уеннар // Мәгариф. – 2010. – № 10. – 41–44 б.

Мортазина Л. Р. Уйныйк әле бергәләп // Мәгариф. – 2012. – № 2. – 48–49 б.

Мортазина Л. Р. Туплы уеннар // Мәгариф. – 2012. – № 3. – 30 б.

Салихова З. *Мәктәпкә кадәр тәрбия өчен кулланма*: 3 яшь белән 7 яшь арасындагы балалар өчен уен, шигырь белән пластика, тән хәрәкәтләре мәҗмугасы / З. Салихова. – Казан: Татар. матб. нәшр. комб., 1925. – 46 б.

*Татар балалар фольклоры*/ төз. Р. Ягъфәров. – Казан: «Раннур» нәшр., 1999.

*Уеннар:* балалар площадкасы тәрбиячесенә ярдәмлек. – Казан: Татгосиздат, 1945. – 14 б.

Ягъфәров Р. *Кәҗә-мәкәрҗә*: балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 1994. – 110 б.

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш ........................................................................................ 3

### I бүлек. Уйныйк, сөеник, көлик

### Хәрәкәтле уеннар

***2–3 яшьлек балалар өчен уеннар*** ....................................... 10
Куяным ...................................................................................... 10
Йонлач көчек.............................................................................. 10
Куян........................................................................................... 11
Мәче.......................................................................................... 12
Тавыклар һәм әтәч...................................................................... 13
Кәҗә.......................................................................................... 14
Чебешле тавык........................................................................... 14
Җитез балалар............................................................................ 15
Казлар ....................................................................................... 15
Курчак белән куыш уены ............................................................ 16
Кояш һәм яңгыр.......................................................................... 16
Кем тупны тизрәк китерә?........................................................... 17
Поезд......................................................................................... 18

***3–4 яшьлек балалар өчен уеннар*** ....................................... 19
Кара урманда, аю янында .......................................................... 19
Куык.......................................................................................... 20
Тавыклар яшелчә бакчасында .................................................... 20
Кем тизрәк?................................................................................ 20
Мәче һәм тычканнар .................................................................. 21
Тигез юл буйлап.......................................................................... 21
Төрле төстәге өйләр ................................................................... 22
Куян........................................................................................... 22
Флагны тап ................................................................................ 23
Тупны тәгәрәтә бел .................................................................... 24
Тере туплар ............................................................................... 24
Кошлар....................................................................................... 24
Кыңгырауны тот!........................................................................ 25

Кунакны таны! ............................................................................. 25
Мәче һәм мәче балалары .................................................................... 26
Светофор ........................................................................................... 27
Аюны кем чакырды? ............................................................................ 27
Сез яңгырдан куркасызмы? .................................................................. 28
Кем тизрәк? ........................................................................................ 28
Тигез юл буйлап .................................................................................. 29
Очкычлар ............................................................................................ 30
Аю һәм бал кортлары .......................................................................... 31
Туп ..................................................................................................... 31
Туп белән үткәрелә торган уеннар ....................................................... 32

***4–5 яшьлек балалар өчен уеннар*** ...................................................... 33
Тота бел .............................................................................................. 33
Тизрәк урыныңа бар ............................................................................ 34
Көтүче ................................................................................................ 34
Куяннар .............................................................................................. 35
Бүре һәм көтү ..................................................................................... 36
Кая йөгерергә? .................................................................................... 37
Өрел, куык! ......................................................................................... 37
Куышу ................................................................................................ 38
Туп белән куышу ................................................................................. 39
Аучы һәм ерткыч җәнлекләр ................................................................ 39
Кайда яшерелгән, тап ........................................................................... 40
Әйдә, безне куып кара... ...................................................................... 41
Яңгыр ................................................................................................. 41
Бакалар .............................................................................................. 42
Соры бүре ........................................................................................... 42
Куяннар .............................................................................................. 43
Кыш бабай .......................................................................................... 44

***5–6 яшьлек балалар өчен уеннар*** ...................................................... 45
Тот, тот! .............................................................................................. 45
Авыз ачып калма ................................................................................. 45
Үз төсеңне эзлә ................................................................................... 46
Үз «капитаныңны» тап ........................................................................ 46

Төлке тавык кетәклегендә .......... 47
Тавышыннан бел .......... 47
Йомырка белән йөгерү .......... 48
Үрмәкүч һәм чебеннәр .......... 48
Балалар һәм чуртан .......... 49
Кем тизрәк җыелыр? .......... 49
Тиенне тот! .......... 49
Атлар .......... 50
Җәнлекне камап ал! .......... 51
Сыерчык оялары .......... 52
Хәйләкәр төлке .......... 52
Бүредән кач! .......... 53
Төз ыргыту .......... 54
Каршылыкларны үтеп ярышу .......... 54
Тупны ыргыт! .......... 55
Шарларның очрашуы .......... 55
Капчыкны алмаштыр! .......... 56
Тупны сетка аша ыргыту .......... 56
Сазлык .......... 57
Кул чабу .......... 57
Кошлар һәм мәче .......... 58
Йорт куяннары .......... 58
Башлык һәм таякчык .......... 59
Карусель .......... 60

***6–7 яшьлек балалар өчен уеннар*** .......... 61
Күз бәйләш .......... 61
Узышчылар .......... 61
Җитез бул! .......... 62
Коткаручы таяк .......... 62
Тычкан тозагы .......... 63
Кем ераграк ыргыта? .......... 64
Флагны кем тизрәк алыр? .......... 65
Оясыз күке .......... 65
Куяннар һәм аучылар .......... 66

Чыпчыклар һәм мәче ........................................................ 66
Хоккей уены ........................................................................ 67
Туп кайда? ........................................................................... 68
Козгын һәм чебиле тавык ...................................................... 68
Күбәләк тоту ........................................................................ 69
Тупны тотып ал! .................................................................. 69
Бозларны тизрәк керт ........................................................... 70
Тупны җибәрмә! ................................................................... 70
Божраны кидер! .................................................................... 71
Әйберне сакла! ..................................................................... 71
Мәче һәм тычканнар ............................................................ 72
Инеш аркылы ....................................................................... 73
«Җитезләр мәктәбе» ............................................................ 73
Табышмаклы уен ................................................................. 75
Кыршаулар белән уеннар ..................................................... 76
Гөр-гөр ............................................................................... 78
Бау (сикергеч һ. б.) белән уеннар .......................................... 79
Почмак алыш ...................................................................... 79
Узышчылар .......................................................................... 80
Буш урын ............................................................................ 81
Акула .................................................................................. 81
Сәяхәт ................................................................................. 82
Аксак төлке ......................................................................... 83
Аю һәм балалар .................................................................... 84
Аучылар, куяннар һәм этләр ................................................ 84
Курыкмыйм! ........................................................................ 85
Тупка бәреп тидер ................................................................ 85
Куыш уены .......................................................................... 86

## II бүлек. Уйнап күңел ачабыз

### Аз хәрәкәтле уеннар

Кулда нәрсә бар икәнен бел! .................................................... 88
Кайда шалтыратканны бел! ..................................................... 88
Нәрсә яшерелде? ...................................................................... 88
Төймә салыш ............................................................................ 89
Мәче балалары һәм балалар .................................................... 89
Атлар һәм колыннар ................................................................ 90
Аю, мине таны! ........................................................................ 90
Әби, уян! .................................................................................. 90
Кемгә теләсәң, шуңа бир ......................................................... 91
Очты, очты... ............................................................................ 91
Артта кем тора? ....................................................................... 92
Ак аю һәм аның балалары ........................................................ 92
Болай ярый, болай ярамый ....................................................... 92
Төньякка бару .......................................................................... 93
Сәгать ....................................................................................... 93
Мәзәкче ..................................................................................... 94
Кем яшеренде? ......................................................................... 95
Нәрсә оча? ................................................................................ 95
Музыканы тыңлый бел! ........................................................... 96
Тынлык уены ............................................................................ 96
Фантлар .................................................................................... 97
Рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне бел! ......................................... 97
Бака белән челән ...................................................................... 98
Тап һәм эндәшмә ...................................................................... 98
Эндәшмә! .................................................................................. 99

### Җырлы-биюле уеннар

Уенга җыю җыры .................................................................... 100
Безнең капка төбендә .............................................................. 101
Үрмәкүч ................................................................................... 102
Парлашып калу ........................................................................ 103
Ак калач ................................................................................... 103

Коймак........................................................................................ 104
Сукыр тәкә.................................................................................. 104
Наза............................................................................................ 105
Яулык алыш ................................................................................ 105
Капкалы...................................................................................... 106
Кунаклар..................................................................................... 106
Куаклар, кошлар һәм тилгән ...................................................... 107
Куянкай ...................................................................................... 108
Нәни булышчылар...................................................................... 108
Өч кош ........................................................................................ 109
Куян белән эт ............................................................................. 110
Коймаклар ..................................................................................111
Нардуган ....................................................................................111
Түбәтәй ...................................................................................... 112
Мәче белән тычкан .................................................................... 112
Ялкау мәче ................................................................................. 114
Күрсәт әле, Габдулла! ................................................................ 114
Габдулла..................................................................................... 116
Мәк ............................................................................................ 116
Гөл утыртканда .......................................................................... 117
Бала белән кош ........................................................................... 118
Бию җыры .................................................................................. 119
Утыр, утыр, Мәликә .................................................................. 119
Тамчы, там!................................................................................. 120
Яшерәм яулык ............................................................................ 120
Төймә.......................................................................................... 121

## Идел буе халыклары уеннары

Әбәк-күбәк *(башкорт халык уены)* ........................................ 122
Энә белән җеп *(башкорт халык уены)* ..................................... 122
Давыл *(башкорт халык уены)* ................................................... 122
Без унике кыз идек! *(башкорт халык уены)* ........................... 123
Үгез-йөзек *(башкорт халык уены)* ........................................... 123
Буяу сатыш *(башкорт халык уены)* ......................................... 124

Исемен ата! *(башкорт халык уены)* .................................... 125
Чыршы *(рус халкының җырлы уены)*.................................. 126
Зур туп *(рус халык уены)* ......................................................... 127
Бәйләгән аяклар белән йөгерү *(рус халык уены)*................. 127
Аю янында, урманда *(рус халык уены)* ................................ 127
Киек җәнлекләр өйрәтүче *(рус халык уены)*......................... 128
Балык тоту *(рус халык уены)* ................................................ 128
Тилгән *(рус халык уены)* ......................................................... 129
Шаян казлар *(рус халкының җырлы уены)* .......................... 130
Шалкан *(рус халык уены)* ......................................................... 131
Бүре һәм куян *(чуваш халык уены)* ......................................... 133
Таралыгыз! *(чуваш халык уены)* ........................................... 134
Чәчәкләр *(чуваш халык уены)* ................................................ 134
Урындык *(уен варианты)* ......................................................... 135
Туп һәм чокыр *(удмурт халык уены)* ..................................... 135
Су анасы *(удмурт халык уены)* ............................................... 136
Куышу *(удмурт халык уены)*.................................................... 136
Кулъяулык белән уен *(удмурт халык уены)* ........................ 137
Түгәрәктә *(мордва халык уены)* .............................................. 137
Туп тәгәрәтү *(мари халык уены)* ............................................. 138

## III бүлек. Уйнап һич тә туймыйбыз...

***Физкультминутлар***.................................................................. 140
Яшел бакча ............................................................................. 140
Чәбәк-чәбәк ............................................................................. 140
Үсәм........................................................................................ 140
Кошлар.................................................................................... 141
Нәниләр .................................................................................. 141
Без шулай ял итәбез ............................................................... 141
Үсеп китте .............................................................................. 142
Матур тубым .......................................................................... 142
Уңган балалар ........................................................................ 142
Бармаклар ............................................................................... 143
Коңгызлар............................................................................... 143

Карагыз ........ 144
Без атлап барабыз ........ 144
Без рәсем ясадык ........ 144
Куянкай ........ 144
Бакчачылар ........ 145
Туганым ........ 146
Кыен эш түгел бер дә! ........ 147
Аш пешерү ........ 147
Кар бөртеге ........ 148
Кышкы урманда ........ 148
Чәчәкләр ........ 149
Куллар ........ 149
Утырып арыдык ........ 150
Без инде хәзер зурлар ........ 150
Без яздык ........ 150
Һәркайсының үз эше ........ 151
Кер юу ........ 151
Кер юучылар ........ 152
Атлап йөргәндә ........ 152
Мәрьям әби малайлары ........ 153
Гимнастика уеннары ........ 153

***Санамышлар*** ........ 155

***Балаларны уенга җыю өчен шигырьләр, җырлар*** ........ 162
Бакча балалары ........ 162
Җәй көне ........ 164
Бала һәм сандугач ........ 164
Күке ........ 165
Күгәрченнәр ........ 166
Кошлар җыры ........ 166
Бозау ........ 167
Хайваннар тавышы ........ 167
Хайваннар чакыру ........ 167
Әнә мәктәп, әнә балалар! ........ 168
Поезд ........ 169

Кармак салганда ........................................................................ 170
Торналар җыры .......................................................................... 171
Каз бәбкәләр чыгаргач................................................................ 172
Каз бәбкәләре саклаганда ........................................................ 173
Кошларны чакыру ..................................................................... 174
Яңгыр һәм балалар..................................................................... 174
Буш уй ........................................................................................ 176
Йорт казы белән ат ..................................................................... 176
Унга чаклы санау........................................................................ 176
Уннан кирегә санау ................................................................... 178
Бала белән ата............................................................................. 180
Бала белән күке .......................................................................... 180
Беләмсез, без кем? ..................................................................... 180

Файдаланылган әдәбият .......................................................... 181

**Кафия Валиевна Закирова**
**Ляля Раисовна Муртазина**

# Игры в детском саду

***Методическое пособие для воспитателей детских садов и инструкторов по физкультуре***

**Кафия Вәлиевна Закирова**
**Ләлә Рәисовна Мортазина**

# Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак

**Балалар бакчасында уеннар**

***Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма***

Корректоры *Г. Г. Мөһәмәтҗанова*
Рәссамы *Л. Ф. Башарова*
Компьютерда биткә салучы *А. И. Галиуллина*
Рецензентлары *М. М. Гибатдинов, Н. Г. Зарипова, М. Г. Шиһабиева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.05.2012.
Формат 60х90 1/16.Офсет кәгазе.
Офсет басма. Басма табагы 12.
Тиражы 5000 д. Заказ № 8.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристов урамы, 2.